www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 37 (1453) 22 сентябрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

6

Шагыйрә Нурия Измайлова тумышы белән Башкортстанның Благовар районыннан булса да, гомере буе татар милләтенә дан җырлады, шигырьләре дә нечкә лирика белән аерылып тора иде.

12-13

Бүген татар теле һәм ислам дине читкә тибелсә дә, 1840 елда Казан университетында шәрык факультеты ачылган, гарәп каллиграфиясен өйрәнү һәм камилләштерү һәрвакыт күз уңында тотылган.

19

Спас районының Көек авылында, Абдулла Алишның авылдашы булып туган Фәрдия апа Гатина быел 99 яшен тутырды, ә аның 15 ел гомере тракторда эшләп узган.

Кибранә гүзәл тыйнаклык та Бик килешә Аллаһ йортына!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Узган атнада Татарстан Рәисе Р.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык Юлламасы тәкъдим ителде.

- Үзбәкстан башкаласының «Туркистон» сәнгать сараенда узган Халыкара конкурста «Татар кызы-2023» исеменә Пенза өлкәсеннән Альбина Медведева лаек булды.

- Татарстан башкаласында Россиянең 23 төбәгеннән 150 делегат катнашында XXXIII Татар яшьләре көннәре узды.

- 2024 ел Татарстанда Фәнни-технологик үсеш елы буларак игълан ителде, бу хакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юллама барышында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Миңнеханов белдерде.

- Казанда беренче тапкыр «АРТМИГРАЦИЯ» Бөтенроссия яшь режиссура фестиваль-форумы уза. Тинчурин театры сәхнәсендә фестивальнең төп программасындагы 4 спектакль куелачак.

- Самарада «Туган як» оешмасы җитәкчесе, хәйрияче Рөстәм Хисмәтов куркыныч юл һәлакәтеннән соң савыга алмыйча вафат булды.

- Чыңгыз Айтматовның 95 еллык юбилее уңаеннан Новосибирск шәһәрендә «Мир Айтматова» дип аталган үзәк ачылды.

- Татарстанда көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләре башланды, алар 23 декабрьдә тәмамланачак.

- Илдән киткән россиялеләргә кире кайту өчен рус телен белүләрен расларга туры киләчә, яңа кагыйдә 2024 елда чит илдә яшәүче ватандашларны кучеру программасына кертелә, ул Белоруссия, Молдавия, Украина һәм Казахстанда яшәүчеләрдән башка барлык чит ил гражданнарына кагыла.

- Россиядә 1 октябрьдән хәрби пенсионерларның пенсияләре арта, бу элеккеге хәрби хезмәткәрләргә, дәүләт саклаучыларына, ФСИН, Эчке эшләр министрлыгы һәм отставкадагы башка көч структуралары, шулай ук чик буе яки тимерьюл гаскәрләрендә хезмәт иткән гражданнарга кагыла.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

23 сентябрь – җырчы, режиссёр, профессор, ТАССР-ның, РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Нияз Курамша улы Даутовның тууына 110 ел (1913–1986);

– балет артисты, балетмейстер, РСФСРның атказанган артисты Әдһәм Фазылҗан улы Нарыковның тууына 100 ел (1923–1968).

25 сентябрь – музыка белгече, педагог, профессор, ТАССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Яков Моисеевич Гиршманның тууына 110 ел (1913–1990).

28 сентябрь – педагог, нәшир, журналист, сәясәтче Әхмәтһади Низаметдин улы Максудиның тууына 155 ел (1868-1941).

СЫНАМЫШЛАР

23 сентябрьдә гөмбә күп икән, кышын кар аз булыр ● 25 сентябрь – җәйдән инде бит сыпыр; бу көнне җил тынмыйча һәм юнәлешен үзгәртеп иссә, һава торышы бозыла ● 28 сентябрьдә чикмән төшә, тун менә ● Мәче башлы ябалак кычкырса, суыклар башланыр ● Торна кышларга иртә китсә, кыш суык һәм озак булыр.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 28 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 46 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **12 сәгать 18 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **29 сентябрьдә 11 сәгать 46 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Сентябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(22-29 сентябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген рабигүл әүвәл аеның 7 нче көне

КӨН КАДАГЫ

«ЯШЬЛӘР 150 МЕҢГӘ ДӘ ЭШКӘ КИЛМИ»

Түбән Новгородтагы Сергач районының Шөбиле (Шубино) авылы фермеры Фаил АРИФУЛЛИН мәшәкать-хыяллары турында яшермичә сөйли.

Фаил абый – үз авылында данлыклы эшмәкәр, 3 бала әтисе. Түбән Новгород идарә институтында белем алган. Үзе белән иркенләп таныштырды.

– Мәктәптә 10 ел укыгач, армиягә киттем, Владимир шәһәрендә эчке гаскәрләрдә 2 ел хезмәт иттем. Хатыным Гөлнур белән армиядән кайткач кына таныштым. 10 ел көрешеп йөргәч, өйләнештек (көлә). Озакка сузылды азрак. Беренче планда бизнес кору иде. Нужа күрдек башта, аннары тормыш кордык. Аллага шөкер, 2 кызым, 1 улым бар – Гөлназ, Ильяс, Самира.

Хатыным башта башлангыч сыйныф укучыларын укытты, хәзер миңа бөтен нәрсәдә булыша. Гел үземнең янымда. Нигездә бухгалтерияне алып бара. Оныкларым юк әле.

Фермер булып киткәнче, Сергач кош фабрикасында директор булып эшләдем. Анда казлар, кошлар үрчеттек. Анда мин 10 ел эшләдем. Аннары фабрикага авыл җирләрен алган идем. Шуннан иплән торып фермерлык белән кызыксынып киттем. Кош фабрикасыннан соң арендага 300 гектар җир алдым. Аннары сарыклар, атлар үрчетә башладым.

«Фермер булам!» – дигән төгәл максатым булмаса да, мин гел бизнес өлкәсендә кайнадым. Үземнең кибетләрем, заправкаларым булды. Бизнесмен инде. Аннары тулаем фермерлыкка киттем.

Хуҗалыгымда 500 баш сарык бар. Шөбиледә 450 кеше яши. Авылда бер генә зур фермер. Ул да булса – мин. Кечкенә фермерлар белән без бергә эшлибез. Аларның 100әр гектар җирләре бар.

Сабан туйларына сарыклар үстерәм. Сарыкларны үрчетәбез, сатабыз, йоннарын Чабаксар оешмасына җибәрәбез. Алар итекләр тегә, без бартерга алабыз, акча бирмиләр.

Атлар да үрчетәбез. Бөтен татар ат үрчетеп эш башларга тотынадыр инде. Тик алар миндә күп түгел – 12-15 баш. Нигездә «Московские тяжеловозы» токымы. Берәр тонна, 800 килограммга җитә. Монысы күңел өчен.

300 гектар җирем бар. Безнең төп юнәлешебез – чөгендер. Сергач бит шикәр заводы белән танылды.

Фермерлыкта төп ике проблема бар. Ул да булса – бәяләр сәясәте һәм кадрлар җитмәү. Алдагы елда орлык 15 тора иде, хәзер 7 сум. Эшләргә кеше җитмәү – ул төп проблема. Кеше җитмәгәч, эшләп тә булмый. Мин яшьләргә эш тә тәкъдим итәм. Хезмәт хаклары 50 дә, 70 дә, 150 мең дә була. Тик эшләтеп булмый берничек тә!

Менә малаем үсеп җитте. Ул Түбән Новгородта авыл хуҗалыгы академиясендә 2 курста укый. Ул миңа эшләргә булыша. Заманча техникаларда эшли белә.

Фермада 10-12 сәгать эшлибез. Иртә китәбез дә төнлә кайтабыз. Кайсы көнне бөтенләй ятып тормыйбыз. Андый вакытлар да булгалый.

● Фаил Арифуллин.

● Хәбиб Измайлов.

– Техникага запчастьләр җитәме?

– Аның белән проблемалар бар. Америка, Германия, Канада техникасы алып бетергән идек, көтмәгәндә санкцияләр керттеләр бит. Шулай да, әлегә табыштырабыз. Әллә аларның складларында калган шунда. Бәяләре 2 тапкырга артты.

– Яшьләргә, студентларга практика үтү мөмкинлеге бармы соң?

Эшләргә кеше җитмәү – ул төп проблема. Кеше җитмәгәч, эшләп тә булмый. Мин яшьләргә эш тә тәкъдим итәм. Хезмәт хаклары 50 дә, 70 дә, 150 мең дә була. Тик эшләтеп булмый берничек тә!

– Практика юк. Безгә йә юрист, йә турист килә (көлә).

Фермер Түбән Новгород өлкәсендәге һава торышы белән дә мактанып алды. Аның сүзләренчә, быел уңыш әйбәт көтелә.

– Игеннәр яхшы хәлдә бездә. Яңгырлар да еш яуды. Безнең быел, Алла теләсә, уңышлар яхшы. Безнең җирдә һава торышы шартлары гел әйбәт, җирләре уңдырышлы. Татарстанда «гадәттән тыш хәлләр режимы» керттеләр, дип ишеттек. Безгә инде Татарстаннан орлык сорап элемтәгә чыктылар, без сезнең белән тыгыз элемтәдә торабыз, – диде фермер.

Мин Фаил абыйдан корылыклы ел булу сәбәпле бирелә торган иминият акчалары – страховка турында сорадым. Шунда аның кәефе кырылды.

– Юк бездә страховка! Без үз көчебезгә таянып эш итәбез. Страховка – ул ничек? Мәсәлән, минем җирләрне иминиятләштерү өчен якынча 10 миллион акча кирәк. Бер елны страховка ясаткан идем, ә ул фирма ахыр чиктә югалды! Ягъни җитәкчесе бер булган, ә фирмасы ике төрле. Аннары ул фирма бурычларын башка фирмага саткан да, икенче фирма ул бурычларын бездән алды. Дөресе генә әйткәндә, шундый бер махинация булган. Аннары без акчаларыбызны судлар аша зур авырлык белән генә кайтардык. Бөтен Түбән Новгород төбәге белән судлаштык! Ышанмыйбыз инде башка страховкага. Ышанырлыгыбыз калмады. Кайсы яклардадыр бар инде ул хакимият ярдәме. Ә бездә юк андый әйбер. Кайчандыр корылык килә калса да, страховка ясату турында уйламыйбыз. Без инде 2 еллык запас тотабыз, – дип сөйләде фермер.

Безнең сөйләшүгә Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Хәбиб ИЗМАЙЛОВ та кушылды.

– Без Фаил белән күрше авыллардан. Без (басым ясап – авт.) – татар авыллары! Бездә нигездә иген үсә. Терлек тә тотабыз. Безнең район уңыш буенча узган елны беренче урынны алды. Былтыр район белән 125 мең тонна иген җыйдык. СССР вакытында да андый нәтиҗә булганы юк иде. Быел да һава торышы белән без бик канәгать. Аллага шөкер. Ел саен яңгырлар вакытында явып тора. Игеннәр яхшы булырга тиеш. Хак кына булсын, хак кына булсын… Химия дә кулланабыз инде. Аларсыз үстереп булмый... Халык бездә тырыш, эшчән. Безнең районда – төбәктә иң күп фермерлар. Кызыл Октябрь авылында 68 фермер, 28 авыл хуҗалыгы оешмасы. Якынча 7 меңгә якын шәхси ярдәмче хуҗалык. Барысы да эшчән, – дип сөйләде ул.

Хәбиб абыйдан: «Ә сез Мәскәү белән күбрәк элемтәдә торасызмы яки Казан беләнме?» – дип сорагач, «Казан безнең белән элемтәгә чыга. Иген алалар. Хәтта ягулык-майлау материаллары белән казанлылар безнең якка йөри. Казаннар белән Бөтенроссия эшмәкәрләре белән җыелганда күрешәбез», – диде ул.

Ралинә СӘЛИМОВА.

Мөгаллимнәргә өстәмә грантлар

Республикада Укытучылар һәм остазлар елында «Безнең яңа укытучыбыз» грантын кабаттан тулы башлыйлар. 200 яшь педагог 3 ел дәвамында ай саен хезмәт хакына өстәмә рәвештә 10 мең сум акча алачак.

Исегезгә төшерәбез, «Безнең яңа укытучыбыз» гранты Татарстанда 2011 елда ук гамәлгә куелган иде. Ул вакыттагы ТР Мәгариф һәм фән министры Альберт Гыйльметдинов Татарстан югары уку йортларын тәмамлаган, шул ук вакытта педагогик белеме булмаган хәлдә мәктәпкә эшләргә килгән яшьләргә өстәмә акча түләргә тәкъдим итте. Шулай итеп мәктәпләрдә педагогик кадрлар җитмәү проблемасы гына хәл ителми, ә укучыларны әзерләү сыйфаты да яхшыра, чөнки физиканы аларга КФУның физика факультетын тәмамлаганнар, химияне кичәге КФУ яки КНИТУ – КХТИ студентлары һ.б. укыта ала иде.

Республикада грантларны 2020 елга кадәр түләделәр. Айлык 10 мең сумлык түләүләр мәктәпләргә 1700 яшь педагогны җәлеп итәргә ярдәм итте. Билгеле булганча, мәктәпкә яңа гына килгән укытучының уртача хезмәт хакы аена 20 мең сум тәшкил итә.

Грант алу конкурсында мәктәптә 3 елдан артык эшләмәгән яшь укытучылар катнаша ала (минималь стаж чиге, Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәтендә аңлатуларынча, чикләнмәгән, бу хәтта 1 көн дә булырга мөмкин). Алар 35 яшьтән яшьрәк булырга һәм Татарстанда даими яшәргә тиеш. Грант программасын гамәлгә ашыру вакыты – 2028 елга кадәр. Грант 3 елга билгеләнә.

Соңгы вакытта, укытучыларга кытлык темасы яңадан актуальләште һәм кабаттан, мәктәпләрдә яшь кадрларны матди яктан стимуллаштыру яхшы булыр иде, дип сөйли башладылар. Бер ел элек ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты депутатлары хөкүмәткә «Безнең яңа укытучыбыз» грантын түләүне яңартуны сорап мөрәҗәгать итте. Менә 2023 - Укытучылар һәм остазлар елында, Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов хуплавы белән, мәгариф тармагында кадрлар дефицитын чишү һәм яшь педагогларны мәктәпләрдә калдыру максатыннан грантны яңарту турында карар кабул ителде.

Грант алу конкурсында мәктәптә өч елдан артык эшләмәгән укытучылар катнаша ала. Шул ук вакытта минималь стаж, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәтендә аңлатуларынча, чикләнмәгән, бу хәтта 1 көн дә булырга мөмкин. Дәгъвачылар 35 яшьтән яшьрәк булырга һәм Татарстанда даими яшәргә тиеш.

Грант 3 елга билгеләнә, яшь педагоглар (елына 200 кеше) ай саен (җәйге каникуллардан тыш) хезмәт хакына өстәмә рәвештә 10 мең сум алачак, бер уку елында барлыгы 90 мең сум. Киләсе елда 200 грант алучыга тагын 200 өстәләчәк. Гомумән алганда, «Безнең яңа укытучыбыз» грант программасы 2028 елга кадәр гамәлдә булачак. Конкурста катнашу өчен гаризалар җирле мәгариф идарәләрендә формалаштырыла, диелә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы порталында.

Фото: https://rt-online.ru/

Даруларны – рецепт буенча

Ике көннең берсендә хөкүмәт карарлары үзгәреп тору гадәти хәлгә әйләнгән чорда кайсы яктан нинди үзгәреш җиле исүен аңламый да каласың. Сентябрь аенда тагын бер яңалык үз көченә керде. Ул – кайбер даруларны рецепт белән җибәрү мәсьәләсе.

Яңа кагыйдәләр буенча кайбер рецепт препаратлары хәзер «Намуслы билге» системасында исәпкә алыначак. Сүз психотроп препаратлар һәм көчле тәэсир итүче яки агулы матдәләр булган барлык дарулар, дәүләт өлешчә яки тулысынча түли торган ташламалы препаратлар, шулай ук онлайн сатып алынган рецепт чаралары турында бара.

Хәзер провизорлар, яңа кагыйдәләргә кагылучы рецепт чараларын җибәргәндә, «Намуслы билге» системасына рецептның датасын, сериясен һәм номерын тапшырырга тиеш булачак. Ягъни, аптека хезмәткәрләре һәр дару өчен тулы хисап тотачак.

Перспективалы технологияләрне үстерү үзәге биргән аңлатма буенча, яңа система дарулар әйләнеше белән бәйле хокук бозулар санын киметергә, ташламалы рецептларны исәпкә алуны яхшыртырга, шулай ук даруханәләргә рецептларның чынлыгын тикшерергә мөмкинлек бирәчәк.

1 нче биттә – Чистай шәһәрендәге 1859 елда төзелгән иң борынгы мәчетләрнең берсе. Рөстәм Сафиуллин фотосы.

Бер сайтта бер миллион татар әйтеме!

Яр Чаллыдан Фәһим Җиһаншин һәм Казаннан Шамил Зариповның tt.forvo.com халыкара әйтелешләр һәм аудиосүзлекләр сайтындагы эшчәнлекләре турында без узган ел язган идек инде. Ниһаять, әлеге шәхесләребез үз алларына максат итеп куйган нәтиҗәгә иреште: бу халыкара сайтта татар телебездәге миллионынчы кертемнең аудиоязмасы язылды!

Фәһим Җиһаншин бу хакта болай аңлатты: «Быел җәй бик эссе килде, шуңа күрә бик озак утырып эшләп тә булмады... Әгәр, гадәттәгечә, бер көн эчендә 300-400 әйтелеш кенә яздырып барсак, Татарстан республикасы көне бәйрәменә кадәр миллионынчы татар әйтемен өсти алмаган булыр идек. Мин: «Инде җитешмәбез, сентябрь ае җитәр», – дигән идем, Шамил килешмичә, бик кызу эшли башлады. Ул көненә берүзе 600-800 татар сүзен яздырып барды. Мин аның өчен сүзләр һәм җөмләләр туплап һәм сайтка өстәп, «чимал» әзерләп тордым. Баксаң, Шамил Зариповның үз ана телебезне яратуы минекенә караганда бермә-бер көчлерәк икән.

Миллионынчы әйтелеш! Миллионынчы әйтелеш итеп без каһарман шагыйребез Муса Җәлилнең «Җырларым» шигыреннән һәр татар кешесенә дә таныш булган, һәр татар да күңелендә йөрткән ике юлны сайладык.

1 000 000. «Сездә минем бөтен тойгыларым, сездә минем керсез яшьләрем».

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, бу җөмләләрне 30 август кичендә яздырдым. Республика көне бәйрәме тамашасы дәвам итә иде әле...

Муса Җәлилнең шушы юлларын ике яктан да Әзербайҗанның халык шагыйре Бәхтияр Ваһабзадәнең Муса Җәлилгә багышланган «Очыгыз, тулпарларым!» поэмасындагы юллар белән уратып алдык.

999 999. «Урадылар җырлар бар дөньяны, барлык киртәләрне үттеләр».

1 000 001. «Җыры белән шагыйрь мәңгелеккә ашты».

Йөз кырык юллык поэма әзербайҗан телендә узган гасырда, 1966 елда ук язылган, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис аны инде сиксәненче елларда тәрҗемә иткән икән, без бу дулкынландыргыч әсәрне күптән түгел «Мәдәни җомга» газетасы битләреннән укыдык. Һәм шул хакта да өстәр идем: «Мәдәни җомга» газетасы ул халкыбызны телебез, тарихыбыз, сәнгатебез белән тирәнтен таныштырып баручы искиткеч яхшы газета. Шәхсән мин аның һәр санын тулысы белән укып барам!»

Яңалыкны йомгаклап, шушы тырыш шәхесләребез – Фәһим Җиһаншинга һәм Шамил Зариповка да ана телебезне зурлаудагы үз эшчәнлекләрен дәвам итүләрен телəп калабыз!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Севастополь утка тотылган

Украина хәрби көчләре (ВСУ) 13 сентябрь кичендә Севастопольгә ракеталар белән аттырган. Герой-шәһәрдәге 8 торакка зыян килгән, дип белдергән шәһәр губернаторы урынбасары Евгений Горлов. Шәһәр губернаторы Михаил Развожаев 24 кешенең яралануын, дүртесенең хәле уртача дип бәяләнүен таныган. Горлов сүзләренчә, күп фатирлы 7 йортның, 1 шәхси өйнең түбәсенә, фасадларына һәм тәрәзәләренә зыян килгән.



Оборона министрлыгы хәбәрләре буенча, ВСУ көймәләр ремонтлый торган заводка канатлы 10 ракета белән аткан. Ремонттагы 2 корабка зыян килгән. Шул ук вакытта диңгез дроннары белән Кара диңгез флоты корабларына һөҗүм ителгән. Канатлы 10 ракетаның 7 сен бәреп төшерә алганнар. «Василий Быков» патруль корабы диңгез дроннарын бәреп төшергән.

Севморзаводта янгын чыккан. Аны сүндергәннәр. Хәрби эксперт Василий Дандыкин Севастопольгә Британиядә ясалган Storm Shadow ракеталары белән һөҗүм ителгәнен фаразлаган.

«База» телеграм-каналы, Севастопольдә 2 кеше һәлак булган, дип яза.

Шул ук кичтә Тверь өлкәсендәге «Редкин тәҗрибә заводы»на да дроннар һөҗүм иткән, ракетаны икенче урынга төшерергә мәҗбүр иткәннәр.

«Военный осведомитель» телеграм-каналы «Минск» десант корабленә дә зыян килү турында хәбәр итә.

intertat.tatar.

Арчада «Ат көне»

Арча районының Яңа Кырлай авылында 9 нчы тапкыр традицион ат-спорт бәйрәме – «Ат көне» узды. Ат чабышлары, «Аударыш» уены, «Ат арбасында иң тиз йөртүче», «Иң матур бизәлгән арба» конкурслары, тизлеккә кымыз эчү, өчпочмак ашау ярышлары булып үтте.

Ат гомер-гомергә татар халкының тугры дусты була. Татар телендә атның 99 атамасы бар. Ул төркиләрне дөнья цивилизациясе мәйданына, тарихына күтәреп кергән баһадир иде. Евразия тарихында төркиләр ат өстендә бөеклеккә ирешә. Татар халкы атны үзенең канаты дип санады.

Хәзерге вакытта да атчылык кәсебенә зур игътибар бирелә. Арчада «Ат көне» 2015 елдан бирле үткәрелеп килә. Ел саен 150 гә якын чиста, ярымкатнаш, җирле токымлы һәм татар атлары катнашучы бәйгенең колачлары киңәя бара. 2015 елда ат ярышлары 40 чакрымга гына үткәрелгән булса, хәзер инде атлар 80, 100, 120 һәм 160 чакрым дистанцияләрдә дә ярыша. Чараның колачы гына түгел, географиясе дә киңәя: Мәскәү, Ленинград, Тамбов, Липецк, Пенза өлкәләреннән, Кабарда-Балкар, Карачай-Черкес республикаларыннан катнашучылар да бар.

Бәйрәмдә соңгы елларны популярлашып баручы «Аударыш» уены да күрсәтелде. «Аударыш» Татарстанда татар токымы атларда гына уза. Ул – борынгы төрки уен. Аударыш кагыйдәләре буенча 2 җайдак бер-берсен иярдән тартып алырга яки көндәшен җиргә тартып төшерергә тиеш.

Быел «Аударыш»та барлыгы 15 егет көч сынашты. Алар 2 авырлык категориясенә бүленгән иде: 80 килограммга кадәр һәм 80 килограммнан артык.

«Аударыш»та: 80 килограммга кадәр авырлыкта: Рөстәм Әмиров (Тукай районы), Наил Ибәтов (Әлмәт) һәм Алик Зиннуров (Әлмәт), 80 килограммнан артык авырлыкта: Инсаф Хөсәенов (Тукай), Илнур Әхмәтов (Әлмәт) һәм Александр Карнеев (Ютазы) җиңеп чыкты.

Татарстанда халкыбызның борынгы, ләкин бүгенге көнгә кадәр сакланып кала алмаган уен төре – «Аударыш»ны Лениногорск районы «Алмакай» хуҗалыгы җитәкчесе Фәрит Нәбиуллин торгызып җибәрә.

– Без татар атларын үрчетәбез, безнең хуҗалыкта 600 чамасы ат бар. Без Республика, Россия күләмендә «Аударыш» бәйгесен торгызып җибәрдек. Хәзер бик күп төбәкләрдән әлеге бәйгедә катнашалар: ногайлар да, башкортлар да, алтайлар да, калмыклар да, хакаслар да һәм үзебезнекеләр – татарлар инде. Быелгы «Аударыш» та һәрвакыттагыча бик матур үтте. Көне дә кояшлы, җылы. Арча халкы бик яратып каршы ала, монда гел кеше күп була. Егетләр төрле районнардан килделәр, ике авырлык категориясендә көрәштеләр. Ә кагыйдәләр буенча «Аударыш»та 6 авырлык категориясе: 60, 70, 80, 90, 100 һәм 100+. Монда турнир гына булгач, ике авырлык категориясе ясадык. 15 кеше катнашты, бик матур көрәш күрсәттеләр. Бер сулышта диярлек үтте. Әлеге «Аударыш» ярышлары күп районнардагы Сабантуй бәйрәмнәренә дә үтеп керде инде. Без хәзер «Аударыш» буенча республика, дөнья, Россия чемпионаты үткәрәбез. Шуңа күрә ул көчәя һәм Сабантуе вакытында һичшиксез булачак. Халык хәтта, көрәшне ташлап, «Аударыш»ны карарга чаба. Ат болай да матур, үзенә тарта, ә аларга атланып, басып, егетләр дә көрәшә. Шуңа күрә, безнең егетләр бар, татарлар көчле! – дип горурланып сөйли Ф.Нәбиуллин.

– «Аударыш» хатын-кызлар арасында үтәме?

– Россиядә генә түгел, бөтен дөньяда иң беренче булып безнең Татарстанда үтте – татар кызлары көрәште. Казахлар да, кыргызлар да, үзбәкләр дә, башкортлар да, алтайлар да, саха да түгел, ә татар кызлары. Менә безнең хатын-кызларыбыз нинди!

Бәйрәмдә «Ат арбасында иң тиз йөртүче», «Иң матур бизәлгән арба» конкурслары, гадәти булмаган тизлектә кымыз эчү, өчпочмак ашау ярышлары, күргәзмәләр, кинологларның күрсәтмә чыгышлары, концерт һәм авыл хуҗалыгы ярминкәсе дә оештырылган иде.

Фәннүр Сәлахов Балтачтан «Карлыгач» исемле аты белән «Иң матур бизәлгән арба» бәйгесендә катнашу өчен килгән. «Өйдә тагын 2 атым бар, ләкин бәйгегә иң тыйнагы, тәртиплесе белән килдем. Бөтенесе дә бизәгәнне, тавышны яратмый, кеше янында пырдымсызлана башлыйлар», – диде ул. Чыннан да, «Карлыгач» – бик тәртипле, башын селкеп, һәрбер кунакны сәламләп торучы түбәтәйле ат.

«Аударыш»та инде 9 нчы ел, башланганнан бирле катнашабыз. Бөтенесе дә этинең, үземнең куллар белән кыш көне эштән кайткач ясадыгы: үзебез кистек, тектек. Кыш буена ясадык, дисәм дә була. Хезмәте күп инде. Мәсәлән, кыңгыраулалары кемнәрдә бар, шулардан сатып алдым. Бер кыңгыравы гына 4-5 мең тора. Ә арбасын машина урындыкларын агачка беркетеп ясадык. Кыскасы, атлар өчен үләбез инде без!» – дип, сөйләде Ф.Сәлахов.

Бәйрәм бәйгеләрдә җиңүчеләргә кубоклар, акчалата призлар тапшыру һәм лотерея билетларын уйнату белән төгәлләнде. Ләкин «иртәнге 5тә 160 чакрымлык дистанциягә чыгып китүче атлар бары тик төнлә генә кайтып җитәчәк», дип хәбәр итте оештыручылар.

Камилә БИЛАЛОВА.

Абдул ФАРХАН фотосы.

intertat.tatar.

Халыкның күңел тәсбихендәге асыл төймә

14 сентябрьдә 84 яшендә хастаханәдә Татарстанның халык артисты, күренекле татар җырчысы Флера Сөләйманова вафат булды. Аны җирләгәндә, бөек моң эпохасы китте, дип искә алдылар. Флера апа бөек моң иясенең соңгысы булды кебек.

Флёра Зыятдин кызы Сөләйманова 1939 елның 9 мартында Кама Тамагы районының Иске Барыш авылында туа. 1955 елда 16 яшендә Казанга килә, киез комбинатында эшли. М. Горький исемендәге мәдәният йортында эшләүче хорга йөри (хор җитәкчесе – Сара Садыйкова). Чирәм җирләргә баручы концерт бригадасы җитәкчесе, җырчы һәм баянчы Гани Вәлиев яшь Сөләйманованы үз коллективына ала. Ф.Сөләйманова 1966 елда Казанга әйләнеп кайта, 1971 елдан бирле ул Татар дәүләт филармониясе солисты. 1983 елда Татарстанның атказанган артисты исеменә лаек була. Моңлы тавышы белән элеккеге Советлар илендәге миллионлаган татарны гашыйк итеп өлгерсә дә, аңа фәкать 2006 елда гына Татарстанның халык артисты дәрәҗәсен бирүне урынлы дип таныйлар. Бу елның февраль аенда гына ул Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясенә дә лаек булды.

Татарстанның халык артисты Флера Сөләйманованы соңгы юлга озату мәрасиме җырчының үзе кебек затлы, пафоссыз һәм халык мәхәббәте белән сугарылган иде. Халык шулкадәр күп иде – Флера апаны соңгы юлга озатырга килүчеләр белән Мәрҗани мәчете ишегалды тулды.

Мәрҗани мәчете – шәһәребезнең йөзек кашы булса, Флера апа халкыбызның йөзек кашы иде. Флера Сөләйманова вафатына некролог та Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев имзасы белән чыкты.

Флера Сөләйманованың җәсәде Курган зиратында, күренекле сәнгатькәрләр аллеясында җирләнде.

Татарстан Язучылар берлеге һәм «Мәдәни җомга» газетасы редакциясе күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимнең бертуган абыйсы

Хәлимов Ингель Нәҗметдин улының

озакка сузылган авырудан соң 87 яшендә вафат булуы уңаеннан якыннарының һәм туганнарының кайгысын уртаклаша.

Армиягә барудан баш тартсаң...

Россиядә армиядә хезмәт итүдән баш тартучыларны гражданлыктан мәхрүм итәргә тәкъдим итәләр. Дәүләт Думасында шул закон проектын караячаклар. Документ Дума базасында чыкты.

Парламентарийларга документны Дәүләт Думасында КПРФ партиясе депутаты Михаил Матвеев тәкъдим итте. Гражданлыктан мәхрүм итү сәбәпләре арасында ашыгыч хезмәттән генә түгел, ә мобилизациядән баш тарту очраклары да атала. Документ кабул ителгән очракта җәза хәрби исәпкә куюо срогы чыкканнарга да яный.

Проектны әзерләүчеләр аңлатма язуында белдергәнчә, ул беренче чиратта Россия гражданлыгы алган чит ил кешеләренә юнәлтелгән, алар хәрби исәпкә басмый.

Искәртик, Дәүләт Думасына тугач та бирелгән гражданлыктан авыр җинаятьләр өчен мәхрүм итү турындагы закон проектын керттеләр, алар арасында армияне дискредитацияләү дә бар. Ләкин соңрак документны эшләүче дүрт сенаторның өчесе дә үз имзаларын алды. Хәзер Россиядә алынган гражданлыкка карата шундый ук закон гамәлдә.

tatar-inform.

● Мексикада кактустан Desserto органик күнен ясарга өйрәнгәннәр. Әлеге материал чыдамлы, сыгылмалы, сулый. Ул хайван тиресеннән иләнгән чын күнне һәм аның экологиягә зыян китерә торган синтетик аналогларын алыштырырга сәләтле.

● Һиндстанда пластик савыт-сабага алмаш уйлап тапканнар – шешәләрне бамбуктан ясарга өйрәнгәннәр. Экологик савыт халык күңеленә хуш килгән, туристлар күп йөри торган Сикким штатында тиз арада бамбук шешә җитештерүне җайлаганнар да.

● Дөньяда иң озын асылмалы күпер Швейцария тауларындагы Церматт һәм Грэхен авылларын тоташтыра. 494 метр озынлыктагы күпер җир өстеннән 85 метр биеклектә урнашкан.

● Кытайдагы Huangtengxia Tianmen – дөньяда иң биектә урнашкан күпер. 500 метр биеклектәге, 400 тонна йөккә чыдам күперне 12 айда төзү 32 миллион фунт стерлингка төшкән.

Минзәлә елгасы буендагы Кадрәк

Күптән түгел Минзәлә районының Кадрәк авылына галимнәр һәм Татарстанның төбәк тарихын өйрәнүчеләр җыелды. Кадрәк тугызьеллык мәктәбе бинасында Бөтендөнья татар конгрессының Төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты рәисе, Татарстан республикасы татар төбәкчеләре оешмасы рәисе, профессор Альберт Борһанов оештыруында «Минзәлә елгасы бассейнындагы татар авыллары тарихы һәм мәдәнияте, һәм Көнчыгыш Татарстанда этнотуризм һәм татар төбәген өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре» дигән темага фәнни-гамәли конференция булып үтте.

Минзәлә елгасы буена урнашкан бу яклар бай тарихка ия. XII гасырда ук бу җирләрдә Бөек Ефәк юлы узган, Көнчыгыш белән Көнбатыш арасын тоташтырып, сәүдә кәрваннары агылган. Юл Минзәлә елгасын аркылы кисеп үткән. Сәүдәгәрләр шул тирәдә туктап, су буйларындагы табигатьнең гүзәллегенә сокланып ял итә һәм ярминкә оештыра торган булган. Елганың исеме дә шуннан килеп чыккан булырга, тиеш, диләр бу якларда. «Мәнзәл» гарәпчәдә «тукталыш» дигән мәгънәне белдерә бит.

Урта Азиядәге Чагатай дәүләте әмире Аксак Тимер – Тамерлан 1391 нче елда Кондырча янында Туктамыш хан гаскәрләре белән алып барган көчле сугышлардан соң, чигенүчеләрне куып, Кура елгасын кичә, Үкәк каласына барып җитә һәм Туктамыш хан армиясен тулысынча тар-мар итә. Аксак Тимер 1395-1396 елларда тагын Алтын Урданың төп шәһәрләрен яндырып үтә. Идел елгасының сулъяк ярына чыгып, кабат Болгар ханлыгы җирләренә басып керә. Болгар шәһәре, Җукәтин, Кирмәнчек һ.б. талана, кырыла.

Бу хәлләрдән соң халык Кама аръягы төбәгендә, шулай ук бүгенге Минзәлә районы җирләрендә яшәргә курыккан. Әмма алар аны һәрвакыт үз җирләре дип белгән. 1552 елда Казан каласы яулап алынгач, 1600 нче еллар дәвамында Минзәлә төбәге дә Россия дәүләтенә кертелгән, бу якларга халык яңадан кире кайта, вотчина хокукына кәгазьләр ала башлаган. Алар патша Алексей Михайлович исеменә язган үтенеч кәгазьләре белән мөрәҗәгатьләрендә үзләрнең электән үк бу җирләр белән идарә итүләрен язган һәм бу төбәккә кабат күченергә фәрман алган. «Хәзер мондый документлар архивларда табыла башлады», – ди Кадрәк авылда туып-үскән әйдәман, Минзәлә районының төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе Нәкыйп Гафиятов.

Кама аръягы – авылларының үткәне вакыйгаларга бай булса да, тарихчылар һәм археологлар тарафыннан бик аз өйрәнелгән төбәкләрнең берсе. Профессор А.Борһанов белдергәнчә, төбәкне өйрәнүчеләр исә нәкъ менә тарихчы галимнәрнең игътибары җитмәгән район-авылларның тарихын барлый. Минзәлә төбәгенә тарихчы галимнәрнең игътибары җитмәсә дә, бу якларны тәҗрибәле археографлар өйрәнгән. Нәкыйп Гафиятов та эшне нәкъ менә археограф Сәет Вәхидиның 1929 елда Минзәлә ягы авылларына фәнни экспедиция белән килеп, өлкән яшьтәгеләрдән туплаган кызыклы мәгълүматларны тикшерүдән башлый. Археограф-галим йөргән 46 авыл арасында Кадрәк, Җәмәк, Юшады авыллары да бар. «Сәет Вахиди туплаган мәгълүматлар буенча Минзәлә өязендә күп татар авылларының XVII гасыр урталарыннан соң нигезләнүе, бу җирләргә Казан ягы авылларыннан, төрле сәбәпләр белән, татар халкының күченүе һәм аларның кайсы сословиедә булулары да күрсәтелә», – ди Н.Гафиятов.

Ул шулай ук С.Вахидиның хезмәтләрен дә кулланып, археограф Марсель Әхмәтҗановның алга таба татар авыллары тарихын тагын «бер баскычка» күтәрүен дә ассызыклап үтте. Галим шәҗәрәләр һәм авылларның тарихи мирасын җыеп, анализ ясаган. М.Әхмәтҗанов хезмәтләре нигезендә Казан тирәсендә дә Нугай Урдасы татарлары нәселләре, элитасы яшәгәнлекләре күп төрле шәҗәрәләр аша расланган.

Н.Гафиятовның тикшерүләре нәтиҗәсендә Идел-Урал төбәгендә Нугай Урдасы татарларының Меңнәр кабиләсе варислары компоненты зур урын биләве ачыкланган. Төбәкне өйрәнүче «Марсель ага Әхмәтҗановның шәҗәрә текстлары татар халкының Нугай Урдасы варислары булуын раслау өчен тулысынча җитәрлек», - дип язуын ассызыклап үтте.

Күченеп килгән Меңнәр нәселенең шәхесләре Минзәлә өязендә 1670-1690 елларда күп авылларга нигез сала. Шәех Маман улы Кадрәк үзенең ыруг-туганнары белән 2000 дисәтин җир алып, Минзәлә елгасы буена 1685 нче елларда Кадрәк исемле авыл төзи. Берничә елдан, Кадрәкнең улы Җәмәк, әтисе биләгән җирдә Минзәлә елгасының икенче ягында үз исемендә авылны нигезли. Төбәкче Н.Гыйниятов барлык җир документларында, милек язмаларында («владенный запись»), план һәм карталарда бу ике авыл бергә күрсәтелүенә игътибар иткән. Шушы рәвешле XVII гасыр азагында ике авыл Кадрәк һәм Җәмәк барлыкка килгән. Сословиеләре «ясаклы татар»лар булган.

XVIII гасыр башында Минзәлә өязендә татарларны чукындыру сәясәте көчәя. Халык, чукындырудан качып, бу өяздән башка җирләргә качып китә башлый. Төбәктә калучыларының кайберләре христиан диненә күчәргә мәҗбүр була. Кадрәк авылында да берничә кеше чукына.

«Кадрәк авылының рухи тормышына килгәндә, аларны өч төркемгә кертергә була: керәшен татарлары, исеме христиан, ләкин ислам диннен саклап, яшерен тотучылар, өченчеләре – ясаклы татарлар. Ул чорда патша законнары нигезендә, аларга бер авылда яшәү рөхсәт ителми. Авыл халкы җаен таба, нәсел җирләреннән китмичә, авылның бер очында керәшен татарлары, икенчесендә ясаклы татарлар урнашып, ике исемдә авылга бүленәләр. Беренчесе Түбән Кадрәк дип атала башлый, ул 1811 елда яшәүдән туктый. Аның халкы яңа төзелгән Урта Кадрәк һәм Кадрәк авылларына күченә. Берсе ясаклы татарлар авылы, икенчесен ясаклы иске-керәшен татарлары авылы булып китә», – дип сөйләде Нәкыйп әфәнде.

Ул бу уңайдан рус христиан миссионерлары башлыгы Ильминскийның 1870 елда Рус православие чиркәве башлыгы архимандридка язган хатыннан өзек тә китерде. Ул анда «Кадрәктә керәшен татарлары үз диннәрен-йолаларын тотмый, авылда хәтта 4 се мөселман дине әһеле булып, ислам динен яшереп халыкка таратала. Авыл халкы христан дине кушканнарны үтәми, алар «Керәшен-татар мәктәбе» ачуга катгый каршы килә», – дип зарланган.

Авыл халкы, төрле дин аермалары булса да, бер-берсенә ихтирам белән яшәгән. Кадрәктә мәчет төзергә рөхсәт булмый, ләкин авыл халкы чиркәүне дә төзергә ирек бирмәгән. Ахун Әбелмәгҗан Нәбиулла улы исә Җәмәк авылында Җәмигъ мәчете һәм мәдрәсә төзеткән. Җәмәк мәдрәсәсендә белем алган муллалар төбәк авыллары мәчетләрендә эшләгән. Нәсарилар да үз диндәшләре янына – чиркәүле авылга барган.

Кадрәк – бүген Татарстанның заманча яшәешле, мул тормышлы авылларның берсе. Биредә гомер итүче халык өчен барлык уңайлыклар да тудырылган. Тугызъеллык мәктәбе, мәдәният йорты, китапханә, фельдшер-акушерлык пункты, балалар бакчасы, ветеринария пункты, «Саулык» медицина дәвалау үзәге – кадрәклеләр хозурында. Эшчән авыл халкы мал асрап көн күрсә, крәстиян-фермер хуҗалыкларында, «Минзәлә таңнары» агрофирмасы» җаваплыгы чикләнгән җәмгыятендә кырчылык, ит-сөт терлекчелеге белән шөгыльләнә. Кызганычка, заман чире – яшьләрнең авылдан китүе кебек хәл Кадрәкне дә читләтеп үтмәгән. Яшьләрне 50 чакрымдагы Чаллы үзенә тарта, шул ук чаллылылар авылда дача итеп тотыла торган йортлар төзүне арттыра, ә төпләнеп яшәүчеләр саны кими бара. Хәзер биредә 125 кенә шәхси хуҗалык бар. Кайчандыр шаулап-гөрләп торган, алдынгылыгы белән дан тоткан күмәк хуҗалык хисабына (Татарстанда андый мәктәпләр икәү генә икән) аның булдыклы рәисе Касыйм Гафиятов 1967 нче елда салдырган салдырган иркен, белем алу өчен барлык уңайлыклары булган мәктәптә дә балалар саны сирәгәя бара. Хәзер биредә биш авылдан килеп укучы 34 бала белем ала. Әмма авылны яшәртү, егет-кызларны туган якларында төпләндерү, аларны әби-бабаларының үткәннәре белән таныштыру ниятеннән эшләр алып барыла. Кадрәк авыл җирлеге рәисе Хәлил Нәбиуллин искәрткәнчә, авыл тарихы музеен төзү буенча да эшне башлап җибәргәннәр. Анда авылны нигезләгәннән алып бүгенге көнгә кадәр тарих яктыртылачак. Елга буендагы уңайлы урында «Кадрәк» спорт-сәламәтләндерү комплексын да төзи башлаганнар, юлларны яхшырталар, фестивальләр үткәрәләр, дини һәм милли бәйрәмнәрне бергәләп оештыралар. Фәнни-гамәли конференция уздырылганнан икенче көнендә дә, авылның нигезләнүенә 350 ел тулуга багышлап, Сабан туе мәйданында «Кадрәк дусларын җыя» дигән зур бәйрәм үткәрелде. «Кадрәк моңнары» җыр фестивале проекты кысаларында үткәрелгән әлеге чарага Татарстан һәм Башкортстан районнарыннан килгән фольклор коллективлары катнашты, авыл тарихын, борынгы йола, гореф-гадәтләрне искә төшерде. Мәйданда төрле кызыклы спорт уеннары да оештырганнар иде. Татар атлары да халыкның күңелен җилкетеп алды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

Мәдәни җомга
22 сентябрь
№37, 2023

«Тик син, тормыш, җырлап кал, яме!»

(Күренекле шагыйрә Нурия Измайлованы юксыну)

Иртәнге якта телефон чылтыравы ук хәвефле ишетелде. Шагыйрә, галимә Лилия Сәгыйдуллина шалтырата икән. «Нурия апа вафат», – ди. Тын алалмый тордым. Нурия... Гомердәш... Аңа карата нәкъ шул сүзне әйтер идем. Алты ел гомер – эштә һәм яшәүдә бергә, аннан соң соңгы көннәргәчә аралашып тору, сирәк булса да күрешүләр... Нурия Измайлова, аның шәхсияте һәм иҗаты турында китаплар да басылыр, чөнки милләтебезнең онытылырлык кызы түгел, халкыбыз хәтерендә сакланырга лаек. Әлеге язмам – аның рухына бер кәлимә сагышлану, аның турында шәрехләү...

УФАДА

Нурия Халит кызы Измайлова 1949 елның 20 июнендә Башкортстанның Благовар районы Иске Күчәрбай авылында дөньяга килә, рәсми туган көне – 1950 елның 1 гыйнвары. Вафаты – быелның 1 июле, АКШның Принстон шәһәре.

Шаран районының Базгыя урта мәктәбен, 1971 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. «Очарга, күчәргә җиеныр мәлләрем», – дип, дәрвишлек шаукымында Үзбәкстанның Фирганә өлкәсенә чыгып китә, укытучы булып эшләп ала. 1972-1978 елларны ул Уфада үткәрде, без бергә эшләдек һәм яшәдек.

Башкортстан китап нәшрияты (хәзер Зәйнәп Биишева исемендәге «Китап» нәшрияты) Уфаның үзәгендә – Совет мәйданындагы Сәнәгать йортында иде. Нәшрият директоры вазыйфасын Нурислам Нуртдинов башкарган вакыт. Ул нәшриятка иң озайлы чор – ике дистә еллап җитәкчелек итте, коллективта аны күпләр ихлас хөрмәтләде. Китапны дөньяга чыгаруга әзерләү басылып эшләүне, бар булмышың белән кульязмага «чумуны» таләп итә, шуңадыр да нәшриятта эш ярларыннан артык ташымый, тотрыклы бер үзәндә агыла. Хезмәткәрләр сыналган, бер тупламга укмашкан, очраклы килеп кергәннәр монда берекми дә. Менә шул «тын елга»га ашкынулы, саф дулкын булып килеп кушылды Нурия. Ул чакта мин Башкорт дәүләт университетының кичке бүлектә тарих факультетында укып йөрим, нәшриятның дәреслекләр һәм уку әсбаплары редакциясендә кече мөхәррир буларак хезмәттәмен. Нурия исә – югары белемле, мәктәптә дә эшләп өлгергән, аны шунда ук башкорт мәктәпләре өчен урыс теле һәм әдәбияты дәреслекләрен нәшерләүче мөхәррир итеп тәгаенләп куйдылар. Икәү иңгә-иң терәлешеп, тоташкан өстәлләр артына утырып эшлибез шулай.

Нурия урыс теле һәм әдәбияты буенча махсуслашкан коллегасы, тәҗрибәле мөхәррир, нәшрият ветераны Тамара Яркунова белән дә, дәреслекләрнең авторлары – педагогия фәннәре докторлары, профессорлар Кәбир Закирҗанов һәм Лена Сәяхова белән дә уртак тел табып, җайлы эшләп китте. Бу олпат затлар Нурияне – үзләренә, яшьлегенә карамыйча, Нурия аларны үзенә тиң күрде шикелле. Гомумән, аңарда абруйлар каршында каушап калу, дәрәҗәләргә табыну сыйфаты юк иде. Җитмәсә, гыйлем багажы да саллы, тәпченүчән, сүзнең асылын аңлаучан, сүз кадерен белүчән.

Ул чакларда нәшриятта бер редакциядә чыккан яңа басмаларны икенче редакция мөхәррирләренә анализларга биреп, бәяләмәне күмәк җыелышларда тыңлау гадәте бар иде. Дуска да, дошманга да сүзен чәчрәтеп әйтүчән Нурия мондый очракларда да хәтер саклап та тормый, фикерен ярып сала. Киңкүләм сәяси әдәбият редакциясе мөдире, танылган шагыйрь Роберт Пальның мөхәррирлегендә чыккан бер китапны җентекләп укып, мантыйклы тәнкыйть җиткерүенә күпләрнең шаккатып калганы да истә. Усаллану, фикерләр төрлелеген ачуланышуга сәбәп итү түгел бу, «мин беләм»лекне күрсәтү дә түгел, ә яхшыртырга омтылып тәнкыйтьләү иде.

Каләм әһеле буларак, Нуриянең исеме дә укучыларга шактый танылган иде инде. Җыры да бар хәтта: «Соңгы хат» дип атала. Беренче шигырьләре тугызынчы сыйныфта укыганда ук «Кызыл таң» гәзитендә басылып чыккан. Әле дә шигырь белән «җенләнә». Мохит тә кулай кебек: нәшриятта әдипләр Әмир Гәрәев, Габдулла Байбурин, Агиш Гыйрфанов, Равил Шаммас, Хөрмәт Биккулов, Ирек Кинҗәбулатов, Риф Мифтахов, Рәшит Сабитов һ.б. эшли. Буш вакытларда – аралашу, иҗат хакында әңгәмә, бәхәсләр. Иҗатчылар яңа әсәрләрен ишеттерә, Риф Мифтахов еш кына Мостай Кәрим шигырьләрен яттан сөйләп, тәзелешенә, эчтәлегенә анализ да ясап куя. Нурия дә укыштыра шигырьләрен. Ул сөйли башласа, яндагылар аеруча җанланып китә.

Килеш-килбәте белән дә сөйкемле, җәлеп итүчән иде ул: чибәр йөз, зифа буйсын, кыю караш, гәүдәсен серле яшереп торган куе, озын чәчләр, өстәвенә, үткер һәм җор тел! Ә җырлап җибәрсәме?! Чиксез дәрья – Иделсу хакында моңлана һәм моңландыра иде ул, яратып, еш башкарыр җыры «Су буйлап» булды.

Нәшриятта ул елларда хезмәткәрләр каләм тотып, кульязмаларга текәлеп кенә утырмый иде. Квартал планы «яна» башласа, оран ташлана: полиграфкомбинатка! Басмаханәгә барып, гадирәк станоклар артына басабыз, китап төрәбез, төрле эшкә кушылабыз. Җәй җитсә – хәзер тарихта калган мәшәкать: колхозларга яфраказык әзерләргә китәбез. Күңел өчен ялга юлланган чаклар да була: ничек рәхсәт алынгандыр, шофер Кәшфулла абый Рәхмәтуллинның йөк машинасының аралап әйләндерелгән әрҗәсенә төялешеп, табигать кочагына, сәйранга чыгабыз, мәтрүшкә, җиләк җыярга барабыз. Анда инде хөррият: җырлар, шигырь сөйләү, такмак әйтешүләр тынып та тормый.

Җиләк җыюда исә Нуриядән уздыра алганнар юк: күз ачып йомганчы чиләге тулган була, кып-кызыл, мөлдерәп кенә пешкәннәрен тапкан үзе! Рәтсез эшне бер дә яратмады Нурия, әштер-өштерне сөймәде.

«Ак хыялның гади чынбарлыкка
Ашар-ашмас чагын сагынам», –

дип язган кебек, ниятләрдә – ымсындыргыч офыкларга, гамәлләрдә камиллеккә бәгланды.

Шигырьләрен камилләштерүдә ул остазы санаган, Базгыяда туып-үскән күренекле язучы, тәрҗемәче Йосыф Гәрәйнең ярдәменә таянгандыр, мөгаен. Аларга еш кына баргалап та йөрде Уфада чакта.

Китап буларак, Нуриянең шигырьләр шәлкеме бер үк вакытта – 1977 елда Башкортстанда «Йәш көстәр» тупланмасында, Татарстанда «Кызлар җыры» җыентыгында дөнья күрде. Басмаларда – ике республикадан чордашлары, булачак сүз осталары Салават Рәхмәтулла, Тамара Ганиева, Зөһрә Котлыгилдина, Лена Шагыйрьҗан, Халисә Мөдәрисова, Нәҗибә Әминева һ. б. Нуриянең шигырьләре беренче китапта – 4, икенчесендә – 10, алар кабатланмый. Чәчәкле-чуклы түгел әсәрләре, шул чакта ук автор аларга мәгънәви орлык сала белгән, укучыга уйланырга, гамьләнергә киңлек, җирлек булдырган.

Холыкларда төрлечәрәк булсак та, бер-беребезгә самими тартылганбыздыр, күрәсең, караватка утырышып алгач, шигырьләрен еш кына миңа аулакта укый иде ул. Матбугат хезмәткәрләренең К.Маркс урамындагы, Үзәк универмагка якын тулай торагында Дүртөйле районыннан бер галимнең туганы, «Башкортостан» нәшриятының реклама бүлегендә хезмәттәге Динара Хәбибова белән мин – бер бүлмәдәбез. Нурия, башка бүлмәдә яшәсә дә, һәрдаим өчебез бергәбез. Азыкны күмәкләшеп алабыз, чиратлап әзерлибез. Берчак кибеттә булгач, Нурия: «Нишләп кәкре кыяр күтәреп кайттың?» – дип оялткан да иде. Үзе тормышны ярыйсы күргән, әчесен дә татыган, сабаклар да алган шул:

«Кагылган чаклар да истә,
Һәм сугылган чаклар да».

Ә минем әле яшьлекнең ал манзарасында кыяр формасына исем китмәгәндер, күрәсең...

Соңрак «Совет Башкортостаны» гәзите журналисты Факил Морзакаев белән гаилә коргач, комендант тулай торакта сабый белән тотмаячагын алдан ук катгый кисәтеп куйды. Дүрт бүлмәле (ике бүлмә бикле, анда хуҗалар мөлкәте) фатирга күченеп, янә Нурия белән бергә яшәдек. «Кияү» дип өзелеп торды Факилгә, улыбыз Камил тугач, мин өзлегеп дәваханәдә ятканда апасыдай курчаклады аны.

– Кырык көн карадым иреңне, – дип шаяртыр иде азак.

Нуриянең җырлары бик күп тә түгел, әмма һәркайсысы тойгыларга бай, образлы, тыңлаучыны хисләр коенына чолгый. Иң таралган җыры – Россиянең, Башкортстанның, Татарстанның халык артистлары Фидан Гафаров, Нурия Ирсаева кебек сәхнә йолдызлары да, халык талантлары да тәэсирле башкарганы – «Адаштым». 2000 елда Казанда чыккан, «Адашкан» дип аталган китабында, тупламаның хикмәтле ачкычы кебек, беренче куелган ул әсәр:

«Ашыгулар ялгышуга була,
Юк шул минем сабыр канатым...
Күңелең – серле урман,
мәхәббәтем – буран, –
Җырлый-җырлый кереп адаштым...»

Нәкъ шулай, ашкынулы-җилкенүле булды Нуриянең ил пәйтәхете Мәскәүгә китүе дә...

МӘСКӘҮДӘ

Мәскәү күз яшьләренә ышанмый, диләр. Хәер, кияүгә чыгып, ире белән башкалага күченгән Нурия елаклардан түгел иде. Мәскәүдә яшәгән 1979-1996 елларда күп нәрсәләр үткәндер башыннан.

Әмма бер шигырендә:

«Кояш чыга! Сикереп торам!
Йөгереп торам, биеп торам...
Мин һәр көнне бу дөньяда
Яңа төшкән килен сыман», –

дип язганынча, язын оя җыйган кош кебек, яңа дөньясын дәртләнеп җайлый башлады ул. Фатир алдылар, уллары Искәндәр белән Солтан туды.

Әнилек ләззәтенә кинәнеп: «Һәм рәхәт, һәм кыен, ләкин тормыш гүзәл, халәтем – 18 яшьлек!» – дип язды бер хатында. Бала тугач, ата-ана өчен «Һаваның һәр күзәнәге бәхет белән тула», – дип, ана һәм бала хакында фәлсәфи табышлы, образлы әсәрләр иҗат итте.

Ул үзе башкалада «Педагогика» нәшриятына корректор булып эшкә керде. Безнең нәшрияттагы хезмәтен чагыштырып: «Редактор булып интеккәнмен икән, корректорга рәхәт: баш ватасы, нервничать итәсе түгел», – дип нәтиҗә дә ясады. Искәндәрен яслегә урнаштыргач, балага үзе күз-колак булыр өчен аның төркеменә тәрбияче булып алынды.

(Дәвамы киләсе санда).

Динә МОРЗАКАЕВА.

Туктатып тор әле сәгатьләрне, Тоймыйк әле вакыт үткәнен...

Данис ХӘЙРУЛЛИН

ЭЗЛӘҮ

Вакытны елларга бүлгәләп
Эзләдем – тапмадым, тапмам да:
Вакытның юклыгын аңладым
Ватылган сәгатьне такканда.

Бу дөнья яртылаш яралган,
Анысы да бетәргә каралган...
Исәннәр-исәрләр, сез кемнәр?
Мәгънәсез мәгънәләр таралган.

Карамы, акмы ул каргалып
Күләгә сарылган ил-чәчәк?
Тилмереп көткәннәр киткәннәр,
Ташларга уелган киләчәк...

Яңага хирыслык яңара,
Искәрми вакытның юклыгын.
Исәннәр исәрләр, сез кемнәр?
Шөбһәле таңнардан бер сыгым...

Эзләдем, тапмадым, дисәм дә,
Вакытка ишек бар. Кер анда!
Һәр аять – бер ишек, keралсаң
Табарсың үзеңне Коръәндә.

ГАҖИЗЛЕК

Көннәр узмый, төннәр онытылды –
Дөрес яшәдемме мин элек?!
Кояш та юк, караңгы да төшми.
Ак томанда очкан кош кебек
Күтәреләм
Күккә, бик биеккә,
Күкләрдән дә бераз югары.
Газиз җаным бушанырга гаҗиз –
Бушлыкларда кала югалып.
Ә барыбер күтәрелә барам,
Керим әле диеп чүт кенә
Галәмнәрнең якынайган саен
Ерагая барган читенә.

Көннәр узмый, төннәр онытылды,
Дөрес яшәдемме мин элек?!
Җиргә төшәм, мин яшәргә разый
Җитмеш җиңеп, җитмеш җиңелеп.

АКЫЛ

I
Күпме акыл җилгә очкан,
Җыелганы күпме?!
Һаман тишмәкчебез әле
Бармак төртеп күкне.

Өсте-өсте өстәр кеше
Сүз өстенә сүзләр.
Акыл өстендә таптанып,
Мәңге акыл эзләр.

II
Акыл җыйдым, акыл бирәм,
Кемгә кирәк акыл?
Сакалымнан сыйпый-сыйпый
Теләделәр ак юл...

СОҢГЫ ШИГЫРЬ

Ничәнче ел?
Бу ничәнче гасыр? –
Әйтә алмас кем дә төгәл генә.
Мәгънәләрен җуя икән вакыт,
Чиксезлеккә таба төбәл генә.

Кара гына күккә йә аскарак,
Бераз гына аска... гүрне узып...
Гомер, имеш...
Күкне җиргә ялгый
Маңгаемнан узган пар-пар сызык.

«Һиҗри», – диләр, бусы – безнең тәкъвим,
Кемдер әйтә: «Юлиан календаре».
Исбатламак була адәмиләр
Булмаганны – юк вакытның барын.

Вакыт юк ла! (Булса бетәр иде...)
Кояш, җир, ай, без бар әле менә.
Елың ни дә аңа, гасырың ни? –
Койрыклы йолдыз әле генә
Узып китте җирнең сыртын ертып,
Үрсәләнеп калды ять-яшь вулкан.
«Магма», – диләр... Кешенеке белән
Бер тамырдан ласа минем бу кан!

Узып китте галәм хәбәрчесе,
Карт тауларның ап-ак башын тарап.
Ул таныды, ул таныды мине,
Миллион еллык күзләремә карап.

Гасыр, имеш...
Меңъеллыклар, имеш...
Юк ул вакыт! Булса бетәр иде...
Һичьюгында соңгы шигыремне
Язып бетергәнне көтәр иде.

ЧАГЫЛЫШ

Чагылып кына ала дөнья бездә,
Дөнья бездә уйнап кына ала.
Уйнап кына безне утка сала,
Уйламаган чакта туктап кала.

Яшәп карыйбыз без уйламый да,
Тынлык та бар бездә, цунами да –
Бер сүзгә дә сыгылып төшәбез без,
Исән калган чакта суламый да.

Чагылып кына ала дөнья бездә,
Без дә анда чагылып киткәлибез.
Без – дөньядан, дөнья бездән туйса,
Ватык көзгеләргә үпкәлибез.

Яшерегез көзгене һәм сүзне,
Күрсәтмәсен көзге безнең көзне!

СҮЗ

Син дәшәсең, сиңа эндәшәләр,
Сүз өстенә сүзләр өелә.
Үз көенә генә яши кемдер,
Кемдер яши сүзләр көенә.

Калебенә язылганны гына
Каләменә элә шагыйрьләр.
Шәп апалар сүзсез яши алмас,
Сүзсез яши белер шәп ирләр.

Сүзләр, дәхи, көн белән төн кебек,
Каралары була, аклары.
Әкиятләрдә генә буладыр ул –
Нахакларны җиңә хаклары.

Гомер бакый адәм балалары
Сүзләр ятьмәсеннән сөзелә.
Бу дөньялар сүздән башлангандыр
Һәм бетәр дә сыман сүз белән...

БЕР СӨЙЛӘШИК ӘЛЕ..

Тел бар әле, ярый тел бар әле,
Очраштыкмы, телгә салынабыз.
Аерылышкач, үзебездән бигрәк,
Сүзебезнең тәмен сагынабыз.

Сөйләп калыйк, энем, сүз боткасы
Майсыз булса да ул җәйсыз түгел.
Кояшыбыз бераз сүрелсә дә,
Төннәребез әле айсыз түгел.

Сөйлә әйдә, сүзе коелганда,
Тегермәнен телнең тартып калыйк.
Вакыт бит ул вакытлыча гына,
Без вакыттан чүт-чүт артып калыйк.

Син баерак, мин саерак инде –
Тамгалары йөзебезгә чыккан...
Тәңкәләр ул тәңгәлләшер әле,
Гөлләр үскәч өскә йә кычыткан...
Баерак булсаң әйбәтрәк инде,
Гайбәтләрең йөзә тел маенда.
Ярлы булу язык түгел ләса,
Ярлы һәрчак җилләр уңаенда.

Йә ярый ла, бер чигелеш бусы,
Читтән карау гына читкә китеп.
Тел бар әле, шөкер – иң зур байлык,
Бер сөйләшик, энем, матур итеп.

ӘВЕРЕЛЕШ

Оеп утырам чирәмдә,
Чирәмдә утырам оеп.
Үсеп утырам чирәмдәй,
Кояшка битемне куеп.

Уйнап оча күбәләкләр,
Күбәләкләр оча уйнап.
Җаным оча – сыңар канат
Күбәләк булырга уйлап.

Яфрак ярып яз мәлендә,
Күз мәлендә яфрак коеп,
Үсеп утырам чирәмдә,
Кояшка битемне куеп.

ТУГАН ТЕЛЕМ

Сүз-чәчәкләр...
Такыялар үрәм,
Кочак-кочак күккә чөямен.
Туган телдән чәчәк исе килә,
Чәчәкләрне өзелеп сөямен.

Сүз-яшеннәр...
Сөя-сөйми, сөя,
Ялкынында һаман көямен.
Хәтеремдә сулган нәркисләрнең
Таҗын саный-саный сөямен.

Сүз-сөңгеләр...
Юньсез... Сөмсез... Комсыз...
Җанызгыза угы тияме?
Тисен әйдә, тисен – туган телне
Үткерлеге өчен сөямен.

Яшенлеме, сөңгелеме булсын,
Газиз телкәй тота ил ямен.
Туган телдән чәчәк исе килә,
Чәчәкләрне өзелеп сөямен.

ИШЕК...

«...Үлем ишеге ачык, һәм аңа һәркем керәчәк». Казанда күл башында Әс-каф чиркәве янында икегә сынган таштагы язу.
Шиһабетдин Мәрҗани
китабыннан

Керәчәк!
Кермәскә тырышып,
Никадәр гомергә ябышма.
Керәчәк!
Туу да, үлем дә –
Җавапсыз мәңгелек табышмак.

Керәчәк!
Шул инде күрәчәк:
Динле дә, денсез дә, бөек тә.
Бары тик аннары аерым
Ашсынга юлың
Йә
Биеккә!

Керәчәк!
Ташларны ярсаң да,
Хөрләрне сөрсәң дә сөргенгә.
Сыяр да бетәчәк гомерең
Шәмнәрең пыскыган бер төнгә!

КЫЙБЛА

Ни буласын алда кемнәр белә,
Кемнәр белә алда ни буласын?
Белмәсә дә, киләчәккә карап
Билгели гел кеше кыйбласын.

Йортын сала.
Машинасын ала.
Бакчасында алма коя агач.
Дөньясы гел җырлап кына бара
Хәләл көчен түгеп баеп алгач.

Җан сөйгәне көлеп кенә тора,
Тәгәрәшеп үсә сабыйлары.
Шәп әйләнә бәхет тәгәрмәче,
Тик җиткерми генә алып барып.

Йә бер чатта очып төшә кеше,
Йә... бөтенләй утырмаган була.
Кан тәкереп уза киләчәккә,
Кара ютәленә буыла-буыла.

Ничә тапкыр күккә ашып карый,
Керми генә нинди кыяфәткә –
Оҗмах бакчасы дип баскан җирдән
Убыла да төшә кыяматкә.

Алла белә алда ни буласын.
Үтә тора дәрвишәнә гомер:
Таланган йорт... Гөле көйгән бакча...
Учакларда сүнәр-сүнмәс күмер...

* * *

Бөтен дөнья тоташ томан гына,
Сәер халәт бүген, үскәнем.
Туктатып тор әле сәгатьләрне,
Тоймыйк әле вакыт үткәнен.

Әйләнмәсен җир дә, әл-хәл алсын,
Сизмәсен дә кояш кызуын.
Картаймыйча яшәп карыйк әле,
Адаштырып гомер узуын.

Яшәрмичә яшәп карыйк әле,
Эшләреңнең бүген куй барын!
Томаннарга карап югалганда,
Томанланып китә уйларым.

Чаллы.

ИСХАКЫЙ

Гаяз Исхакый «Зиндан»ның хатимә өлешендә, Чистай хәбесханәсендә утырган чакта, төрмә хакындагы фикерләрен белдереп, болай ди:

«Төрмәгә ябылган вак-төяк караклар, төрмәдәге зур караклардан өйрәнеп, аларның әллә никадәр дәресләрен тыңлап, чын карак булып чыга. Болар төрмәдән чыкканның икенче көнендә үк тагын урларга тотыналар. Төрмәдән курку боларны бер эштән дә тыя алмый. Сәясиләрнең йомшаграклары иптәшләрен күреп үзләрен тотарга өйрәнә, төрмәнең начальствосы берлән тартыша-тартыша табигатьләре ныгый, куркулары кими, аларның наданраклары әллә никадәр нәрсә укыйлар. Әллә никадәр сүз ишетәләр. Моңынча кадәр кеше әйтмештән генә с.р. яисә с.д. булып йөргән кешеләр чынлап партия кешесе булып чыга. Төрмәдә вакытның йокыдан калганы бар да буш булганга, төрлесе төрле фән берлә мәшгуль булып, әллә никадәр мәгълүматларын арттыралар, төрмә боларга бертөрле мәктәп була!»

Исхакый үзе «бертөрле мәктәп була» дип атаган төрмә темасы башка әдипләргә дә мәхбүсләр язмышын яктырту өчен бер этәргеч булды. Мәсәлән, М.Гафуриның 1906 елда язылган «Фидаи мәхбүс агызыннан» дип исемләнгән шигыре Исхакыйның «Зиндан»ындагы иҗтимагый-шәхси мотивларга аваздаш булуы белән аерылып тора:

Хөр улмай йөргәнемнән
үлгән артык,
Үземне кара йиргә
күмгән артык...

Хокуксыз тормакы бу
милләтемнең
Бәнем чөн михнәте
зинданнан артык...

Бу форсатлар ике килмәс
гомердә,
Атып калган ятып калганнан
артык.

Хөррият өчен, милләт вә шәхес азатлыгы өчен шәһит китү һәм шуны иң бөек гамәл итеп тану мотивлары Й.Акчураның төрмә көндәлеге рәвешендә язылган «Мәүкуфият хатирәләре» («Тоткынлык хатирәләре») дигән повестенда (1907), Г.Тукайның «Мәхбүс» шигырендә (1907), С.Сүнчәләйнең «Шильон мәхбүсе» шигырендә (1910), Н.Думавиның 1911 ел эчендә язылган «Мәңгелек мәхбүс», «Мәхбүс», «Мәхбүс дустыма», «Себер төрмәсендә» дигән шигырьләр бәйләмендә, Г.Газизнең «Олуг ләгънәт» хикәясендә (1912), З.Шаһгәрәевнең Буби мәдрәсәсендәге фаҗигале хәлләрне дә читләтеп үтмәгән «Төрмәләр хатирәсе» исемле әдәби-документаль повестенда (1913), Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романының беренче вариантында (1914) тәгәл чагыла, һәм бу әсәрләр киң җәмәгатьчелеккә резонанс уята. Әлеге әдипләрнең әсәрләрен патша хакимиятенең җәза органнарында хөкем сөргән яман тәртипләрне һәм вәхшилекләрне фаш итү рухы берләштерә. Шуның белән бергә, Г.Исхакыйның «Зиндан» әсәрендә чагылган гыйсъянчылык рухының да аларга ят булмавын искәртеп узасы килә.

Биредә шул хакта да әйтергә кирәк: совет чорында яшәгән татар әдәбияты өчен «төрмә» темасы, «мәхбүс» мәсьәләсе озак еллар буена ябык булды. Шул сәбәпле азатлык, хөррият өчен көрәшүче милләтпәрвәрләрне мәхбүсләр хәлендә тоткан инкыйраз көчләрен берләштерүче тоталитар система хакимияте кылган җинаятьләрне фаш итү темасына әдәби әсәрләр бераз соңрак, сиксәненче-туксанынчы елларда гына иҗат ителә башлады. Шундый эчтәлектәге әсәрләр җөмләсендә, мәсәлән, И.Салаховның «Колыма хикәяләре» роман-хроникасын (1989), А. Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!» роман-хатирәсен (1991-1993), Л.Бадыйкшанның «Мөртәт» романын (1994), Г.Тавлинның «Афәт» роман-трилогиясен (1990-1995), Р.Кәраминең «Каргышлы этаплар» романын (1995) атарга була. Әлеге әсәрләр сәяси мәхбүсләрне юк итүнең патша хакимиятенә караганда да нечкәрәк ысулларын тудырган коммунистик режимның халыкларга карата эшләгән авыр җинаятен фаш итү рухы белән сугарылган. Җан тетрәткеч эпизодларга, дәһшәтле мисалларга һәм куркыныч саннарга бай булган бу кырыс әсәрләр аша идеологиясе шәхес ireгән чикләүгә һәм кеше хокукын тупас рәвештә бозуга корылган системаның канлы йөзе яхшы күренеп тора, милләтләрне инкыйразга этәргән гамәлләре күзгә бәрелеп тора.

Бу нисбәттән И.Салаховның «Колыма хикәяләре» роман-хроникасына киңрәк тукталасы килә. Чөнки анда Г.Исхакыйның «Зиндан» әсәре белән чагыштырырлык детальләр һәм күренешләр шактый.

«Колыма хикәяләре» роман-хроникасы – илебезне бөлгенлеккә төшергән һәм хурлыкка калдырган рәхимсез шәхес культы гаепләүче һәм аңа карата иң гадел хөкем карарын чыгаручы әсәрләрнең берсе. Сагыш һәм әрнү белән сугарылган рухы белән ул атаклы шагыйребез Хәсән ага Туфанның лагерь чоры иҗаты белән тиңләшә ала.

Шул ук вакытта Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» роман-хроникасы шәхес культы чорының гаделсезлекләрен фаш итү белән генә дә чикләнеп калмый, культ идеалының бүгенге, безнең чордагы рецидивларын да искәртеп куя, шул явызлыкларны тудырган бюрократик-административ системаның халыкка каршы эшләгән җинаятен ачып сала.

Роман-хроника – кырыс реалистик рухы белән культ идеалын җимергән әсәрләрнең берсе. Әдип ил һәм халык язмышының фаҗигале көннәрен тасвирлый, шул әрнү-газапларның сәбәпчесе булган шәхес культының килеп чыгуын аңларга омтыла. И.Салахов әсәрендә шунысы гаҗәпләндерә һәм сокландыра: ул үзен имгәтүче, аяксыз калдыручы төрмә сакчылары, тикшерүчеләр, лагерь башлыклары турында ачынып язганда да, алар кылган яманлыкларны тасвирлаганда да аек акыл тезгенен кулында тота. Ул чын мәгънәсендәге дөреслекне тудырырга тырыша һәм үз максатына ирешә дә. Роман-хрониканың һәр битеннән кан һәм ачы яшь белән сугарылган кырыс чынбарлык, шул чорның әрнү-тетрәнүләре бөркелеп тора. Без, торгынлык идеологиясенең зыянын татыган яшьләр, шундый фаҗигале чынбарлык белән күзгә-күз очрашкач, бермәлгә югалып та калдык. Шул дәвергә рәнҗүе төшкәнлектән буяуларны бераз куертып җибәрмимме икән дигән шөбһәле уйлар туарга өлгерми, әдипнең кешелеклелеге һәм үз җәлладларының вәхшилекләрен тасвирлагандагы объективлыгы күңелдә шундук башка тойгыларны уята, аңа булган хөрмәт хисләре арта.

Вакытында Галимҗан Ибраһимов белән бәйләнеш тотканы өчен генә кулга алынган һәм дәһшәтле концлагерьлар аша үткән шәхеснең үзен газаплаган системага дәгъва белдерүе дә акланыр иде. Кеше буларак, без ул тойгыны да дөрес аңлар идек, элеккеге сәяси мәхбүснең әрнүләрен йөрәгебез аша кичерер идек. Әмма Г.Исхакый кебек чын гуманист булган И.Салахов, авыр язмыш сынауларын җиңә алган нык иманлы кеше, андый юлдан китми. Үзен интектергән бәндәләр дәрәҗәсенә төшми. Кимсетелүенең ачы газапларын йөрәге аша кичергән әдип сталинчыларның сәяси җинаятен ача, алар кулындагы һәртөрле «алиби»ны юкка чыгара. «Социализм җиңә барган саен аның дошманнары да күбәя бара» дигән теоретик карашның мәгънәсезлеге, аек акыл кысаларына берничек тә сыймавы роман-хроника битләрендә яхшы ачыла. Ул чордагы кулга алуларны, очраган бер кешене төрмәгә тыгуларны әле һаман аңлап бетереп булмый. Хәтта укый-яза белмәгән, катлаулы сәяси интригаларга катнашмаган чегәннәрне дә политик сәбәп белән кулга алу әрнүле нәфрәт һәм тетрәнү хисе уята. Пләтән төрмәсенең юеш камераларында интеккән Гыйлем Камай, Кыям Абрамов, Шамил Усманов, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан, Сөббух Рафиков, Ләбиб Гыйльми, Мохтар Мутиннарның фаҗигасе хакындагы юлларны укыганда, шул чорның бу дәһшәтле күренешләре шундый сорау куярга нигез бирә: намуслы затларга яла ягуның шуннан да акылсызрак формасы белән кешелек тарихының әлегә кадәр очрашканы булган иде микән?

58 нче статья буенча хөкем ителгән сәяси мәхбүсләрне изүнең, мыскыл итүнең тупас системасын эшләгән Берия ведомствосындагы башбаштаклыкларга, вәхшилекләргә күңел ышанырлык түгел. Әмма конвойчылар тарафыннан кыр казлары дип мәсхәрәләнгән гарип тоткыннарга – сукырларга, саңгырауларга, аяк-кулсызларга карата кешелексез, хайвани мөнәсәбәт әлеге канлы системаның йөзендәге битлекне шундук салдырып ташлый. Ул чорда фашист зинданнарындагы ерткычлар хакында шаулаган матбугат органнарының «принципиальлеге» нишләптер үзебездәге хәлләргә кагылмый...

«Алпан-тилпән килеп, үз аякларына үзләре сөртенеп, утынчылар уза. Төркемнең иң соңында ава-түнә килгән бер озын, ябык инвалид, вахта капкасына да җитә алмыйча, абынып егылды. Артта тартылып-уйнаклап килгән овчарка, бәе бушауга, бер генә сикереп, җирдә яткан теге утынчының өстенә ыргылды һәм талый башлады.

– Ха-ха! Ха-ха!

– Шайтан, әйдә каезла шул контрны!

– Ха-ха, хи-хи-хи! – Арттан килгән конвойчылар, туктап калып, бу тамашага карап көлә башлады».

Роман-хроника белән танышмаган кеше бу өзекне, һичшиксез, танылган язучы Нәби ага Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» дигән повестеннан алынган дияр. Әгәр әсәрне укымаган булсам, үзем дә шулай уйлар идем. Әмма, кызганычка каршы, конвойчылар явыз эсэсчылар түгел, бәлки Эшче-Крестьян Кызыл Армиясендә хисапланучы солдатлар. Тоткыннары исә – шулар тарафыннан гарипләнеп, имгәтелеп беткән кичәге сәламәт совет кешеләре. Лагерьларның урыны да Себер урманнарында, Колыма елгасы буенда. «Кем эшләми – шул ашамый» принцибын лагерь начальниклары әнә шулай тормышка ашыра.

Без бүгенге көндә дә әле меңнәрчә шәхес культы корбаннарының каберләрен генә дә белмибез. Сталин чорында сабый балаларны кулга алырга, җәзаларга һәм атарга рөхсәт иткән документлар булуын да әле күптән түгел генә белдек. Күз алдына да китерүе кыен булган вәхшилеккә шулай иҗтимагый төс бирүне бер буын да беркайчан да гафу итмәс...

Г.Исхакыйның «Зиндан» әсәрендәге төрмә темасы әнә шулай И.Салахов романы аша А.Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!» дигән роман-хатирәсе өчен дә җитди нигез булды. Һәрхәлдә, туксанынчы еллар башы татар әдәбиятына бу тема Г.Исхакыйның «Зиндан» исемле сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре җыентыгы басылып чыккач килеп керде.

«Йәгез, бер дога!» роман-хатирәсендәге вакыйгалар автор хикәяләвендә бирелә. Документаль төгәллек һәм тарихи дөреслек белән ныгытылган күренешләр, вакыйгалар, хәлләр, эпизодлар, фактлар әсәрнең тәэсир итү көченә куәт өстәсә, сәяси мәхбүс сыйфатында концлагерьда газап чиккән автор-геройның уй-кичерешләре, хыял-омтылышлары, әрнү-газаплары, гамәл-фигыльләре, мөнәсәбәт-карашлары яңа чынбарлыкның – «тоткынлык халәтенең» кырыс үзенчәлекләрен, кеше күзеннән бик әчкә яшерелгән нюансларын шактый төгәл күрсәтергә булыша. Роман-хатирәнең һәр битендә кан һәм яшь белән сугарылган фаҗигале чынбарлык, шул дәвернең әрнү-тетрәнүләре ярылып ята, төрмә сакчылары, лагерь башлыклары,



Гаяз Исхакый.

ДӘВАМЧЫЛАРЫ

●Ибраһим Салахов.



●Аяз Гыйләҗев.

тикшерүчеләр – тоталитар хакимиятнең нигез ташлары булган социаль группаның әхлакый портреты җете буяулар белән тасвирлана.

Аяз Гыйләҗев безнең татар әдәбиятында әле үзләштерелә генә башлаган «лагерь» темасын роман-хатирә аша ачып кына калмый, бәлки сәяси, хокукый, әхлакый, иҗтимагый аспектларны үз эченә алган лагерь системасының үзенчәлекле күмәк образын да тудыра һәм аның аерым бер шәхес язмышында тоткан урынын анык билгеләргә омтыла.

Әйтергә кирәк, Аяз Гыйләҗев, роман-хатирәдә шәхес культы чорының гаделсезлекләрен һәм тирән фаҗигасен фактик төгәллек һәм документаль дөреслек нигезендә фаш итү белән бергә, әлеге имәнеч системаның шәхесне акрынлап юк итүгә корылган җәза механизмын тудырган сәбәпләргә дә күз ташларга омтыла.

Ежов, Ягода, Берия, Рюминнар төзегән «ГУЛАГ архипелагы»ның төрле лагерьлары аша үткән һәм кимсетелүләрнең ачы газапларын йөрәге аша үткәргән әдип сталинчыларның ил күләмендә эшләгән геноцид дәрәҗәсендәге зур сәяси җинаяте шаһиты буларак чыгыш ясый. Роман-хатирә 1941-1945 елгы сугыштан соңгы чор белән 1953 елга кадәрге вакыт арасын үз эченә ала, вакыйгалар, истәлекләр әдипнең дәвер, яшәеш, тарих, язмыш, шәхес, җәмгыять турындагы уйланулары, фәлсәфи фикерләре, тарихи тәрәккыяткә карата аның шәхси мөнәсәбәте белән тыгыз үрелеп баралар.

Аяз Гыйләҗев – тоталитар системаның инглиз әдипләре Артур Кестлер белән Джордж Оруэлл әсәрләрендә тасвирланган теоретик моделен китап аша түгел, бәлки үз күзләре белән күргән, үз язмышы аша үткәргән әдип. Шуңа күрә аның шаһитлык кылган һәр сүзе, һәр фикере, һәр уе чын кабул ителә, ышандыра, тетрәндерә, нәфрәтләндерә. «Төрмә энциклопедиясе» дип тә атала алырлык роман-хатирәнең һәр юлы, һәр бите ленинизм тәгълиматына нигезләп канлы террор гамәлләрен тормышка ашырган җәлладларга, коммунист-түрәләргә карата кискен гаепләү акты булып яңгырый. Әдип, тарих агышы һәм җәмгыятьнең бүгенге көндәге рухи халәте хакындагы җитди уйлары белән бергә, үз язмышын гыйбрәт итеп, безне алдан кисәтеп куюны да үзенең изге бурычы итеп саный. «Бүгенге көннән үткәннәргә ашыгып кайтып, кемнәргәдер хөкем чыгарырга әзер фюрерлар уйлансын: әле Җирдә яшәү тәмамланмаган, адәм баласы ни тырышса да зәңгәр шарыбызны орбитасыннан чыгара алганы юк. Рәсәй, көчле вә явыз ил, таркалмаган, сак вә уяу булыйк, без кичергән бәла-казалар, төрләнеп, өр-яңадан бүтән төсмерләр алып, көнгә чыкмасын! Әле Рәсәйдәге бер халык та бүгенгедән гыйбрәт алып киләчәккә терәк булырлык иманга килмәгән!

Бөегебез Фатих Әмирхан гасыр башында ук безне кисәтеп куймаганмыни?! «Кыланчыклык, шпионлык, сүз йөртү, яла ягу, юк гаепне бар итү, көнчелек, начар уйда булу. Корьәндә кискен рәвештә тыелган «кара» сыйфатларны үз замандашларында күреп, бу яман хәлләрдән арынырга чакырып оран салмаганмыни? Гасыр үтеп бара, офыкларда «коммунизм кыры» түгел, «җен-пәриләр туе» шәйләнә. Сергей Курский борчылган хәлләр күз алдында, күкләр бездән өмет өзмәдеме икән?! Кая барабыз?!»

Кая барабыз?! Бу авыр сорауга җавапны әдип дәһшәтле концлагерьларның ягылмаган барагындагы агач нарда аунаганда да, салкын төрмә камерасында берялгызы күшеккәндә дә, концлагерьларның канлы бозын имгәндә дә, төрмә сырхауханәсенең тимер рәшәткәле палатасында аунаганда да газапланып эзли, илне, җәмгыятьне, кешеләрне шундый түбән хәлгә төшергән яман көчләрнең яшәү чыганагын табарга өметләнә, ирек белән ирексезлек арасындагы аермаларга фәлсәфи яктан бәя бирергә тырыша. Тимер читлеккә ябылган аерым бер кешенең, бу очракта Аяз Гыйләҗевнең шәхси язмышы, шәхси фаҗигасе аша без йөзләрчә милләтне тәшкил иткән миллионнарча сәяси мәхбүсләрнең әрнү-газапларын аңлый башлыйбыз, кулга алу, төрмә, карцер, лагерь, лагерь баландасы, месть, петушок, тентү һ.б. шундый сүзләрдән торган үзенчәлекле лагерь лексикасы аша бу дөньяның бөтенләй икенче асылы белән танышабыз.

Әдипнең уйлары, фикерләре, истәлекләре белән чиратлаштырып барылган лагерь тормышы күренешләре, анда хөкем сөргән әхлакый климат белән сәяси һәм иҗтимагый-хокукый шартлар кайбер җитди нәтиҗәләргә дә этәрә. Аяз Гыйләҗев шәхси язмышын шактый катлауландырган һәм, үзенә җәбер-золым китереп, рухи дөньясын нык имгәткән бу системаны каргау, пычрату, яманлау юлыннан китми, бәлки аны шундый хәлгә төшергән сәбәпләрнең тирән тамырларын эзләп, ерак тарихка да күз сала. Ул, симпатиясе белән антипатиясен читкә куеп, бары гаделлек принципларына гына таянган зирәк тарихчы кебек, «тоталитар хакимият» дип аталган һәм иҗтимагый-сәяси һәм әхлакый-хокукый аспектлардан торган катлаулы системаның шәҗәрәсен барлап чыга.

Тоталитар хакимият системасы – термин гына түгел, бәлки рус халкының барлыкка килеп формалашуы һәм аның үз дәүләтчелеген төзү өчен көрәше барышында туган иҗтимагый күренеш. Киев Русе төзелеп, ул таркалганнан соң, вак удел кенәзләре Мәскәү тирәсенә туплана башлагач, тоталитар хакимият төшенчәсе дәүләт белән идарә итү формуласына әверелә. Һәм шуны да әйтергә кирәк: тоталитар хакимияткә берсүзсез буйсыну – рус халкының милли психологиясенең мөһим өлешен тәшкил иткән~милли сыйфатларнын берсе. Россия дәүләте белән гомер-гомергә хәрби-тоталитар хакимият системасы идарә итеп килде. Ул милли психологиянең мөһим өлешенә әйләнеп кенә калмады, бәлки дәүләт белән идарә итүнең милли формуласына да җан өрде. Безнең эраның V гасырында сыйнфый җәмгыять барлыкка килгән чордан башлап рус империясенең беренче тышчасы булган СССР таркалганчыга кадәрге вакыт эчендә рус хәрби кораллы көчләре 193 халыкнын җирен-суын тартып алган, аларның милли дәүләтчелеген җимергән. ЮНЕСКО мәгълүматларына караганда, 1926 елда элеккеге СССРда 194 милләт яшәгән булса (рус милләтен дә кертеп), 1979 елда исә аның саны 101гә кадәр кимегән, ягъни шушы кыска 53 ел эчендә генә дә 93 милләт юкка чыккан. Аз санлы халыкларның юкка чыгу, ассимиляцияләнү тенденциясе исә, СССР дигән империя таркалып, «совет халкы» дигән ясалма империя милләте юкка чыкканнан соң, тагын да зуррак тизләнеш алды...

Корал көче белән буйсындырылган аз санлы башка халыкларның илләрен җимерү, мәдәни һәм матди хәзинәләрен талау исәбенә яшәү хасияте, аларга кол итеп карау гадәте рус халкының канына сеңеп, геннарының бер өлешенә әйләнү сәбәпле, Европа белән Азиянең бер өлешен биләп торган гаять зур территориядә тоталитар хакимият өчен уңдырышлы җирлек әзерләнде. Гәрчә, тарихи тәрәккыятнең зарурлыгына нигезләнеп, иҗтимагый-икътисади формацияләр алышынып торса да, йөзләрчә милләт яшәгән ил белән идарә итү принцибының – тоталитар хакимиятнең асылы тамчы да үзгәрмәде. Теге яки бу формациянең аерым бер дәвердә хакимлек итүенә карап аларның аталышлары, исемнәре генә икенче төрле әйтелә башлады. Партия диктатурасы, соңрак президент институты алыштырды. Тапкырлаучыларның урыннарын алыштырудан тапкырчыгыш үзгәрмәгән кебек, тоталитар хакимият, чорына һәм идеологиясенә карап, бай гардеробында булган төрле төстәге киемнәрне генә алыштырып торды. Аяз Гыйләҗевнең үткен күзе роман-истәлектә мәсьәләнең нәкъ менә шул ягына игътибар итә. Ул, тарих катламнарын актарып, башыннан ук «халыклар төрмәсе» булып оешкан колониаль дәүләтнең лагерьлар иленә әйләнүенең табигый, кануни бер котылгысыз күренеш икәнлеген төгәл мисаллар һәм бай тарихның кыйммәтле документлары нигезендә дәлилли. Илбасарлык һөнәрен төп кәсепкә әйләндергән, башка халыкларның мал-мөлкәтләрен корал көче белән тартып алуны һәм ватып-җимерүне көндәлек бер гадәти шөгыльгә санаган рус хәрби милләте шул гамәлләре аркасында рухи байлык тудыруга әһәмият бирмәгән. Нәтиҗәдә илбасарлыкны яшәү рәвешенә әйләндергән тулы бер халыкның рухи дөньясында җан вакуумы хасил була, һәм ул бушлыкны тиз арада тоталитар хакимият тутыра. Русиядә крепостное правоның бары 1861 елда гына рәсми рәвештә бетерелүе – моның бер мисалы. Әнә шулай чын тарихның төзәтелмәгән дөрес мисаллары һәм төгәл фактлары нигезендә Аяз Гыйләҗев үзен сәяси мәхбүскә әйләндергән тоталитар хакимиятнең барлыкка килү сәбәпләрен дөрес ачып бирә. Элеккеге СССРның «ГУЛАГ архипелагы»на әйләнүен бары коммунистлардан гына күргән һәм моның өчен бары аларны гына гаепләгән Александр Солженицыннан аермалы буларак, илдә лагерь социализмы барлыкка килү мәсьәләсенә Аяз Гыйләҗев әнә шулай киңрәк карый. Бу очракта Аяз Гыйләҗев тоталитар хакимиятнең килеп чыгуын рус халкының милли психологиясенә, милли үзенчәлегенә бәйләп аңлата. Башка халыкларны кол итү белән мавыккан рус халыкның бер көнне әнә шулай «лагерьга» әләгүен угрылык белән щөгыльләнүнең табигый нәтиҗәсе икәнен искәртә. Большевиклар төзегән хакимиятнең тирән тамырларын патша самодержавиесеннән, кенәзләреннән эзләргә димли. Аяз Гыйләҗев тоталитар хакимиятнең туу тарихын тикшереп, анатомиясен тирән анализлап һәм бүгенге көндә дә яшәү сәләте зур булуын алдан искәртеп, аның тарихи тәрәккыяткә киртә булган гамәлләрен фаш итә һем җәмгыять тәнендә яман шеш булган бу авыруның килеп чыгу сәбәпләрен кайта-кайта күрсәтә. Гәрчә Аяз Гыйләҗев «лагерь» темасына шушы роман-хатирәсен генә багышласа да, «Йәгез, бер дога!» әсәре тарихи хакыйкатьне ачу сәләте һәм кешелеккә иксез-чиксез бәла-каза китергән тоталитар системаның табигатен дөрес аңлау хасияте белән Г.Исхакыйның «Зиндан» әсәрендәге лейтмотивка шактый якын тора.

Миңнәхмәт СӘХАПОВ.

«Бердәм агым» китабыннан.
ТКН, 2006.

ДӨЯ КҮЗЕ

Чыңгыз АЙТМАТОВ

(Дәвамы. Башы 35, 36 нчы саннарда).

Көн ярыйсы гына әйбәт башланды, һичьюгы, моторлар сүнеп, туктап тормый – мин суны вакытында китереп торам. Ләкин кичкә хәтле бик ерак шул әле...

Чишмә янына бер баруымда, бәрәннәрен иярткән кечерәк бер сарык көтүе очрады. Аларны бирегә бер кыз куып китергән, сарыкларны чишмәнең үзенә җибәрмичә, инешеннән су эчертеп тора иде. Каян килеп чыккан бу кыз? Бездән бер читтәрәк ике түбәле калкулык артындагы тугайдан килгән булса кирәк. Ул якларда чабаннар көтү көтә. Кызның йөзе нәрсәсе беләндер миңа таныш кебек тоелды. Бервакыт бер журналда мин яшь кенә бер Вьетнам кызының сурәтен күргән идем – аның да, шушы кызныкы шикелле, маңгаенда чәч чугы бар иде. Әнә шул сәбәпле, бу кызны кайдадыр күргәнем бар кебек тоелгандыр.

Без сүзсез генә бер-беребезгә караштык. Минем монда килеп чыгуым аның өчен дә көтелмәгәнрәк булды, ахры. Ләкин мин, берни булмаган кебек, арбамнан сикереп төштем дә чишмәдән мичкәгә су тутырырга керештем.

Ул арада сарыклар су эчеп туйды да, кыз аларны чишмә яныннан куып алып китә башлады. Минем яннан узган чакта, ул:

– Бу чишмә ничек атала? – дип сорады.

Мин әле генә үзем болгаткан түгәрәк чишмә суына карап уйлана калдым. Чыннан да, безнең бу бердәнбер чишмәбезнең исеме булырга тиештер бит. Мин уйланып торган арада, чишмә суы бераз тона төште, өсте чистарып, төбе генә кара-кучкылланып калды.

– Дөя күзе! – дидем мин, кызга таба борылып.

– Дөя күзе дигән чишмәме? – Кыз чәч чугын селкеп, елмаеп куйды. – Исеме бик матур икән! Ул чыннан да дөя күзенә охшаган бит, шундый уйчан...

Шуннан соң сөйләшеп киттек. Кыз безнең якныкы икән. Хәтта укытучым Алляровны да белә икән. Таныш булмаган бер кыз авызыннан шушында, далада, үзеңнең яраткан укытучыңның исемен ишетү гаҗәп кызык икән. Бу кыз үзе дә минем укытучым йогынтысы белән Анархайга килеп эләккәндер әле дип уйлап куйдым мин. Кыз мәктәпне – безнекен түгел, башка мәктәпне – былтыр ук тәмамлаган икән инде, ә хәзер сакманчы, ягъни чабан ярдәмчесе булып эшли икән.

– Безнең утардагы коеның суы тозлы, – дип сөйләп китте кыз. – Шушы тирәдә кайдадыр чишмә бар дип ишеткән идем. Минем үземнең дә җир астыннан чыккан чишмә суын күрәсем килгән иде. Бәрәннәргә дә эчертим дидем, чын суның ни икәнен күрсеннәр, белсеннәр, мәйтәм. Аларны менә үстереп көтүгә тапшырам да көзгә университетка укырга китәм...

– Минем дә киләчәктә укырга керергә исәп, – дидем мин. – Тик мин механизация буенча китәм. Мине монда тракторда эшләргә дип җибәргәннәр иде, ә монысы болай гына, – дидем, мичкәгә ишарәләп, – вакытлыча гына ярдәм итәм... Су ташырга икенче кеше җибәрергә тиешләр.

Монысын инде, билгеле, артыгын ычкындырдым, авызымнан ничек ычкынганын сизми калдым. Оятымнан эсселәп киттем, аннары шундук суынып та киттем. Ерактан Әбәкернең:

– Әй-й, Акаде-емик, җаныңны ала-ам! – дигән шөкәтсез тавышы ишетелде.

– Ай, сөйләшә торгач, онытылып киткәнмен.

– Нәрсә бар анда? – дип сорады кыз, аңлап җиткермичә.

– Бернәрсә дә юк. Су илтергә кирәк, – дип кызарынып мыгырдандым мин.

Кыз үз юлы белән сарыкларын куып китеп барды, Әбәкер исә басуның аргы башында, тракторы кабинасында торып баскан килеш, йодрыгын селкә-селкә, һаман акыра иде әле.

– Киләм бит инде, киләм! Акырма ул хәтле! Чит кешеләр барында шулай кычкыралармыни! – дип ачынып сөйләндем мин һәм атны кушаяклатып чаптырып киттем.

Мичкәдәге су чайкала, түгелә, мичкә авызыннан чәчрәп мине баштанаяк коендыра. Түгелсен, әйдә! Тамчысы да калмасын! Бу кадәр мәсхәрәгә моннан ары түзеп яши алмыйм!

Әбәкер кабинадан сикереп төште дә, теге вакыттагы шикелле яңадан миңа ташланды. Мин атны туктаттым.

– Әгәр шушылай кычкыра торган булсаң, эшне ташлыйм да кайтам да китәм!

Көтелмәгән бу сүздән Әбәкер каушый калды, аннары сызгырып җибәрде дә мине аты-юлы белән сүгәргә кереште:

– Син маңка Академик булмаганга карап моңарчы Анархай юкка чыкмаган һәм хәзер дә убылып җәһәннәмгә китмәс! Бар, олак моннан, дүрт ягың кыйбла! Каршы сүз әйткән була бит, ыштансыз студент.

Мин, арбадан сикереп төшеп, чыбыркымны трактор артына ыргыттым да китеп бардым.

– Туктале, Камил! Алай ярамый бит! Кая китәсең, тукта! – дип Хәлифә артымнан кычкырды.

Мин аның саен кызурак атладым.

Арттан Әбәкернең:

– Туктатма, олага бирсен! Ансыз да аптырамабыз! – дигән сүзләре ишетелде.

– Кеше түгел икәнсең, кансыз, бәгырьсез ерткыч икәнсең, нишләдең син! – дип, Хәлифә аны оялтырга кереште.

Аларның тиргәшүләре миңа байтак ара ишетелеп торды.

Мин, адымымны киметмичә, киткәннән-китә бардым. Кая барып чыксам да, миңа барыбер иде. Тирә-юньдә беркем, бер җан әсәре юк, дөньяның кайсы ягына китсәм дә, юл ачык иде. Чишмәне уздым, кыр станын, теге таш сын торган калкулык битеннән үттем. Таш карчык, бик күп тасырлар буена җиргә иңеп утырган хәлендә, усал елмайган сыман, буш күз чокыры белән минем арттан карап калды.

Берни уйламыйча атлыйм да атлыйм. Минем күңелемдә бер генә уй: моннан мөмкин кадәр тизрәк китү, Ходай каргаган бу Анархайга җилкә чокырымны гына күрсәтү иде.

Күз алдымда буп-буш, ямьсез дала җәелеп ята. Бөтен җире – калкулыклары да, текә тау битләре дә, уйсулыклары да – бөтен тирә-як күңел кайтаргыч дәрәҗәдә бертөрле. Кем дөньяга бар иткән бу эчпошыргыч, үле бертөрлелекне? Нигә әле мин, шушылай кимсетелеп һәм мыскыл ителеп, очсыз-кырыйсыз эче әрем даласын адымым белән үлчәп йөрергә тиеш? Кая карама – бөтен җирдә җансыз-тынсыз чүл. Ни калган монда кешегә? Дөньяда моннан башка җир азмыни аңа? Минем иртәнге хыялларым үз-үземә көлке һәм мәгънәсез булып тоелды.

«Менә сиңа аксыл-зәңгәр әремле гүзәл дала, менә сиңа Анархай иле!» дип, үземнең көчсез, ятим-ялгыз һәм чарасыз булуымны җаным-тәнем белән тойган хәлдә, үз-үземнән көлдем мин.

Минем өстә, баш түбәмдә, бик биек күк йөзе, тирә-ягымда иксез-чиксез дала җире җәелеп киткән – менә шушы дөнья уртасында мин үземне каяндыр монда адашып килеп чыккан, өстенә сырган фуфайка, аягына – кирза итек, башына таушалган-уңган кепка кигән бик бәләкәй, ялгыз бер адәмчек итеп тойдым.

Шул хәлемдә атлый бирдем. Алдымда юл да, сукмак та юк. Барам да барам. «Берәр төшкә, тимер юл буена барып чыгармын әле, – дип уйландым, – шпаллар буйлап китәрмен дә, берәр разъездга җиткәч, товар вагонына утырып китәрмен. Кешеләр булган төшкә барып чыгармын әле...»

Артымда дөп-дөп иткән ат аягы тавышы һәм ат пошкырганы ишетелгәч тә әйләнеп карамадым. Сорокиндыр ул. Ул булмыйча, тагын кем булсын. Менә ул хәзер мине шелтәли, үгетли башлар. Төкерәм мин аңа – барыбер кире кайтмыйм, уйламыйм да.

– Туктале! – диде Сорокин, артык кычкырмыйча гына.

Туктадым. Сорокин тиргә баткан аты белән минем янга килеп җитте. Уңган кашлары астыннан миңа сүзсез генә, зәңгәр күзләре белән текәлеп карап торды да кыр сумкасына тыгылып, аннан кызыл кәгазь бите чыгарды – минем комсомол путёвкасы иде ул. Бирегә килгән көнне мин ул путёвканы бик зур горурлык белән аңа тапшырган идем.

– Мә, моны калдырырга ярамый, – дип, Сорокин тыныч кына путёвканы миңа сузды.

Мин аның күз карашында шелтә дә, ачу-нәфрәт тә күрмәдем. Ул мине ачуланмый да, кызганмый да иде. Һәртөрле көтелмәгән хәлләргә күнегеп-гадәтләнеп беткән, эш-мәшәкатьләргә чумган кешенең җитди күз карашы иде бу. Сорокин талчыккан, кызгылт төк баскан битен уч төбе белән сыпырып алды да:

– Разъездга барсаң, юлны уңгарак тот, әнә теге уйсулык буйлап, – дип, миңа юл күрсәтте һәм шуннан соң, атын борып, әкрен генә китеп барды.

Мин, тәмам аптырап, аның артыннан карап калдым. Нигә ачуланмады ул мине, нигә үгетләп маташмады? Нигә аның аты да боек, үзе дә бик арыган-талчыккан? Гаиләсе аның – хатыны белән балалары – кайдадыр еракта, ә үзе монда бер ялгызы еллар буе далада йөри. Нинди кеше ул Сорокин, нәрсә бәйләп тота аны шушы Анархай даласына?

Ник икәнен үзем дә аңламастан, мин әкрен генә аның артыннан иярдем.

Кич җиткәч, бөтенебез тирмәгә җыелдык. Беркем бер сүз эндәшми. Тирмә эче тып-тын, чырт-чырт итеп учак янганы гына ишетелә. Бөтен гаепнең башы миндә. Сүз әле башланмаган, шулай да Сорокинның киеренке бер чырай белән кашларын җыерып утыруыннан нәрсәдер әйтергә җыенганлыгы сизелеп тора

– Йә, нишлибез? – диде, ниһаять, Сорокин беркемгә атап эндәшмичә генә.

– Ә нәрсә бар, Анархайны туфан суы басамы әллә? – дип көлеп куйды Әбәкер.

Ул шулай дигәч, Садабәк сүзсез генә торды да тирмәдән чыгып китте. Теге көнне сугышканнан бирле ул Әбәкер белән сөйләшми иде, һәм хәзер дә аның сүзгә катнашырга исәбе юк иде, ахры. Энесе прицепщик Әсәркәп тә урыныннан кузгала башлаган иде дә, нидер уйлап, кире утырды.

Әбәкер аның белән дә тату түгел. Беркөнне Әсәркәп, үтенечемне тыңлап, мине Садабәк тракторындагы үз сабанына утырткан, ә үзе минем арба белән су ташыган иде. Билгеле инде, суны вакытында җиткермәгәч, Әбәкер моңа да ябырылган. Ләкин Әсәркәй үзен кыерсыттырмаган, ул да сугыша белә торган егет. Югыйсә миннән өч кенә яшькә олы.

Әбәкернең сүзенә каршы беркем җавап кайтармады.

– Уйлап торасы юк монда, – диде Әбәкер. – Эшне кем тоткарлаган шул җавап бирсен.

– Хикмәт кемнең гаепле, кемнең гаепсез булуында түгел! – диде Сорокин, миңа карамыйча гына. – Биредә яшь кешенең язмышы хәл ителә, нишләргә тиеш ул хәзер?

– Һи, язмыш, имеш! – диде Әбәкер, көлеп. – Моның ише академикларның язмышы күптән хәл ителгән: өметсез, бернигә яраксыз халык алар! – дип, кулын гына селекте Әбәкер. – Йә, үзең уйлап кара Сорокин, ни эшкә ярый алар? Без, бөкребезне чыгарып, икмәк үстердек, ә алар унар-унбишәр ел буена укып яттылар. Без аларны ашаттык, киендердек, ә алардан нәрсә чыкты, аларны анда нәрсәгә өйрәттеләр? Машинаны белми, атка камыт кигезә белми, чөелдерекне дә җүнләп кыса алмый... Ни сәбәптән әле мин аның өчен интегергә тиеш? Миңа ниемә кирәк аның укымышлылыгы? Таш сыннарны белә, янәсе! Ә эшне эшли алмый. Алай икән, ычкын моннан, башкаларның эшенә аяк чалма! Син дә, Сорокин, мине кысма, мин алмашчысыз, ал-ял белми эшлим, берәүгә дә эленке-салынкы йөрергә бирмим. Ошамыйм икән – иртәгә үк минем монда эзем дә булмас. Ләкин әлеге сүземне һәрвакыт әйтәчәкмен: мин ул академикларның барысын да...

– Җитте! – дип Сорокин, Әбәкергә карамыйча гына, ачу белән аны сүзеннән бүлдерде. – Анысын без синнән башка да беләбез. Сүз ул хакта түгел. Йә, Камил, әйт әле, син үзең ничек уйлыйсың соң?

(Дәвамы киләсе санда.)

Герой исемен алмаган 8 татар

(Ахыры. Башы 35-36 нчы саннарда).

Габдрахманов (бүләкләү кәгазендә Абдрахманов) Газис 1923 елда Балык Бистәсе районының Югары Тегермәнлек авылында туган, 1943 елның 13 апрелендә мобилизацияләнгән. Фронтта 1943 елның 13 маеннан бирле сугыша. Ике тапкыр яралана. Кызыл байраклы 11 нче гвардия укчы дивизиянең 40 нчы полкында җәяүле разведчиклар отделениесе командиры, өлкән сержант булып хезмәт итә. Яулар барышында 1944 елның 4 августында – Кызыл Йолдыз, 3 октябрендә – Кызыл Байрак, 6 декабрьдә, вафатыннан соң, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары белән бүләкләнергә өлгерә.

1944 елның 12 сентябрендә Көнчыгыш Пруссия җиренә бәреп кергәч, разведка төркеме дошманның нәкъ үзләре шикелле үк 60 солдаттан хасил разведкасы белән йөзгә-йөз очраша. Тегеләрнең коелып төшүеннән оста файдаланып, Габдрахманов разведчиклары граната һәм автоматлар белән дошман төркемен юк итеп бетерә, Ә Газис үзе каравылда торган немецны әсирлеккә ала.

1944 елның 18 октябрендә Көнчыгыш Пруссиядәге Ланкупе авылы янында Габдрахманов өч разведчик белән бергә янә бер «кыйммәтле тел» эләктерә, яу барышында 20 гитлерчыны юк итәләр. Шулчагында Газис каты яралана. Аны 1944 елның 18 октябрендә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр. Әмма 1944 елның 12 ноябрендә Газис госпитальдә вафат була, аны хәзерге Калининград өлкәсенең Нестеров районындагы Калинин авылында җирлиләр. Алтын Йолдыз урынына Кызыл Байрак ордены ул вафат булганнан соң гына килеп җитә.



Җиһаншин Рәхимулла Прокопий улы 1916 елда Кайбыч районының Большое Русаково авылында туа, 1941 елның сентябрендә шул ук район комиссариаты тарафыннан фронтка озатыла. 6 нчы гвардия танк корпусының мотоцикллы 3 нче аерым Перемышль батальонында Т-34-85 танкының механик-йөртүчесе һәм гвардия өлкән сержанты булып хезмәт итә. Бер мәртәбә авыр яралана. Яулар барышындагы батырлыклары өчен 1 һәм 2 дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Сугышчан казанышлар өчен» медале белән бүләкләнә.

1945 елның 18 гыйнварында Җиһаншин, танкы белән оста маневрлар ясап, Польшадагы Варта елгасына, Радом шәһәре янында корылган күперне бик оста эләктерүгә ирешә һәм аны кабат дошман кочләренә бирмичә, үз кулында тота. Дошман контрһөҗүм ясап караса да, 50 дән артык сугышчысын югалтып, кире чигенергә мәҗбүр була. Үз танкына ут капса да, Җиһаншин аны ташламыйча, һаман яуны дәвам итә. Үзе дә шунда янып һәлак була.

1945 елның 20 февралендә аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр. Ләкин аны вафатыннан соң, 26 мартта, инде икенче мәртәбә 1 нче дәрәҗәдәге Ватан сугышы ордены белән йомып куялар.





Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

Хәбәрчеләребез яза

Арчада – каһвәле иҗатчылар җыены

Иртәне бер чынаяк каһвәдән башлау – күпләр өчен гадәти хәл. Дөресен әйткәндә, мин бу гадәтнең зыянлы йогынтысын гына исәпкә ала идем, бүгенгә чаклы... Фикеремнең катгый үзгәрү сәбәбе: Англия патшабикәсе Елизавета Икенче каһвә фаворитты булган икән бит! Тагын кызыгы шунда – ул үзенең 96 яшен тутырып кына гүр иясе булды.

Каһвәгә, каһвә сөючеләргә кагылышлы мондый фактларны үзебенең Арча шәһәре «Date&coffee» каһвәнәсендә узган кичәдә ишетеп кайттым. Без стереотиплар, бу төр эчемлеккә булган мөнәсәбәтләр хакында сөйләшү белән генә чикләнмәдек. Югыйсә, җыенда әдәбиятка гашыйк булган чын иҗатчылар катнашты. Биредә каһвәгә багышланган хикәя, язма, шигырьләр яңгыравы да шуның белән бәйле.

Бер әсәр белән генә язучының, яки шагыйрьнең иҗатына объектив бәя биреп булмый диләр, монысы тотрыклы мәсьәлә. Әмма шунысы хак – чарадагы һәр катнашучының каләме ышанычлы. Алар арасында төрле яшьтәгеләр һәм төрле һөнәр ияләре бар. Син үзеңнән кечерәк, яки синнән олырак кешеләр белән аралаша аласың. Моны бик кызыклы тәҗрибә дип билгеләр идем. Иҗатның яше юк бит, карты да юк. Шулай да аның мөһим миссиясе бар – фикердәшләрне бер урынга туплау.

Каһвә – үзенчәлекле һәм кызыклы тема. Кичәдә катнашып шәхсән үзем, иҗатымны баетты, чөнки алдан ук каһвә темасына язылган әсәрем юк иде. Шәп тәкъдимне ишеткәч, үз көчемне сынап карарга булдым. Гомуми күзәтүләргә килгәндә, күп катнашучыда каһвә мәхәббәт, җылы хисләр белән ассоциация тудыра. Һәм әлеге ярату – ул яшьлек ярату гына түгел. Бәлкем «сихри эчемлек»кә булган аерым мәхәббәт. Ул күп иҗатчыларны кирәкле энергия белән тулыландыра да бит әле. Безнең очракта аның белән аерылмас дуслык та язу эшенә керешкәч башлана.

«Иҗат итүче яшьләрне каһвәханәдә җыю теләге миндә инде яз айларында ук туган иде, ләкин без аны җәйгә калдырырга булдык, чөнки укучы яшьләрне бу чорда җыю уңайлырак», – ди чараны гамәлгә ашыручы Адилә Әхмәтҗанова. – «Яшьләр өчен моңарчы да кызыклы форматта чаралар да оештырырга тырыштык. «Каһвәле иҗат»та тукталуымның сәбәбе, ул «каһвә» темасының актуаль булуында. Минем районыбызның яшьләренең замана белән бергә атлап иҗат итүен күрсәтәсем килә. Яшьлек – ул мөмкинлек. Алардан дөрес итеп куллану кирәк дип саныйм. Иҗат итүче яшьләрне берләштерәсем килә, Арчаның яшь талантларының зур бер илһам тулы дулкын булуын телим, ә районыбыз халкының иҗатны тыңлый белү сәләтен үстерәсем килә. Бу очрашу һәрберебез күңелендә бары җылы тәэсирләр генә калдырды, чөнки мин һәрбер катнашучыда зур кызыксыну чаткысын күрдем. Без алга таба үсәрбез һәм бер дулкын булып иҗат итәрбез дигән теләктә калам».

Китапханә һәм китаплар әдәбият белән тыгыз элемтәдә булмаганнарга нык зарыктыргыч булып күренергә мөмкин. Гадәти җыелышны гадәти булмаган урында оештырсак, бирегә китап яратучы, язырга яратучылар гына түгел, бу төр эшчәнлеккә битараф булмаганнар да йөриячәк.

Нәтиҗә буларак, шуны әйтәсем килә: иҗади очрашуның каһвәханәдә узуы – уникаль күренеш һәм ул замана яшьләрен әдәбиятка тартуның әйбәт ысулы да булып тора. Киләчәктә дә очрашулар насыйп булсын!

Азалия САБИТОВА.
Арча районы,
Ашытбаш авылы.

Татар каллиграфиясе:

Быел беренче тапкыр халыкара каллиграфия көнен «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә күргәзмә белән билгеләп үттек. Халыкара каллиграфия көне 2017 елда гамәлгә куелып августның икенче чәршәмбесендә билгеләп үтелсә дә, безнең бу җәһәттән бәйрәм оештыруыбыз беренче мәртәбә. Бу экспозициянең моңа кадәр үткән күпләгән матур язу күргәзмәләреннән аермалы ягы шунда – анда гарәп язуы борынгы рус каллиграфиясе, кытай басма гравюралары белән янәшәдә куелган. Экспонатлар сынлы сәнгать музее архивыннан, Н.Лобачевский исемендәге китапханәдән, Ислам университетының гарәп каллиграфиясе һәм ислам сәнгатьләре үзәгеннән алынган. Иран, Үзбәкстан, Кытай консулларының катнашуы чарага дәрәҗә өстәде.

● Матур язу остасы Гөлназ Исмәгыйлева.

● Текстолог галим, каллиграф Нәҗип Нәккаш.

Гарәп хәрефе һәм татар мәдәнияте

Матур язу сәнгате дөньядагы барлык халыкларда да бар. Әмма ислам мәдәниятендә гарәп каллиграфиясе аеруча зур үсеш алган, чөнки Аллаһ, пәйгамбәрләребезнең һәм бөтен тере җан ияләренең сурәтен ясау тыелганга күрә, язу осталары хыял байлыкларын эшкә җигеп, гарәп ыргакларыннан төрледән-төрле образлар уйлап чыгарган. Коръән сүзләрен тасвирлаучы чара буларак, гарәп язуы татар мәдәниятенә дә килеп кергән һәм күп гасырлар буе түр урынны биләде. Безнең көннәргә килеп җиткән гарәп язулы кабер ташлары, Алтын Урда чорына караган хан ярлыклары гарәп каллиграфиясенең мәдәниятебездә нинди зур урын тотканын күрсәтә. Әмма Казан алынгач, архитектура, зәркәнчелек, келәм туку кебек һ.б. элитар сәнгать төрләре белән бергә каллиграфия дә юкка чыга яза.

Мөхәммәтгали Мәхмүдов

1840 елда Казан университетында шәрык факультеты ачылгач, гарәп каллиграфиясен өйрәтү ихтыяҗы туа. Һәм мөгаллим буларак университетка Казан губернасы Минзәлә волосте Сәләнгүр авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килгән Мөхәммәдгали Мәхмүдовны чакыралар. Казанның Зәңгәр мәчете мәдрәсәсендә укыганда язуга оста егет университет җитәкчелегенең күзенә чалынган булса кирәк. Җитәкчеләр исә мәдрәсә шәкертләрен гел күз уңында тота, чөнки алар уку барышында шәрык китапларын һәм дәреслекләр күчереп язалар, шәрык факультетында укытыр өчен исә әсбаблар бик кирәк. Әмма Мөхәммәтгалинең югары белеме юк, җитмәсә, ул крестьян баласы. Крестьяннарга исә үзләре теләгәнчә күченеп йөрергә рөхсәт юк. Шуңа күрә ул укыту эшенә 1844 елда гына керешә һәм ул елларда беренче татар мөгаллиме, югары белеме булмаган укытучы һәм крестьян сословиесеннән чыккан остаз буларак университет тарихына кереп кала. Безнең гарәп язуын торгызу нәкъ шул вакыттан башлана. Каллиграфия университетның дүрт курсында да җентекләп укытыла. М.Мәхмүдов студентларга вакытын кызганмавы, язу өчен кирәк-яракларны үзе табуы, укыту эшенә бирелгәнлеге белән җитәкчелектә зур абруй казана. Шәрык факультеты Санкт-Петербургка күчкәч, Мөхәммәтгалине Казанның 1 нче гимназиясенә укыту эшенә билгелиләр. Соңыннан ул уку йортының директоры була. Татар, төрек телләрен укыту буенча дәреслекләр яза. Аннары фикердәшләре белән бергә татарда беренче дөньяви уку йорты укытучылар мәктәбен ача. М.Мәхмүдов бик милләт җанлы шәхес булган дип уйларга кирәк. Гимназиядә укытучы булып эшләгәндә ул директорга татарча киенеп йөрергә һәм сакал йөртергә рөхсәт сорап хат яза, университетта да милли киемнән киенеп йөрдем, дип үтенеченең нигезсез булмавын дәлилли. Әмма Мәхмүдовка милли кием кияргә рөхсәт бирмиләр. Әмма архивта аның 60 яшьләрендә төшкән фотосурәте сакланган. Аннан күренгәнчә, мөгаллим, каллиграф, мәгърифәтче Гали Мәхмүдов сакалын кырмаган. Үз дигәненә ирешә торан үҗәт, тырыш кеше булган, күрәсең.

● Әлфия Исхакованың «Милләтнең алтын баганалары» исемле шәмаиле.

● Ришат Сәлахетдиновның «Локман» сүрәсе шәмаиле.

Гарәп каллиграфиясенең татар мәдәниятендә үсеше

Гарәп язуы турында сөйләгәндә беренче профессиональ рәссамнарыбыздан булган Бакый ага Урманчены телгә алмыйча мөмкин түгел. Ул гарәп хәрефләре белән матур мәгънәле композицияләре иҗат итә. 1990 елларда исә каллиграфия сәнгатебезнең яңаруы текстолог галим язу остасы Нәҗип Нәккаш исеме белән бәйле. «Мирас» журналы ачылып, матбугат битләрендә милли тарихыбыз, татар мәдәниятен сурәтләүгә юл ачылу гарәп каллиграфиясен, шәмаил сәнгатен дә халыкка киң таратырга мөмкинлек бирә.

Нәҗип аганың Татар дәүләт гуманитар институтында һ.б. уку йортларында каллиграфия дәресләре алып баруы нәтиҗәсендә, бу сәнгатькә яшьләр килә башлый. Бүген гарәп каллиграфиясе осталарыбыз байтак. Күргәзмәдә Нәҗип Нәккаш, Владимир Попов, Ришат Сәләхетдинов, Әлфия Исхакова, Роза Хуҗина, Гөлназ Исмәгыйлеваның һәм Ислам университетнындагы гарәп каллиграфиясе һәм ислам сәнгатьләре үзәгендә Рамил Насыйбулловтан осталыкка өйрәнүче берничә укучының иҗат эшләрен күрергә мөмкин.

Гарәп каллиграфиясенең тормышыбызда кулланылышы

Ни кызганыч, сирәк-мирәк уздырылган күргәзмәләрдән кала, гарәп хәрефләрен тормышыбызда юк дияргә була. Югыйсә, аны архитектурада, кабер ташларында, элмә такталарда, киемнәрдә, интерьер дизайнында, ювелир сәнгатьтә, гамәли-бизәүдә һ.б. киң кулланырга мөмкин булыр иде. Гарәп хәрефенең театр сәнгатендә яңаруы сөендерсә дә, бик каршылыклы фикерләр тудырды. Нурбәк Батулла башкарган «Әлиф» спектакле «Алтын битлек» алса да, «Шәмаил» спектакле, киресенчә, татар җәмәгатьчелегендә нәфрәт уятып, Казан сәхнәләреннән ары китә алмады.

Язу сәнгатенең сәламәтлеккә файдасы

Психологлар фикеренчә, матур язу сәнгате кешенең «йоклаган» ми күзәнәкләрен дә уята ала. Даими рәвештә матур язу белән шө-

● Кытайларның бәхет теләп язылган сурәте. XIX гасыр ахыры-XX йөз башы.

● Владимир Поповның Фатбер Сафинга багышланган туграсы.

● Ришат Сәлахетдиновның «Гыймран сүрәсе» шәмаиле.

● Әлфия Исхакованың «Аллаһның 99 исеме» шәмаиле.

кичә, бүген, иртәгә

● Ришат Сәлахетдиновның «Гыймран сүрәсе» шәмаиле.

● «Аллаһ матур һәм матурлыкны ярата». Бакый Урманче эше.

гыльләнгән кешенең холкы уңай якка үзгәрергә мөмкин. Ул катлаулы эшләр алдында да каушап калмый, хисләре дә «утыра» төшә, кирәксә-кирәкмәсә дә кызып китүчәнлеге басылырга мөмкин. Совет заманында тикмәгә генә матур язуны мәктәпләрдә укытмаганнар. Педагогика училищеләрында шулай ук программада матур язуга сәгатьләр каралган була. Бүген компьютер заманында һәм мәктәпләрдә матур язуга әһәмият бирелмәгәч, табиблар балаларның вак моторикасы үсми калуын билгеләп үтә. Бу исә аларның укуында да, холкында да, үзара мөнәсәбәтләрендә дә чагыла. Шуңа күрә психологлар мәктәпләргә матур язуны кайтарырга теләп чаң суга. Тормышның бөтен яклары автоматлашкан заманда адәм баласы үзе дә чын хисләргә, матурлыкка сусады. Кафелардагы элмә менюларга кулдан язулар, кулдан язылган открыткалар аша кешеләр матур язуга тартыла. Язу бит ул – киләчәк буыннарга юллама, язу – кешенең йөзен ача торган бер сыйфат. Бигрәк тә татар кешесенә кулдан язуга кайту бик мөһим. Чөнки каллиграфия ул – образлы фикерләвебезнең бер чагылышы. 2017 елда халыкара каллиграфия көнен кертелүендә дә бер хикмәт бар дип уйларга кирәк...

Гарәп каллиграфиясенә укыту

Ни кызганыч, бүген гарәп каллиграфиясенә бары Ислам университетында гына өйрәтәләр. Анда каллиграфия һәм ислам сәнгатьләре үзәге 2010 елда ачыла. Җитәкчесе – Рамил Насыйбуллов. Һәр теләгән кеше килеп өйрәнергә мөмкин. Укыту көн саен икешәр сәгать һәм, иң мөһиме, бушлай. Әмма Рамил әфәнденең әйтүенә караганда, килүчеләр күп булса, да өйрәнеп бетеп диплом алучылар бик аз, чөнки эше бик матавыклы, авыр.

Татар каллиграфиясе көне кирәк!

Татар халкының каллиграфия, шәмаил сәнгатенә хөрмәте аерыча зур. Чөнки пыялада язылган шәмаилләр һәр татар өендә хәтта дингә каршы пропаганда алып барылган авыр елларда да сакланып калды. Ул пыяла кисәкләрендәге гарәп ыргаклары безнең өчен мәчет тә, имам да, вәгазь дә, намаз да булды. Шуңа күрә бүген шәмаилләребезне православие дине белән бәйле язу үрнәкләре белән янәшә күреп, күңелнең асты өскә килә. Күренекле рәссамыбыз Григорий Эйдинов күргәзмәдә бабасы Арон Эйдиновның яһүдләрнең дини китапларын күчереп язуы турында сөйләгәндә әлеге чара бөтенләй Арон дәдәйнең мирасы презентациясенә ошый башлады. Бозау тиресенә генә язган, зирек агачы чикләвекләреннән караны да үзе ясаган, каз каурые белән генә сырлаган, изге китапларны тимер каләм белән язарга ярамый, дигән, имеш. Ул гына белгән инде бөтен рәтен... Читтән караганда исә халыкара каллиграфия көне дигән булып, татар сәнгатен әлеге дә баягы башкалар белән бер казанга салып бутау һәм шулар эчендә эреп югалуына юл ачылды кебек... Кытай каллиграфиясе тарихы мең еллыклар белән исәпләнә. Бүген дә һәр Кытай шәһәрендә каллиграфия үзәге эшләп килә. Казанда күргәзмәгә куймасалар да, Кытай хәрефләре югалмаячак. Ә менә татар кешесе шәмаил белән янәшәдә уйгур дин кардәшләребезне диннәреннән ваз кичтермәкче булып өтермәннәрдә җәзалаган кытайларның каллиграфиясен күреп ничек йөрәге чыдасын? Шуңа күрә безгә халыкара бәйрәм түгел, татар каллиграфиясе көне кирәк!

Уң кул нишләгәнне сул кул белми

Зурдан кубып каллиграфия көнен билгеләп үткәч, матур язу музее кирәклеге турында да фикерләр байтак яңгырады. Чыннан да, мең яшәр Казаныбызда каллиграфия музее эшләп торса бик күркәм булачак, чөнки гарәп каллиграфиясе татарның мең еллык әдәби мирасының чагылышы да әле. Совет чоры язучыларының бер-ике әсәрен укып, татарны да юньле әдәбияты бармыни, дип мыскыл итүчеләргә, музейга килеп, хаталарын тану өчен бер мөмкинлек ачылыр иде. Әмма бездә татар шәмаиле галереясе бар иде бит инде. Ул байтак еллар Кремльдәге Кол Шәриф мәчетендә эшләп килде. Өлкән һәм яшь каллиграфларның очрашу, аралашу, үз-үзләрен күрсәтү урыны иде ул. Аны архитектор, шәмаилләр буенча кандидатлык диссертациясе яклаган сәнгать фәннәре кандидаты Рөстәм Шәмсутов җитәкләде. Әмма Кремльдәге керемле урынны аннан кызганып булса кирәк, галереяне ипләп кенә ябып куйдылар. Инде хәзер музей ачу турында сөйләшәбез. Кысла, чуртан һәм аккош кебек сәнгатьне, мәдәниятне, милли тормышны төрле якка тартудан кайчан туктарбыз икән? Ошбу зур күргәзмәне сынлы сәнгать музее башлап йөрде. Музей турындагы сүзләр дә аның җитәкчесе авызыннан ишетелде. Галереяны япканда кайда булган соң сынлы сәнгать музее директоры? Әллә бөтенесенә төкереп, үзенең эш күрсәтәсе килеп йөрүеме? Кремльдәге хуҗалар исә ни өчен ни теләсә, шуны кылана. Ул аерым утрау түгел, республикабызның бер өеше буларак милли сәнгатьне, мәдәниятне саклауга хезмәт итәргә тиештер ләбаса! Мең газап белән ачылган шәмаилләр галереясен ябып куюны шулай җиңел генә хәл итәргә тиеш иделәрме?

Халыкара каллиграфия көнен шулай билгеләп үттек...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

АКТАНЫШ

(Ахыры. Башы 33, 34, 35, 36 нчы саннарда).

Олы Имән – Бүләр-Байсар волостена керә. **XVII гасырда** нигезләнгән. 1795 елда 32 «башкорт», 96 типтәр яшәгән, 1905 елда халык саны 1104 кешегә җиткән. 1870 елда үткәрелгән тикшерү барышында авыл типтәрләре «безнең бабайларның бер өлеше Байлар, икенчеләре Йәнәй олысыннан күчеп килгән, аларга җир белән файдалану турындагы грамоталар безнең вотчинникташлар булган Чалманарат кешеләре кулында калган», дип аңлата. Әмма вотчинник буларак танып, җир фәкать 53 «башкорт»ка гына тиешенчә (40 дисәтинә хисабыннан) бирелә. 1912 елда инде 291 кешене «башкорт», ә 902 җанны типтәр дип таныйлар.

1834 елда бу авылдан да Минсәяф Сарыйбулат улы Сөешев офицер дәрәҗәсе ала һәм дворяннар катламына күчә. Биредә үскән Лемон Леронов (Ләбиб Лерон) 2022 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Уразай – Гәрәй волостеның Әҗәкүл түбәсендә, Бакылды күле һәм Шәбез елгасы буенда. 1795 елда 28 хуҗалыкта 179 «башкорт» исәпкә алынган. Тарихы иртәрәк. Авылны **1674** елда Уразай Токаев нигезләгән, дигән фараз да бар (Моратов Ф., Хуҗин Й. Актаныш – туган җирем. Казан, «Идел-пресс», 2003 ел, 233 бит). Ә тарихи документларда 1750 елда бу авылдан Күгәш Тугашев һәм аның улы Күгән Такталачык, Әҗәкүл, Куян авылы вәкилләре белән бергә Агыйдел буендагы балык тоту урыннарын Каракүл волостендагы Пермяк авылы крестияннарына елына 16 сум түләү хисабыннан 30 еллык арендага бирү турында килешү төзү уңаеннан телгә алына. Уразайның элек «Мүкле» дигән аты да булган.

1902 елдан соң икегә бүлеп йөртелә. Иске Уразайда 1912 елда – 549, Яңасында 548 «башкорт» яши.

Түбән Уръяды – Йәнәй волостеның Тугыз түбәсенә буйсынучы авыл. **1741** елда Уръяды һәм Адай авылларыннан 6 кеше кул куеп, Бүләр волосте старшинасы Мәсәгуть Тәтимовтан үзләрен Меңнәр авылы янында буш яткан җирләргә күчеп урнашырга рөхсәт сорый. Ә авыл ирләре үз яннарында җир җитмәгәнгә күрә яңа утрак урын эзли икән, димәк, авыл 1741 елга кадәр һичьюгы 50-60 ел алдарак нигезләнгән, дип исәпләргә кирәк. Якын-тирәдәге дистәләгән авыллар шикелле үк, тәүге ревизия биредә 1795 елда гына үткәрелә, авылдагы 3 йортта 16 «башкорт» яшәве ачыклана. 1912 елда алар саны 442 гә җитә.

Югары Уръяды – шул ук түбә составында. 1762 елда 7 типтәр яши, «башкортлар» исәпкә алынмый. Аның каравы, 1795 елда бу авылда инде 212 «башкорт» яшәве ачыклана. 1912 елда 423 кеше типтәр булып языла.

Усы – Бүләр волостеның Мөшегә түбәсенә карый. **XVII гасырда** нигезләнгән. 1784 елда әле мәчетсез авыл була. Ә 1795 елда 25 йорттагы кеше саны 218 «башкортны» тәшкил итә. Ләкин Усы һәм Зөбәер авылы вәкилләре 1770 елда ук тарихка теркәлә, бу елда алар Мөшегә елгасындагы тегермән урынын 31 елга сарай крестиянарына сатып җибәрә.

Өшәр-Семиостров – Йәнәй волостендагы түбә үзәге. Авыл **1645 елгы** документларда ук телгә алына (История башкирских родов. Гирей. 82 бит). Шул ук китапның 87 битендә Өшәр «башкорты» Мятючка Токаевның 1701 елда авыл янындагы күлләрне Каракүл крестияннарына 15 сум хакына арендага бирүе тасвирлана.

Кара чикмәнгә төренгән атакайлар туктаусыз котыртып тору нәтиҗәсендәдер, падишаһ Алексей Михайлович 1656 елда Семиостров янәшәсендәге балык тоту урыннарын Савва Сторожев монастырена бүләк итү турында карар чыгара. Әмма 1730 ел үрләренә кадәр татар старшиналары килмешәкләрне үз вотчиналарына кертми. Мисалга, 1795 елда да биредәге 76 йортта 609 «башкорт» «гөрләп» яши әле. Ләкин 1736 елда вотчинниклар урысларга Сәүз күле артындагы тауда урнашырга рөхсәт бирә башлый. 1738 елда үз җирләрен аларга арендага да бирәләр. Кама елгасының биек ярлы ягында, Камышлы, Шумшар, Кырыкмас инешләре буенда 1746 елда урысларның Осиновка, Онтрожиха, Ломовая атлы биләмәләре үсеп чыга, алар Сәүз, Күргә, Җәенле дип аталган балыклы күлләрне дә эләктерә. 1890 елларга чаклы алар күл һәм елгалар буендагы бер мең дисәтинә мәйданда урманнарны кисеп бетерә. Билгеле, мондый күршелек тәэсир итми калмый, 1816 елда ук Өшәрдәге 424 ирнең 54 е Сәүз күле аръягына кача һәм шунда Сәүз – Яңа Семиостров авылын нигезли. Үҗәт татарлар Иске Семиостровта барыбер бирешми, 1912 елда 500 хуҗалыкта 2485 «башкорт» гомер итә әле. Ләкин большевик комиссарлар күпкә миһербансызрак шул. Алар Өшәргә «өлкән агай» вәкилләрен китереп тутырды, рус мәктәбе ачты. Ходай Тәгалә хупламады, ахрысы, Түбән Кама сусаклагычы нигезләү башлангач та, Семиостров саласы юкка чыкты.

Чалманарат – Бүләр волостеның Бүләр түбәсенә буйсына. Ерак тарихы әлегәчә ачыкланып бетмәгән. **XVII гасыр** башында ук нигезләнгән булырга тиеш. Әмма 13 йортта 84 «башкорт» вотчиннигы, 3 хуҗалыкта 9 типтәр гомер иткән, дип 1795 елгы мәгълүматлар гына мисалга китерелә. 1912 елда 92 йортта 518 «башкорт», 6 хуҗалыкта 23 типтәр яшәве дә мәгълүм. Гәрчә 1842 елда Минзәлә өязе идарәсендә стряпчий Скарятинов алдында җавап тоткан чакта авыл типтәрләре Мөхәммәтвәли Акаев белән Акай Моратов үз бабаларының әлеге биләмәдә борын заманнардан бирле гомер итүе, өйдәш итеп кертелгән «башкорт» вотчинникларының Йәнәй волостеннан күчеп килүе турында сөйли, ләкин сүзләрен дәлилләү өчен җир саклау грамоталарын гына чыгарып сала алмый.

Бу авылда 1807 елгы Пруссия походы вакытында ук танылган һәм көмеш медальгә лаек булган Габдрәшит Габсәлам улы Айтуганов гомер иткән була. Шушы авыл егете, шагыйрь Мөхәммәт Мирза (Илфак Ибраһимов) 2012 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Чуракай – Бүләр волостеның әүвәл Бүләр-Байсар, соңрак Әмәкәй түбәсенә буйсына. Тәүге ревизия 1795 елда гына үткәрелә һәм авылның 11 йортында 98 «башкорт» яшәвен ачыклый. Чуракайның улы – азанчы Идриснең 1746-1812 елларда гомер итүе билгеле, димәк, Чуракай үзе 1720 елларда дөньяга килгән һәм авылны **1740** елларда нигезләгәндер, дип уйлыйк. Авыл Калмия елгасы буенда, куыш эчендәге кебек тыныч урында яшәгән. Баскыннар килеп талау кебек зәхмәтне күрмәгәндер. 1912 елда 210 хуҗалыктагы халыкның 1093 «башкортка» җитүе шул хакта сөйли. Башкортстанның Әлшәй районында да Чуракай исемле зур авыл бар.

Чат – Байлар волостеның Калмаш түбәсенә кергән. **XVII гасырда** нигезләнгән. 1795 елда 31 йортта 234 «башкорт» җир хуҗасы булып яшәгән. 1905 елда 187 йорттагы халык саны 1050 кешегә җиткән.

Чынык – Байлар волостеның Калмаш түбәсе составында. **1713 елда** документларга кергән. 1795 елда 18 өйдә 153 «башкорт» яши. 1905 елда авылдагы 55 йортның 16 сы типтәрләрнеке булып саналган, җәмгысе 316 кеше гомер иткән.

Чөгәнә – шул ук исемдәге күл һәм инеш буенда урнашкан, Кыргыз волостеның Ябалак түбәсенә буйсынган. 1745 елда Гәрәй волосте старшинасы Мөтә Җанырысов белән бергә Чөгәнә йөзбашы Иштирәк Дүсмәкәевнең ясаклы татар Җиһанша Балтаевны чолыкчылык һәм аучылык белән көн күрү өчен үз вотчинасына кертү турында төзелгән килешү уңаеннан телгә алына. Ә беренче тапкыр 1795 елда үткәрелгән ревизия вакытында авылда 148 «башкорт» көн күрә. 1905 елда 546 кеше яши.

1859 елда 10 нчы җанисәп үткәрелгән чагында Чөгәнә вәкилләре элек Бөре өязендә Гәрәй волостеныкы булып исәпләнгән җирләрдә үз бабаларының да вотчинниклары булуы турында искәртә һәм моны раслап, хәтта **1689** елда бирелгән грамотаның копиясен дә чыгарып сала. Тик 170 ел үтеп киткәннән соң бичара татарны кем тыңласын инде?!.

Чирү – Байлар волостеның Калмаш түбәсе составында. **XVII гасырда** нигезләнгән. 1795 елгы ревизия вакытында авылның 19 йортында 136 «башкорт» – җир хуҗасы яши. 1834 елда халык саны 306 «башкорт»ка, 30 типтәргә җитә. Гәрчә барча Солтановлар нәселе Байсар янындагы Мәчти авылында яшәп ятса да, олуг түрә – кантон башлыгы Баязит Габделҗәлил улы менә шушы Чирүдә гомер итә. 1905 елда инде бу авылда 624 кеше яши.

● Актаныш һәм Татарстан горурлыгы Әлфия Авзалова һәйкәле.

Шәбез – Йәнәй волостеның Камбарка түбәсенә буйсына. Тарихи документларда тәүге тапкыр **1685** елда ук телгә алына. Бактың исә, Шәбез авылыннан Мәскәү һәм Әтәк Хуҗалаевлар, шулай ук тау ягы татары Алешка Бабаков (?) Себер юлындагы Кущин волостена бара (ә бу соңыннанрак Пугачев бригадир-генералы булачак Бәхтияр Канкаев туган Олы Ака, шулай ук янәшәдәге Урта Ака, Әзекәй, Кызылбай, Габдулла авыллары урнашкан төбәк) һәм андагы Бакый Акбулатов атлы «башкорт» аларга үз вотчинасында төпләнергә ирек бирә... 1723 елда Семиостров-Өшәр вәкилләре белән бергә Шәбез «башкорты» Кинҗәкәй Җияшев Каракүл крестиянарына Янәү күленең яртысын һәм тагын вак-төяк 7 күлне 49 сум бәядән 10 ел буе файдалану өчен арендага бирә. 1746 елда Шәбезнең 3 «башкорты» Кама елгасының биек ярлы ягындагы үз вотчиналарын дәүләт крестияннарына елына 70 тиен бәядән 20 ел буе файдаланурга тапшыра. 1757 елда Суыксу һәм Шәбез «башкортлары» Йәнәй волостендагы бер биләмәләрен Сарапул крестиянарына елына 2 шәр сум хактан 20 ел буе файдаланырга бирә башлый. Шул ук елда шушы ике авыл вәкилләре Саклау күлен дә елына 10 сум бәядән 20 елга Каракүл крестиянарына арендага бирә.

Аңлашыла булыр, Шәбез вотчинниклары кысан яшәми. 1795 елда ук бу авылның 27 йортында 187 «башкорт» «гөрләп» гомер итә. 1834 елда халык саны 325 «башкорт»ка җитә. Имана җирләренең аз булуы һәм өстән кысу мәҗбүр иткәндер, 1859 елда, тирә-юньдәге туган-кардәшләрен дә чакырып, 411 «башкорт» һәм 10 типтәр Уфа өязенең Кызылъяр авылына (Нариман районында) күчеп китә. 1902 елгы җанисәп вакытында Шәбездә үзләрен һаман хәрби хезмәттә санаучы 231 кеше гомер итә.

Шәрип – Гәрәй волостеның Әҗәкүл түбәсе составында. Тарихи документларда тәүге тапкыр **1758** елда, башлыгы старшина Коңгыр Мутин булган Гәрәй волостеның Җияш, Теләкәй, Мерәс, Куян, Әҗәкүл, Актанышбаш вәкилләре белән бергә Шәриптән Ишгали Бикбаев һәм Мансур Азаматовның да Әҗәк күлен елына 26 сум хактан 15 елга арендага бирүләре турында килешү төзүләре уңаеннан искә алына. 1795 елда Шәрипнең 15 хуҗалыгында 90 «башкорт» яши. 1870 елгы җанисәптә шәрипләр – типтәр, 1902 елда «башкорт» булып языла. 1905 елда 123 йортта яшәүче халык саны 602 кешегә җитә.

Ямалы – Гәрәй волостеның Такталачык түбәсенә буйсына. 1795 елда 13 йортта 87 «башкорт» яшәве ачыклана. Өч елдан соң 11 нче «башкорт» кантонының 14 нче йорты составына кертелә, соңрак авылның 160 «башкорты» төрле вазифалар үтәүгә тартыла. 1896 елда авыл икегә аерыла һәм Татар белән Чирмеш Ямалыларына бүленә. 1912 елда Татар Ямалысында 123 йортта 625 «башкорт» вотчиннигы, Чирмешнекендә 76 татар типтәре яши.

АВЫЛЛАРЫ

● **Березники каласында легендар батырлар булып танылган Мирсәет Арбуанов һәм Мифтах Солтанов хөрмәтенә стенд.**

● **Актаныш район хакимияте бинасын аның янына куелган ат һәйкәле бизи.**

Элекке тарихи документларда кайвакыт Идел Ямалысы дип искә алынган авыл белән янәшәдә Удмуртиянең Кыяз районында XIX гасырда барлыкка килгән Таужамал авылын искә алырга мәҗбүрбез. Безгә калса, аның дөрес исеме «Тау Ямалысы». Ул да, нәкъ менә Татар белән Чирмеш Ямалысына бүленгән шикелле үк, 150-160 еллар элек Идел Ямалысы авылыннан аерылып киткәндер. Ул хәзер яшәгән төбәктә, чыннан да, авыллар бер-берсе өстенә атланып утырмаган, аннары Тау Ямалысы һәм аның күршесендәге Байсар авылы элек Йәнәй волостенда булып исәпләнгән вотчина җирләренә барып урнашкан, ягъни, рөхсәт сорап, йөз суы түгеп йөрү дә һич мәҗбүри булмаган...

Хәзер безнең авыллар янәшәсендә урнашкан берничә төбәк исемен өстәсәк тә була, алар безнең төбәктәге бистә-салаларның кайсы заманда нигезләнгән булуын исбат итә. Байсардан 15 чакрымда урнашкан Әмәкәй авылы – Бүләр волосте составында кергән, ул вотчинлыкка грамотаны **1687 елда** алуга ирешкән. Аның күршесендә, әмма һаман шул ук Бүләр волосте составында исәпләнгән Баек авылы «башкортлары» власть ияләре каршында үз бабаларының инде **1728,** 1737 елларда ук сусар тиресе һәм һәрбер морҗа өчен дүртәр тиен типтәр ясагы түләп торуларын аларга язып бирелгән квитанцияләр белән исбатлаган. Бәкәбез (Бәк абыз!) авылы «башкортлары» 1781 елда Бүләр волосте старшинасы Муса Мөслимовка буйсынып гомер иткән, шул елда алар Нәдер волостеннан күченгән Әбҗәлил Сәетовны, ә бер ел узгач, Адай авылыннан килгән 8 типтәр гаиләсен үз вотчиналарына яшәргә керткән. Әмәкәй авылына терәлеп торучы диярлек Сөякәй авылыннан Бикмәт Ишмәтев атлы кешенең 1695 елда стольник Д.И.Молоствов командасында Азов походында катнашуы мәгълүм, димәк, авыл ким дигәндә **1680** елда ук «чәчәк» аткан инде. Бүген Мөслим районында, элек Бүләр волостенда саналучы Имәнче-Мөшегә – **1657**, Исәнсеф һәм Чәчер – **1683**, Уразмәт белән хәзер инде юкка чыккан Сөендек авыллары **1658** елгы, Октябрь инкыйлабыннан соң Башкортстанның Илеш районына күчкән Сеңгерән авылы **1664** елгы документларда телгә алына. Хәзер Илеш районында, элек Бүләр волостенда саналган Исәммәт, Торачы, Җәйләү, Аккүз, Кадер, Кыпчак ... авылларының барчасы да 1700 елга кадәр нигезләнгән була.

Тат.Бүләр авылын сөйләм барышында алда да телгә алдык. Ул тарихи документларда **1664** елда ук, Минзәлә төрмәсендә якташлары Теләнче Байҗегетевнең аманат-тотык итеп тотылуы уңаеннан теркәлә. Аның янәшәсендәге Мари Бүләре (Иске Бүләр) дә **1642 елдан** бирле яшәп ята.

Бүләр волосте составында исәпләнгән Исәнсеф, Колын, Качкын, Түке, Усы авыллары бүләрлеләргә **1683,** 1701 елларда бирелгән вотчиналык грамотасы нигезендә үсеп чыга. Бүген район үзәге булып торучы Мөслимгә терәлеп торучы Метрәй авылы крестияннарының бер өлеше үзләрен Байлар волостеның Салагыш авылыннан күчеп утырган «асабалар» дип саный. Ә Мөслим янәшәсендәге Салавыз-Мухан авылы «башкортлары» үз бабаларының бирегә **1701 елда** Байлар волостеның Сарайлы-мең (әүвәл бүгенге Алабуга, соңрак Сарман районы җирләрендә) биләмәләреннән күчеп килүен раслый.

Бүләр волосте составындагы Уразмәт авылы янындагы Сәет 1737 елда, 1735 елда Акай Күчемов җитәкчелегендә башланган фетнә барышында, Бөрҗән волостеннан ук килеп җиткән башкорт отрядларының аларны кулга алуы һәм Ык елгасы башланган урыннарга кадәр алып китүе уңаеннан телгә алына, Ходайның рәхмәте белән әсир итеп алынучылар качып котыла.

Элек Бүләр волосте составында, хәзер Мөслим районында исәпләнүче Симәк авылын искә алу да урынлы. Шушы Мөслим районында туган бер шәкерт 1700 еллар тирәсендә бүгенге Әгерже районының Салагыш авылында эшләүче мәдрәсәсенә барып эләгә. Кайсы яктан килүен сораштыргач, ул «безнең як томана, караңгы, анда укый-яза белүчеләр дә юк», дип җавап бирә. Мәдрәсә мөгаллиме Симәк Әлмәкәев түзеп кала алмый, «юк, безнең бер генә төбәктә дә укый-яза белмәүче, томана татар калырга тиеш түгел», дип җавап кайтара. Күп тә узмый, үзенең улы Кадермәт белән ул Мөслим төбәгенә күчеп килә һәм Кыпчак елгасы буенда Симәк авылын, ә анда мәдрәсә нигезли. 1763 елда инде вафат була, кабер ташы исән.

Элек Ирәкте волосте составындагы, бүген Мөслим районындагы Тәмьян авылы урыс документларында янәшәсендә Иштирәк (соңрак Ольга авылы) бакыр коюу заводы һәм Тәмьянда бакыр рудниклары төзелү уңаеннан гына телгә алына. Гәрчә 1684 елда Агыйдел буендагы иң эре вотчинник һәм 1681 елда үзе үк кузгаткан восстание башлыгы Теләкәй морза дар агачына асып үтерелгәч, аның улы Күчем этисе калдырган биләмәләреннән мәхрүм ителә, аңа шушы Тәмьян авылы «башкортлары» типтәр сыйфатында Ык буена килеп урнашырга рөхсәт бирә. Күчем Теләкәй улы Ык елгасының уңъягындагы тау өстендә үз утарын нигезли. 1719 елда баскыннар юллаган җанкыярлар Күчемне суеп үтергәч, аны Тәмьян авылы зиратына җирлиләр. Безнең якта гасырлар буе зыян-зәүрәт күрмичә басып торырдай мәрмәр ташлар да юк шул. Күчем батыр кабере өстенә куелган комлы ташны ике метр тирәнлектән казып чыгарсак та, анда Корьән сүрәсенең ике-өч сүзеннән башка бер мәгълүмат та таба алмадык. Ә Күчем морзаның улы Акай батыр язмышы тагын да аянычрак. Йәнәй волосте «башкорты» саналган Акай Күчем улын Тәмьян волосте «башкортлары» 1730 елның февраль аенда үз биләмәләренә күчәргә рөхсәт бирә. Акай Ык елгасының сул ягында, Ногайбәк крепосте каршындагы зур күл буенда яңа авыл нигезли, аны Акай Күле дип йөртәләр. Акайны 1737 елда әсирлеккә эләктергәннән соң, фетнәчеләрнең коткаруыннан куркып, Петербургка тикле алып китәләр һәм шундагы Шлиссельбург крепостенда дар агачына асып, 1738 елда әрәм итәләр. Шул ук елда карательләр Акай Күле авылындагы барлык татарларны йортларыннан куып чыгара, ә алар хуҗалыгына килмешәк урыс гаиләләре кертеп тутырыла. Акай күле Рус Шуганы атын алып яши башлый...

Бүләр волосте составында саналган Теләнче (хәзер Октябрь) авылы урыс документларына 1750 еллар тирәсендә генә барып керсә дә, ул **1664 елга кадәр** үк нигезләнгән булып саналырга хаклы. Бүләр авылыннан алып кителгән һәм Минзәлә төрмәсендә 1664 елда аманатлыкта тотылып азат ителгән Теләнче Байҗегетевнең шул елларда үз исемендәге авылны нигезләве мөмкин.

Тәмьян янындагы, безнең төбәк өчен бик тә истәлекле булган Тугаш авылын да телгә алыйк. Биредә яшәүче Ирәкте вотчинникларының 1756 елда Уса юлыннан килгән типтәрләрне үз биләмәләренә кертүе теркәлгән. Шушы ук авылда 1760-1812 елларда гомер иткән Чуракай Тугашев атлы кешенең исеме дә билгеле, ә бу исә авылны аның этисе Тугаш нигезләгәндер, дигән нәтиҗәгә этәрә. Ләкин... тарихи дастаннарда 1395 елда Алтын Урданың Болгар әмирлеге җирләренә Аксак Тимер бәреп кергәннән һәм әмир Габдулла хан-Карабәкне Болгар каласында җәзалап үтергәннән соң Алабуга янында кышлауга калуы тасвирлана. Ял вакытында ул Тугаш би һәм Бигеш би янында да кунакта булган, имеш. Аксак Тимер декабрь аеннан мартка тикле беркая да чыкмыйча гына яши алмагандыр. Әгәр Тугаш би белән Бигеш бине реаль персонажлар итеп искә алабыз икән, аларның, чыннан да, бүгенге аэропорт янындагы яки Мөслим янәшәсендәге тирмә-авыллар булуы да мөмкин бит. Димәк, ул тарихи дастаннарның да реаль нигезе бар...

Аерым тукталып, элеккеге Кыргыз, Йәнәй, Гәрәй, Бүләр волостьларына буйсынган авыллардан бер котылгысыз бәла – җир җитмәү сәбәпле бүгенге Башкортстан районнарына күченеп китәргә мәҗбүр булган туганнарыбыз турында да сөйләргә кирәк иде. Мондый күренеш элеккеге гасырларда да бик еш кабатланып торган, ә XVIII гасыр уртасында гаҗәеп колач алган. Массакүләм күчеп китүләрнең берничә мисалын гына саныйк. 1740 елларда ук Бүләр волостеның Качкын, Усы, Шәбез, Түке авылы крестияннары Уфа провинциясенең Кыр-Елан волосте (хәзер Ярмәкәй районы) җирләренә барып төпләнә һәм анда Исламбакты авылын нигезли. 1760 елда Әнәктән – 6, Пучыдан – 4, Чәчердән – 4, Туердан – 3, Тузганабикәдән – 3, алардан тыш әле тагын 5 авылдан бер-икешәр гаилә бүгенге Әлшәй районындагы Торынтаеш авылына күчеп утыра. Аларның яңа җирдә бик уңай тернәкләнеп китүе турында хәбәр алуга ук, Бүләр волостеннан 1762 елда янә 152 ир Торынтаеш авылына күчеп төпләнә. 1763 елда инде алар үрнәгенә Җизмыек, Иске Җияш авылы ирләре дә ияргә, алары хәзерге Нуриман районындагы Кызылъяр, Шиде, Торбаслы, Байкилде, Бикморза авылларына күчеп урнаша. Бер гасыр узуга, 1859 елда шул ук Кызылъярга Аеш авылыннан – 173, Шәбездән – 411 «башкорт» һәм 10 типтәр, хәзер Мөслим районында саналучы Исәнсефтән 129 ир-ат һәм 109 хатын-кыз, Усыдан – 38, Карачтан – 61, Качкыннан 28 кеше күчеп китә. Һаман да шул Усы, Илтимер, Качкын, Түке, Исәнсеф крестияннары – Башкортстанның Кырмыскалы районындагы Сарт-Нәүрүз, ә Урьяды, Буранчы, Адай авылларыннан күчкәннәр Иске Шәрәй авылына килеп утыра. Тора-бара Сарт-Нәүрүздәге актанышлылар, тәүге яңа нигездән аерылып, биш чакрым читтә, һаман да шул Агыйдел елгасы ярында Сарт-Чишмә авылын нигезли. Ни гаҗәп, урындагы «юлбашчылар» яңа авыл урамнарына совет заманында «Совет» яки М.Гафури исемен кушып караса да, авыл урамнары һаман элеккечә – Илтимер, Түке, Усы урамнары булып йөри. Юл уңаеннан санау барышында гына да без Башкортстан районнарында Байсар, Сәфәр, Чуракай, Исәнбай, Эсләк, Богады, Гәрәй, Актанышбаш, Карт ... шикелле үз исемнәрен саклаган авылларны да санап уздык, ә асылда алар дистәләгән. Без, махсус рәвештә, сезгә Сөн, Ык, Агыйдел елгаларының каршы ярына күченгән авылларны түгел, ә 1922 елдан соң Зур Башкортстанга әверелгән җөмһүриятнең иң түренә үк урнашып утырган Актаныш авылларының бер өлешен санап чыктык. Безгә, иң беренче чиратта, менә шулар белән туганлык җепләрен яңартасы иде.

Вахит ИМАМОВ.

Файдаланылган әдәбият:
Т.Кәримов. Бүләр, Гәрәй, Йәнәй волостьлары тарихы. Кулъязмалар.
Ә.Әсфәндияров. Аулы Мензелинских башкир. Уфа, 2012.
История башкирских родов. Гирей. Уфа, 2016.

Мәдәни җомга
22 сентябрь
№37, 2023

Мәтәскә

Казан артында хәзерге Арча районына керә торган ике Мәтәскә авылы яшәп килә: аның берсе – Югары, икенчесе – Түбән Мәтәскә. Е.И.Чернышев Казан ханлыгы авыллары исемлегендә Мәтәскә атамасы кергән сигез авылны атый. Гадәттә, исемнәре охшаш авыллар арасында якын бәйләнеш була, ул йә территориаль яктан, йә нәсел туганлыгы белән дә билгеләнергә мөмкин. Халык риваяте буенча, Түбән Мәтәскәне нигезләүчеләр Югары Мәтәскә авылы кешеләре булган, ә Югары Мәтәскә җирләренә килеп авыл булдыручылар – хәзерге Теләче районының Олы Мәтәскә кешеләре [Гарипова, б. 650 – 652]. Е.Чернышев күрсәтүенчә, бу авыллар Казан ханлыгы чорында ук яшәгән, әмма аларның нигезләнүе күпкә иртәрәк булуы да ихтимал. Кызганыч ки, моны документ белән раслау мөмкинлеге юк. Арча районына керә торган Югары һәм Түбән Мәтәскә авыллары гомер-гомергә бергә яшәгән, аларга бүлеп бирелгән җирләре дә уртак булган.

● Туган як буйлап велосипедта походлар ясадык.

1793 елда уздырылган ызанлау вакытында бу ике авыл халкын берләштергән игенче общинасына барлыгы 1640 дисәтинә 1936 сажин җир туры килгән, шуның 1594 дисәтинә 2155 сажины – чәчүлек җирләре. XIX гасырның икенче яртысында мәтәскәлеләр файдаланган басулар янәшәсендә эре җирбилүчеләрнең дә хосусый җир кишәрлекләре урнаша. Югары Мәтәскә янында элек алпавытлар А.К.Тюфянов, А.Е.Комаровскийныкы булган җирләр соңрак Арча мещаны И.Я.Горшеновка күчә. Шунда ук сәүдәгәр Гобәйдулла Габдулла улының печәнлекләре була, ул 1874 елның 20 июлендә сатып алган бу җирләрне 1881 елның 8 августында икенче гильдия Казан сәүдәгәре, Арча сәүдәгәре С.И.Кисловка 1000 сум алтынга сатып җибәрә. Шифалы үләннәр үстергән С.Кисловны җирле халык үләннәр белән дәвалаучы табиб буларак әле дә хәтерендә саклый, бу җирләрдә хәзер инде чытырманлык булса да, халык ул урыннарны «Кислов дачасы» дип атый. Түбән Мәтәскә авылы янындагы 63,5 дисәтинә җир кишәрлеге И.И.Аппаковныкы була. Анда тегермән дә эшли.

Мәтәскә халкы, нигездә, җир эшкәртеп көн күргән, кышкы сезонда, өстәмә табыш алу максаты белән, халык башка һөнәрләр белән шөгыльләнергә тырышкан, читкә китеп бәхет эзләүчеләр дә булган.

Тарихи яктан Югары Мәтәскә алданрак нигезләнгән булса да, XIX гасырда кеше саны, икътидаси мөмкинлеге ягыннан Түбән Мәтәскә өстенлек ала. Бу – Себер юлы тракты өстендә урнашкан Түбән Мәтәскәдә почта станциясе төзелү белән бәйле. XIX гасыр ахырындагы рәсми документлардан күренгәнчә, авылның 7 крестьяны ямщик хезмәтендә торган [Материалы.., б. 4-5]. XX йөз башында Түбән Мәтәскә авылының почта станциясе Николай Васильевич Михайлов милкендә була, станцияне карап торучы булып Василий Добрынин хезмәт итә. Биредә почтага хезмәт күрсәтү өчен 16 пар ат тотылган.

Почта йорты Казанның беренче гильдияле сәүдәгәре В.А.Савин тарафыннан төзелә. 1825 елгы тасвирламада бу йорт түбәндәгечә сурәтләнгән: «Озынлыгы тугыз сажин һәм бер аршин, киңлеге җиде сажин һәм бер аршин булган кирпич фундаментлы бер бина. Түбәсе кызылга буялган калайдан». Бина алты бүлмәдән торган, мич белән җылытылган. Йортка керә торган ишек башына зур «А» хәрефе һәм дә ике башлы бөркет сурәте куелган була. Утарда ямщиклар өе, кирәк-яраклар саклау бинасы һәм ат абзары урнашкан [Из истории..., с. 51]. XX йөз башында Казан губернасында 8 почта станциясе булса, шуларның икесе Казан өязе Түбән Мәтәскә һәм Карадуган авылында урнаша. Авыл аша почта юлы үтү бер яктан отышлы булса, крестьяннар өчен акча эшләү мөмкинлеген арттырса, икенче яктан, авыл тормышына тынычсызлыклар да алып килә. 1891 елның 13 декабрендә Карадуган арасы белән Мәтәскә арасын үткәндә берничә кеше, талау максаты белән, почтальоннарның юлына чыга. Талаучыларны куркыту өчен, почтальоннар һавага атарга да мәҗбүр була. Талаучылар урманга кереп кача. Бу хәлдән соң почтальоннарны саклау һәм трактның куркынычсызлыгын тәэмин итүне көчәйтергә диган боерык алына.

Казан арты авылларына хас булганча, мәтәскәлеләрдә дә, җир эшкәртүдән тыш, төрле һөнәрчелек эшләре белән шөгыльләнү киң таралган. Халыкның бер өлеше авылда эшләсә, икенчеләре читкә китеп кәсеп иткән. XIX йөз ахырында Югары Мәтәскә кешеләре тире эшкәртүдән елына 200 сум керем алган, шулай ук татар крестьяны җир эшкәртүдән калган вакытында итек басу, агач эше, урман кисү, читән үрү, йон эшкәртү, пыяла кою белән дә шөгыльләнгән. Тегүчеләр, авылдан-авылга йөреп, заказга кием теккәннәр. XIX йөз ахырында Югары Мәтәскә авылында тирә-якта танылу алган зәркәнче яшәгән, аның көмештән ясаган бизәнү әйберләре сәнгать югарылыкта булган. Шулай ук, Югары Мәтәскәнең ике атаклы миччесе булуы билгеле. Түбән Мәтәскә авылы миччеләренең исемнәре дә тарихка кергән, алар – Әхмәтша һәм Сиражетдин Әхмәдиевләр. Түбән Мәтәскәнең бер кешесе төрле татлы ризыклар, хәлвә әзерләп, Казан шәһәренә илтеп сату иткән. Авылларда умарта тотучылар да була, бу – табигать шартларына карап, төрле елда төрле күләмдә гаилә казнасына күпмедер табыш керткән. Мисал өчен, XIX йөз ахырында Югары Мәтәскә авылында 11 гаиләнең умарта тотуы билгеле. Үзләреннән арткан товарны базарда сатудан кергән акчаны гаиләне тоту, салым түләү өчен файдаланганнар.

Казан артындагы күп кенә авылларга хас булганча, Мәтәскә авылы кешеләре Казан шәһәренең завод-фабрикаларына китеп тә эшләгән, байларда хезмәтчеләр дә булып торган. Вакытлыча кышкы сезонда гына эшләргә килгән татар крестьяннары Казан шәһәрендә яшәп тә калган. Кызганычка, татар крестьяны җәй җир эшкәртеп, кышка кергәч, читкә китеп, мөмкинлеге булганда һөнәрчелек белән шөгыльләнеп яшәсә дә, әллә ни зур байлык җыя алмый. XIX йөз ахыры мәгълүматлары буенча, ике Мәтәскә авылында да йортларның өчтән бер өлешенең түбәсе салам белән ябылган [Материалы..., с. 4 –5]. Шуның өстенә әле 1879 елда Түбән Мәтәскә авылында зур янгын чыгып, 60 йорт янып бетә [Список мест..., с. 7 – 8].

Түбән Мәтәскә авылында көндәлек кирәк-ярак сату өчен кибет (лавка) тотучылар да була. 2 кибет хуҗасы Мәгъриф Халитова һәм Ногман Шакиров үз авылы кешеләре булса, Нәбиулла Хәйбуллин – чыгышы белән Наласадан [ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 2243 эш. 207–226 кгз.]. Түбән Мәтәскә кешесе Гайнетдин Шәмсетдинов Казиле авылында Арча мещаны Дмитрий Федорович Кустовтан су белән эшләүче тегермән арендалап торган. Югары Мәтәскәдә дә Ия елгасы буенда бер су тегермәне эшләгән [Список населенных мест…, с. 156–157]. Түбән Мәтәскә авылы янындагы Аппаков дачасында бер кәгазь җитештерү «фабрикасы», бер вак-төяк сата торган кибет һәм бер тимерчелек алачыгы эшләп торган [Список мест..., с. 159].

● Түбән Мәтәскә авылы мәчете.

Югары һәм Түбән Мәтәскә авыллары халкы тулы рухи тормыш белән дә яшәгән. Халыкның уртак бәйрәмнәре, җыеннары булган. Ике Мәтәскә авылы да Казан артының «Күкчә җыены»на караган, аны икенче төрле «Кыр җыены» дип тә атап йөрткәннәр. Монда Мәтәскә авылларыннан кала, Өчиле, Бирәзәбаш, Урта Бирәзә, Югары Әзәк, Түбән Әзәк, Мөндеш, Кәче, Күкчә-Бирәзә авыллары кергән [Гарипова, б. 652].

Мәтәскә авылларында мәчетләр борын-борыннан эшләп килгән. Авыл халкы аның кайчан салынганын да белми, гадәттә, авыл нигезләнү белән үк мәчет ачыла торган була. Алдан ул гадәти бер йорт рәвешендә булса, халыкның мөмкинлеге булуга, манаралы бина итеп зурайтылган. Мәчетләрне җимергән тарихның караңгы бер чорында, XVII–XVIII йөзләр чигендә, 20 хуҗалыгы булган Югары Мәтәскә авылының мәчете юк ителә, ә шулай ук 20 хуҗалыктан торган Түбән Мәтәскә авылы мәчетенә кагылмыйлар. Кабат Югары Мәтәскә авылында кайчан мәчет салынуы билгеле түгел, XIX йөзнең уртасында авылда бер мәчет эшләгән, бу мәчет мәхәлләсе үз эчендә 189 ир-атны, 174 хатын-кызны берләштергән. 1857 елдан башлап мәчетнең имам-хатыйбы булып Хөснетдин Шәмсетдинов торган [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 8 эш. 69 кгз.], 1866 елдан аны Таип Фәхретдинев алыштыра [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 273 эш. 253б – 255 кгз.].

Таип Фәхретдинев Түбән Мәтәскә авылы имамы Мөхәммәдшакир Хәләфев, Күпербаш мулласы Камалетдин Нәҗметдинев, Кармыш-Казанбаш авылының Мөхәммәдситдыйк Хафизов белән берлектә мәхәллә кешеләренең милкен бүлүдәге хилафлыклары өчен гаепләнә, алар өстеннән Диния назарәтенә шикаять керә [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 6781 эш. кгз. 18]. 1897 елгы материаллар буенча, Югары Мәтәскәдә имам урыны буш торган, имамның, югарыда аталган сәбәп аркасында, эштән азат ителгән булуы ихтимал. 1898 елда Югары Мәтәскә авылына имам-хатыйб булып Казан өязе Казиле авылы кешесе Габделхак Гатаулла улы мәдрәсәсен тәмамлаган Әухәди Мифтахетдинев (Указы 1898 елның 6 октябреннән) килә [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 734 эш. 236 кгз.]. Аннан соң аны Мөхәммәди Мифтахетдинев (Указы 1904 елның 6 октябреннән) алыштыра [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 8464 эш. 54б– 55 кгз.].

Авылның яңа җәмигъ мәчете 1856 елда төзелә. Озынлыгы 5 сажин булган мәчетнең намаз укый торган өлеше 3 сажин, ә калганы – керү, кием һәм аяк киемнәрен

авыллары тарихы

● Югары Мәтәскә авылы урамы.

● Югары Мәтәскә авылы мәчете.

калдыра торган урын. XX йөз башында 78 хуҗалыгы булган авылда мәчеткә йөрүче кеше саны 150 гә житкән [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 7606 эш. 5 кгз.]. Элеккеге мәчет инде бу кадәр халыкны сыйдыра алмый башлаган. 1906 елның 23 февралендә мәхәллә халкының мәчетне зурайту һәм ремонтлауга рөхсәт сорап язган үтенеченә уңай җавап алынган. Элеккеге мәчет бинасы 9 сажинга кадәр озынайтылган, һәр якка өчәр тәрәзә өстәлгән һәм михрабка да тәрәзә куелган. Мәчет түбәсе калай белән капланган. Шулай ук мәхәллә халкы исәбенә мәчет бинасы тулаем төзекләндерелгән [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 7606 эш. 5 кгз.].

Түбән Мәтәскә авылы мәчетендә 1841 елдан башлап Мөхәммәдхәләф Сөләйманов (билгеләнү турында указы 1841 елның 17 июненнән), аннан аның улы – Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхәләфев (1873 елның 30 ноябреннән) хезмәт иткән. 1895 елдан бу вазифаны Сәлахетдин Гыймадетдинов (1895 елның 18 июненнән), Мөхәммәдфатыйх Мөхәммәдшакировлар ала (1905 елның 5 мартыннан). Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхәләфев бер үк вакытта Күтернәс авылы мулласы вазифасын да үти. Ихтимал, Күтернәс авылы кечкенә авыллардан булып, аларның аерым мулла тоту мөмкинлеге булмаган, бу авыллар арасы бик якын булганга, алар бер мәхәллә исәпләнгән булса кирәк [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 1887 эш. 302б – 303 кгз.]. Соңрак Күтернәс авылы халкына Күпербаш авылы мулласы хезмәт күрсәтә башлый. Мөхәммәдфатыйх Мөхәммәдшакиров (ул Мөхсин фамилиясе белән дә билгеле) 1871 елда туган, Казиле авылында Габделхак хәзрәттә белем алган, ә Сәлахетдин Гыймадетдинев (Ишморатов) Казан өязе Түбән Ядегәр авылыннан, Малмыж өязенең Күшкетбаш мәдрәсәсендә белем эстәгән. Сәлахетдин мулла авыл җәмәгатьчелегендә үз гамәлләре белән ризасызлык уята, аның хөмер эчүе дә, мәхәллә әгъзаларыннан акча алырга яратуы да халыкның ачуын кабарта. 1903 елның 10 октябрендә авыл җәмәгатьчелегенең зур күпчелеге аны вазифасыннан азат итәргә, муллалыктан алырга дигән карарга килә [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 6870 эш.4 кгз.]. Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхәләфев тә Югары Мәтәскә, Күпербаш, Кармыш-Казанбаш муллалары белән бергә гаилә малын канунсыз бүлүдә гаепләнә, әмма аларның гаепләре расланмый. Бу – алар өстеннән дошманнарының донослары гына булырга тиеш.

Казан арты авыллары үзләренең мәдрәсәләре белән данлыклы була. Уку-укытуның куелышы, шәкертләр әзерләү ягыннан Курса, Кышкар мәдрәсәләреннән калышмаган, татар җәмгыятендә абруйлы мәдрәсә Түбән Мәтәскә авылында да эшләп килгән. XIX гасырның 80 нче елларында Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхәләфев 15 ир баланы укыта, шул вакытта 17 кыз да дин дәресләре ала. Сәлахетдин Хисаметдинов укыткан 90 нчы елларда шәкертләр саны 34 кә җитә, әмма мулланың югарыда әйтелгән кырын эшләре аркасында, шәкертләр саны кинәт кими [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 5568 эш. 32б – 38 кгз.]. Әлеге мулладан соң билгеләнгән Мөхәммәдфатыйх Мөхәммәдшакиров мәдрәсәнең авторитетын бик тиз кайтара, ул эшләгән 3 ел эчендә шәкертләр саны 20 дән 42 гә җитә, ә гадәттә еллар дәвамында укучы кызларның саны тотрыклы рәвештә 17–18 кеше булса, ул эшләгәндә кызларның саны да 36 га җитә. Бу казанышлар – әлбәттә, мөгаллимнең зур хезмәте һәм абруе нәтиҗәсе. Мулла, мөгаллимнең янында булып, җәмгыятьнең анасы булачак кызларны укытуда, аларны тәрбияле, белемле итүдә абыстайларның фидакяр хезмәтен аерым билгеләргә кирәк. Татар авылында белем бирү, мәктәп-мәдрәсә тоту һәр имамның бурычы саналган, бу бурыч күңел ихтыяҗы белән эшләнгән, һәр авылның мулла, мөгаллим, абыстайлары – татар җәмгыятенең үсешен булдыручы төп көчләр.

Мәтәскә авылларының тарихы икәнен күрсәтүче тагын бер чыганак – ул таш билгеләр, кабер ташлары. Сәнгати дәрәҗәдә эшләнгән кабер ташлары тарихы зур булган, маллы кешеләр көн күргән, югары рухи тормыш белән яшәгән авылларда сакланып калган. Түбән Мәтәскә авылы зиратында XVI йөз урталарында ук куелган кабер ташлары безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Каберташ язмалары белгече А.Гайнетдинов Түбән Мәтәскә авылында тарихи яктан игътибарга лаеклы 9 кабер ташын күрсәтә. Шулар арасында иң борынгы кабер ташлары 1541–1542 елларга карый, алар – Аман хуҗа Кунак Хуҗабай улына һәм Җаян хуҗа Кунак Хуҗабай улына куелган ташлар. Кызганычка, Түбән Мәтәскә имамнарына куелган барлык кабер ташлары да сакланып калмаган, әмма XX йөз башында бу авылда имамлык иткән дамелла Мөхәммәдфатыйх мулла Мөхәммәдшакир улы Яхинга (имамлыкка Указы 1905 елның 5 мартыннан) 1934 елны вафатыннан соң куелган таш Түбән Мәтәскә авылының тарихи ташлары рәтендә тора [Гайнетдинев, б. 231 – 233]. Үкенечкә, Югары Мәтәскәдә тарихи ташлардан бары тик берсе генә ачыкланып, аның 1915 елга караганлыгы билгеләнде [Гайнетдинев, б. 333]. Каберстан татар җәмгыятендә һәрвакыт тарихның үзе итеп кабул ителгән, зиратлар тәртиптә тотылган, чистартылган, кабер ташларына сак карарга тырышканнар. Түбән Мәтәскәнең кәгазьдә саклау мөмкинлеге булмаган чорда үз тарихын ташларда саклап кала алуы – бу авыл кешеләренең хөрмәткә лаек булуы хакында сөйли.

Татар җәмгыятенең рухи тормышы, мәгариф һәм мәдәният үсеше, тарихи сәбәпләр аркасында, авыл җирлеге белән бәйле. Шунлыктан, татар тарихын өйрәнүдә аның һәрбер авыл тарихы мөһим. Һәр авылның имамы, ул тоткан мәктәп-мәдрәсәсе татар дөньясы томышында, аның үсеш-үзгәрешендә хәлиткеч роль уйнаган.

Эльмира СӘЛАХОВА,
тарих фәннәре кандидаты.
«Фәнни Татарстан» журналыннан.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

23 сентябрь (шимбә). ***Рабигуль әүвәл аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 16.40 сәгатьтә калка, 22.07 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 12.14 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь.

Салкын тигәндә

Салкын тиеп маташканда ук 1 бүлем сарымсак ашасаң, төнгелеккә үкчәгә йод сөртеп, коры горчица салынган йон оекбаш киеп ятсаң, 1 тамчы йод тамызып, ярты стакан су эчсәң, авырмый калу ихтималы зур. Яисә 1 стакан кайнар суга 1 әр аш кашыгы кура җиләге кайнатмасы, бал, лимон согы, 1 аспирин төймәсе салып болгаталар да, төнгелеккә эчеп яталар.

24 сентябрь (якшәмбе). ***Рабигуль әүвәл аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 17.19 сәгатьтә калка, 23.39 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 12.09 сәгать.***

Үзгәрү, катгыйлык көне. Һәр эштә дә игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уяныргa мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Магнитлы көндә

Магнит давыллары тәэсиреннән интеккән кешегә 1 аш кашыгы вакланган кандала үләнен (донник) 1 стакан кайнар суда 1 сәгать төнәтеп, сөзәргә, көненә 2-3 тапкыр яртышар стакан эчәргә кирәк. Кандала үләне канны сыегайту үзлегенә ия.

25 сентябрь (дүшәмбе). ***Рабигуль әүвәл аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 17.41 сәгатьтә калка, 1.16 сәгатьтә бата.2 нче фаза. Көн озынлыгы 12.04 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Истә тоту мөһим

Диабеттан интегүчеләргә атнасына 3 йомырка, көненә тавык йомыркасы зурлыгындагы 2 бәрәңге, 3 кисәк арыш икмәге, 1 аш кашыгы үсемлек мае ашарга ярый. Ашарга ярты сәгать кала 1 стакан кайнамаган су эчкәндә, ашказаны асты бизенең юллары чистара һәм инсулин бүленеп чыгу арта. Инсулин ачылганчы, табибләр шикәр авыруыннан интегүчеләргә ач яки ярымач (бер генә төрле ризык, мәсәлән, гел солы боткасы гына ашап) торырга куша торган булган.

26 сентябрь (сишәмбе). ***Рабигуль әүвәл аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 17.56 сәгатьтә калка, 2.56 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 12.00 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга яра-

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

мый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь.

Ютәлдән – банан

Чистартып, кисәкләргә бүленгән бананны, бераз какао порошогы сибеп, блендерда издерәләр, 1 стакан кайнаган сөт кушып, тагын күпертеп алалар. 1 чәй кашыгы бал кушсаң, файдасы тагын да күбрәк була. Көненә бер тапкыр, йокларга ятар алдыннан, кайнар килеш эчәләр. Дәва курсы – 1 атна.

27 сентябрь (чәршәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,18.07 сәгатьтә калка, 4.13 сәгатьтә бата.2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.55 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Фейхоа сихәте

Фейхоа йодка бай, шунлыктан аны калкансыман бизләрендә проблема булган кешеләргә, шулай ук киеренке акыл эшчәнлеге таләп ителгәндә куллану яхшы. Анда С витамины да цитрус җимешләрендәге кадәр. Бу җиләк кандагы зарарлы холестерин микъдарын киметә, атеросклероздан, стресстан саклый. Фейхоаны иттарткычтан чыгарып, шулкадәр үк микъдарда шикәр йә бал кушалар, суыткычта саклыйлар. Кан басымын нормага китерү өчен, көненә 3 тапкыр 1 әр чәй кашыгы кабалар.

28 сентябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 18.16 сәгатьтә калка, 4.33 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.50 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына биргәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Кабак тынычландыра

Төнлә йокларга ятар алдыннан 1 стакан кабак согы эчү нерв системасын тынычландыра һәм йокыны яхшырта. Кабак согы кариесны кисәтү өчен дә яхшы чаралардан санала. Халык медицинасында кабак С гепатиты белән чирләгәннән соң тулысынча сихәтләнү өчен дә кулланыла – аны, пешереп, мөмкин кадәр күбрәк ашарга кирәк.

29 сентябрь (җомга). ***Рабигул әүвәл аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 18.24 сәгатьтә калка, 6.05 сәгатьтә бата. 12 сәгать 58 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 11.46 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр тәэү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Файдалы кәнфит

1 әр стакан күрәгә һәм йөзем, 2 аш кашыгы солы ярмасы (хлопья), 3 аш кашыгы төелгән чикләвек кирәк. Күрәгә һәм йөземне яхшылап юып, бераз кипшендергәч, коры табада бераз кыздырып алынган солы ярмасы белән бергә иттарткычтан чыгаралар, шарчыклар ясап, чикләвектә әвәлиләр, суыткычка куеп торалар.

Гаилә дәресләре

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе директорының беренче урынбасары, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин рус телендә «Гаилә дәресләре» исемле китабын чыгарды. Ничек дөрес талашырга? Исламда контрацепция кулланырга ярыймы? Никах, бала табу, исем кушу, килен-кайнана мөнәсәбәте, хәтта аборт – Рөстәм хәзрәт күтәргән фикерләрне санап бетермәле түгел.

Китап яшь гаиләләргә, гаилә корырга җыенучыларга адресланган. Китап мөселман булмаган татар һәм рус гаиләләрен дә истә тотып әзерләнгән. Китапны тәкъдир иткәндә Рөстәм хәзрәт гаиләгә кагылышлы сорауларга җавап бирде. Журналистлар арасында 1-2 генә ир-ат бар иде. Шуңа күрә Рөстәм хәзрәт гаилә кыйммәтләре турында күбрәк яшь кызларга төбәп сөйләде.

«Кияүгә чыкмаган кызлар бармы? Кулларыгызны күтәрегез әле. Кияүгә чыгам дип сайлаган ярыгыз «иң замечательный, суперский»дыр инде. Булачак ирегезгә нинди сораулар бирер идегез? Менә китапның тышында «Ирнең керемнәре – ул гаилә бюджеты, хатынның керемнәре – аның бюджеты» дип язылган. Бу мәсьәләне булачак ирегез белән күтәрдегезме?» – дип үзе үк аудиториягә дистәләгән сорау әченда калдырды хәзрәтебез. Аннан янә дәвам итте.

«Кайда торырбыз?» «Эшләргә рөхсәт бирерсеңме?» – дигән сораулар биреп караганыгыз бармы? Татарстан мөселман республикасы булгач, хәзер ир кеше, намаз укымаса да, өстәл сугып: «Мөселман дине буенча син өйдә утырырга тиеш!» – дип әйтә ала бит. Күз алдыгызга китерегез әле. Никах, язылышу, туй мәшәкатьләре узып китүгә үк бер иртәдә ирегез сезгә: «Элекке эш урыныңны оныт. Өйдә утыр, «удаленка»да эшлә», – дип ярып сала калса, ни кылырсыз?

Яки кияүгә чыктыгыз да, тик шәһәрдә сезгә кулай бер генә эш тә юк, ди. «Әйдә, авылга кайтабыз. Фәлән гектар җир алырбыз, шунда бәрәңге үстерербез. Син 5 сыер саварсың, 10 үгез үстерерсең», – дисә, андый ярга кияүгә барырсызмы? Маникюр, педикюрлар белән...

Менә шушы рәвешле башланган очрашу тиз арада кайнар бәхәс уятты. Килен – кайнана мөнәсәбәтләре – мәңгелек тема. «Китапта ул тема урын алганмы?» – дип сорыйлар.

Дин кайнана белән киленне конкрет рәвештә аңлатып бирә. Олы яшьтәге апа күз яшьләре белән елап килә: «Хәзрәт, килен гел исемем белән эндәшә. Бер дә «әни» дигәне юк», – ди. Авыр булса да, ул – сезнең ирегезне үстергән әни. Ул сезнең ирегезне үстергән, ул «әни» дип әйтелергә лаек. Никахларда кияүдән сорыйбыз, анда сайлау бар: син «әти-әни» дип әйтәчәксеңме, «әби-бабай» дипме? Килентә дин сайлауны бирми. Килен «әни» дип әйтергә тиеш. «Әни» дип әйтү күп мәшәкатьләрне юкка чыгарыр иде.

Кайнаналарга ла нәсыйхәт бирәбез. Никахларда да әйтәм: сез киленгә бик каты «тешләр белән ябышкан» чакта, үзегезне искә алыгыз. Сез дә нәкъ шулай килен булдыгыз. Кайнана сезне дә «ашый» иде. Ул вакытта сезгә ничек авыр булган, хәзер киленегезгә шулай авыр. Кайбер әниләр әйтә: «Мин түздем, ул да түзсен», – ди. Яшьләр әле дөнья күрмәгән. Килен белән әни – аерым кешеләр. Килен беркайчан әнине капламас, әни урынына менмәс. Монда көнләшү дә була ала. Тик хатын ул – хатын, әни – ул башка дәрәҗә кеше. Җәннәт – әниләрнең аяк астында.

Кияүгә чыкмаган, тик дәү әниле йөртә туып, килен – кайнана мөнәсәбәтләрен бәләкәйдән күреп үскән кыз буларак, «Бергә тору тиешме?» – дип сорамый кала алмадым. Рөстәм хәзрәт көлеп куйды.

– Хәзерге кызларның позициясен аңлыйбыз. Электән бер түбә астында берничә буын бергә тора иде. Менә сезгә догаларны кем өйрәтте? Әби. Бергә торуның файдасы күп.

Ләкин хәзерге әбиләр әле әби булырга ашыкмый. Әбиләребез әле әби сыйфатына кермәгән. Бүген генә «хәзрәт, сиңа да кызык булыр, укып ал әле» дип җибәрделәр. 86 яшь әби, бабаен җирли дә, «мин дөньяның тәмен тоймаганмын икән» дип, дустын ала да әллә кайларга ялга киткән, телефонын сүндергән. Кызы анда чүт үлмәде. Әнисе акчасы беткәч кенә телефонын кабызып, «кызым, акчам бетте» дигәч, кызы барып алып кайткан. Әле үзеннән 5-10 яшькә яшьрәк бабай белән танышкан.

Әби булудан оялмасыннар. Үз дәрәҗәсен төшермәсен: ул бит әни, ул бит әби. Олы кеше булган өйдә бәрәкәт бар. Олы кеше белән бергә бер түбә астында яшәү саклланса, безнең талаклар, аерылышулар саны күпкә кимрәк булыр иде. Чөнки олы кеше янында артык эндәшмисең, артык сөйләшмисең, үз-үзеңне кулда тотасың. Аны балалар да күрә.

Әгәр без гаиләләребезне сакларга теләсәк, киләчәктә гаилә институтының булуын телисәк, олы буын белән бергә тору яхшырак булыр иде. Аерым торырга телибез икән, ул безнең нәфесне үстерү генә була, үз комфортыбыз өчен. Ләкин киләчәк буынны тәрбияләүдә әби-бабайларның өлеше бик зур.

Сөйләшү башка төрле юнәлеш алды. Ир-атлар бу китапны укырмы? Рөстәм хәзрәт «оят» дип саналган темага кагылды.

Абортның гөнаһ икәнен беләбез. Тик, гафу итегез, авырга узган саен бала табу да – вариант түгел. Ислам контрацептивлар, ягъни саклану чаралары турында нәрсә ди?

Безне, бу дөньяны Аллаһ Тәгалә яраткан. Бөтен кануннар, вакыт – бөтенесе Аллаһка буйсына. Раббыбыз Сөбхәнәһу вә Тәгалә әйтә: шайтан килеп, сезне ачлык белән куркыта. Бу – бала, баланы өздерү мәсьәләсендә. Россиядә генә, рәсми мәгълүмат буенча, бер елда 1 миллион баланы өздерәләр. Казан халкы кадәр сан бит бу, югыйсә!.. Аллаһ Тәгалә әйтә: «Шайтан сезне ачлык белән куркыта. Тик ризыкны мин бирүче, алар бирми», – ди. Һәр бала үз ризыгы белән килә. Шулай дигәч, кардәшләребез: «Хәзрәт, син беләсеңме, баланы КФУга кертеп укытырга күпме акча кирәк? Мәктәпкә форма, китап, тегесе-монысына күпме акча кирәк. Аллаһ бирәме?» Аллаһ үзе әйтә: «Әйе, мин бирүче». Шуңа күрә, саклану чараларын куллану шул нияттән икән, бу – дөрес булмаган ният. Аллаһ Тәгалә бирер, Аллаһ Тәгалә ашатыр.

Икенче юнәлеш – исәнлек-саулык. Яңа гына бала табып, тагын балага узсагыз, бик авыр булыр. Ул вакытта, әлбәттә, дин ягыннан рөхсәт ителә. Ләкин үзегезгә зыян китерү ярамый һәм баланы өздерү – гөнаһ. Дин баланы өздерүне бер очракта гына рөхсәт итә – әнине сакларгамы, баланы сакларгамы, икесенең берсе үлә, дигән вакытта гына аборт рөхсәт ителә. Башка вакытта ул үтерү дип санала.

Китаптагы «Ничек дөрес талашырга?» дигән җөмләләр дә, ике яклы гафу үтенүләр дә игътибарны җәлеп итте. Аннары яшь парлар яки никах мәсьәләсе турында сүз кузгалса, ике ярның яшь аермалары читтә кала алмый. Пәйгамбәребез (с.г.в.) гомере – безгә мисал. Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең беренче хатыны Хәдичә анабыз Рәсүлебез (с.г.в.) нән 15 яшькә олырак була. Рәсүлебез (с.г.в.)нең берничә хатыны була. Бер хатыны – Әбү Бәкернең кызы Гайшә анабыз аннан күпкә – 30 яшькә яшьрәк була. Хәдис китапларын алсагыз, иң күбе шушы 2 хатыны турында әйтелгән. Хәдис шәрифләрендә безгә иң күп дәресләрне шушы 2 хатын-кыз биргән. Ягъни «плюс»ка да, «минус»ка да Рәсүлебез (с.г.в.) мисал күрсәткән, бәхетле тормышны күрсәткән. Әгәр дә кеше гадел, әдәпле, тәртипле, ышанычлы икән – чыксыннар. Ләкин гаиләдә диннәр яки телләр каршылыгы калып чыгу мөмкин. Катнаш гаилә коручылар саны да күбәя генә бара.

Әлбәттә, татар кызын кияүгә алу хәерлерәк. Әгәр ул: «Юк, мин – аны яратам, ул – мине ярата», – ди икән, ул чакта, ул кыз динебезне кабул итсә, тагын да хәерлерәк. Әгәр дә ул үз динендә калса, әти-әниләр каршы булса, ул вакытта да никах укыла. Ләкин балалар мөселман динендә була.

Балаларга аңлатырга кирәк. «Яратам» дип өйләнешәләр, яшиләр, ә картайгач, берсе – бер зиратта, икенчесе икенче зиратта ятырмы? Ул кыз бала динебезне кабул итсә, хәерлерәк булыр.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА.

intertat.tatar.

Тракторчы Фәрдия әби

Спас районының Көек авылында 99 яшьлек Фәрдия әби Гатина яши. Киләсе елда йөзне тутырам әле дип сөенеп йөри. Унбиш ел буе тракторчы булып эшләгән ул. Әле дә трактор йөртергә хыяллана!

Мин йорт ишеген ачканда Фәрдия апа таякка таянып чолан баскычыннан төшеп бара иде. Елмаеп җибәрде, үз оныгын каршылаган кебек: «И, бәбекәм», – дип җылы итеп кочып алды. «Әйдә, кызым, әйдә», – дип бүлмәгә алып керде. Бүрәнә йорт, диварда элеккеге тартма сәгать эленеп тора, тәрәзәдән ак чәчәккә чумган алмагач күренә. Утырып дога кылдык.

Фәрдия әби үзе генә яши, әле янына малае кайткан иде. «Мунча яга торсам да буладыр, кичкә кадәр сөйли ала бит ул», – дип шаяртты Гыйльман абый. 99 еллык гомерне бер көнгә дә сыйдырып булмыйдыр инде. Фәрдия әби үзе барысын да хәтерли, зиһене дә, юмор хисе дә, усаллыгы да Аллага шөкер.

Фәрдия апаны авылда усал дип йөртәләр икән. Үзе әйтте. Ул унбиш еллап тракторчы булып эшләгән. Гел ир-атлар арасында эшләгәч, усаллык та кирәк булгандыр.

– Тракторга ике сабан тагып эшләдем. Сабанчылар тимерне җиргә тирәнрәк кертә дә, минем трактор ыңгыраша, минем йөрәк әрни башлый, шунда егетләргә кычкыра идем. Хәзер дә миңа тавыш күтәргәнне яратмыйм, үзем генә кычкырам, – дип елмайды ул. – Акыллы усал булырга кирәк. Шул усаллык саклады мине, кызым. Ул вакытта тракторда эшләгән кызларның күбесе аракыга алданып харап булды. Ир-ат хатын-кызга бер рюмка эчереп кысып алса, кыз эри дә төшә. Алдансаң, хурлыгы күпме аның! Аллага шөкер, сүз әйтерлек булмадым...

Фәрдия апа окоп казу, урман кисү газапларының барысын да күргән. Үзе ишле гаиләдә туган, белемен дә алган. Ул әтисенең олы кызы булган. Җиде яшьтән әтисе белән ат арбасында йөргән. Әнисе белән кырга арыш көлтәләрен ташырга барган. Сугыш башланганчы тракторчыга укыган. Сугыш турында хәбәрне дә кыр сукалап йөргәндә белгән. Дәү ЧТЗ тракторында эшләгән. Ул тирәдә ике генә шундый трактор булган. Икенчесе башка авылда, шулай ук хатын-кыз кулында. «Сугышка китәсе булган шунда, кителмәгән бит тинтәк баш», – ди Фәрдия апа.

Ул әле дә тракторларга тыныч күңел белән карый алмый. «Трактор күрсәм, күңел җилкенеп куя. Утырып китәсем килә. Җимерелсә дә, тракторларны үзебез ясый идек. Ирләр юк бит инде ул вакытта. Аның кайтканы да йә аяксыз, йә кулсыз. Запчасть булмый иде. Күргән җирдән тимерләрне җыеп йөрдем», – дип искә ала ул.

Булачак ире белән дә Фәрдия апа тракторда эшләгәндә танышкан. Харис абый Фәрдияападан дүрт яшькә яшьрәк булган. «Миңа дигән егетләр үлеп бетте. Калганнарын матуррак кызлар алып бетерде, мин калдым. Ул армиядән кайтканны көттем, 50нче елда кияүгә чыктым. Насыйбым шул булгандыр инде. Ул вакытта яраттыммы, юкмы – белмим дә. Балам, сиңа шуны әйтәм: матурны эзләмә, акыллы булсын. Матурга башкаларның да күзе төшә», – ди ул.

Ире дә тракторчы булган, Фәрдия апа аның ярдәмчесе булып эшләгән. Берсе көндезге сменада, берсе – төнлә. Ике елдан беренче балалары туган. Фәрдия апа бәләкәй баланы әнисенә калдырып, басуга чыгып киткән. Икенче баласын тапканда комбайнда эшләп йөргән...

Шул вакытта бүлмәгә Гыйльман абый кереп чыкты. «Әнинең эштән кайтканын көтеп тәрәзә төбендә утыра идем», – дип өстәде ул...

Усал булсам да, кеше белән әрләшмәдем, ди Фәрдия апа. Бер хәлне генә искә алды. Иренең элеккеге йөргән кызы аны үзенә кайтарырга теләгән. Менә аның белән әрләшкәннәр. Мәхәббәт нишләтмәс. «Гел ирләр арасында эшләгәч, ирегез көнләшми идеме?» – дим. Артык көнләшмәгән, үзе дә шунда эшләгән ич, тик артык ачылып китеп сөйләшкәнен яратмаган.

Харис абый 1996 елда вафат булган. Биш ел чирләп яткан. «Соңгы тапкыр мунча кергәндә хәле авыр иде инде. Үзем юындырдым. Ул яшь иде ич әле, матур... Син мине шулай юындырырга тиеш идең бит, дим. «Аллаһның тәкъдиредер», – диде...»

Фәрдия апаның күзләре яшьләнде. Югалтулар ул гына булмаган. Алар өч бала тәрбияләгән. Бер малайлары 49 яшендә үлгән. «Нинди генә авырлык килмәсен, шөкер итегез», – дип нәсихәт бирде әңгәмәдәшем.

Безнең фотограф Расих абый өйгә соңрак керде. Фәрдия апа сикереп торды да, аның белән кул кысып исәнләште. Расих абый аппаратларын сумкасыннан чыгара башлады. «Эзләмә әле, әйберләреңне куеп тор. Утыр әле!» – ди Фәрдия апа. Расих абый аның сүзен тыңламады, әле дә сумканы кабалый иде. Фәрдия апа торып басты да: «Утыр, бу йортта мин хуҗа!» – дип тавышын күтәреп әйтте. Менә ул усаллык кайда икән! «Әүвәл йортка дога кылырга кирәк», – дип ачуланды. Утырып дога кылдык. Фотограф төшерә башлагач: «Яулыкларым әйбәтме, кызым, ямьсез әби димәсеннәр», – ди. Фотоны күргәч, бер кияү дә табылыр әле, дим. «Тфү-тфү, әстәгъфирулла», – дип көлеп куйды...

Тракторда эшләве аны ачлыктан саклап калган дисәм, ялгышмам. Ничек кенә булмасын, тракторчыларны ашатканнар, хөрмәт күрсәткәннәр. Күршедәге рус авылы Бураковога баргач, дуңгыз колагыннан аш та пешереп биргәннәр. «Ашында бәрәңгесе бар иде, шуны ашадым. Кайткач әтигә сөйләдем. Әти өчен мин бик зур кеше идем. «Ник сез татар баласына дуңгыз колагы ашаттыгыз?» – дип Бураковога барып кергән. Әтине складка алып барганнар. Анда бер дуңгыз асылынып тора икән, шуннан башка әйбер булмаган. Кеше ул вакытта үләксәне дә ашады бит. Тракторчыларны барыбер ашаттылар әле», – дип искә алды ул.

Кияргә кием дә булмаган. Майга буялып каткан итәкләр... Аның астында бер кат ыштан гына. Райком секретаре Май бәйрәмендә Фәрдия апага күлмәк алып килгән. Аннан соң ун метрлы тукыма алып кайтып биргән, тик анысы өчен акчасын да сораган, 100 сум торган ул.

Бер диварда төрле төстәге чәчәкләр белән чигелгән тукыма эленгән. «Үзегез чиктегезме?» – дим. Килене бүләге булып чыкты. Заманында үзе дә чиккән. Андый эшкә вакыт та калмаган. Трактордан кайткач, аулак өйләргә барырлык та хәл булмаган бит...

Өстәлдә кызыл тастымал өстендә коңгырт дисбе ята, шунда ук лупалы күзлек, дини китаплар, боргычлы яшел телефон тора. Фәрдия апа ул китапларны әле дә укый, гарәпчә дә укый белә. Аннан бакчага йөгереп чыгып китә. Анда җиләкләренә су сибәргә кирәк. Помидорлар да утырткannar. Кызы һәм малае кайтып тора. Узган кышны Фәрдия апа беренче тапкыр Казанда кызында үткәргән. Быел бармаска дип тора. Ашауга, йоклауга карата бернинди зарлары юк. «Бераз эшләп тә алсаң, кереп авасы гына кала», – дип елмая.

Сыер булса, анысын да савар иде әле. Хәзер бетергәннәр инде. Заманында өчәрне тотканнар. «Юләр кешеләр генә сыерны бетерә. Акыллы кеше сыерга тими. Сыйлы көнең – сыер, дигәннәр», – ди ул.

Фәрдия апа трактор да йөрткән, агач та утырткан, ире белән йорт та салган, балалар да үстергән, югалтуларга да түзгән... Сөбханалла! Хәзер ул авылдагы иң өлкән кеше! Туган көнемә килерсез, дип калды. Насыйп булсын!

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.
Автор фотосы.

Банан... нурланыш тарата?

Нурланышның куркыныч булуы һәркемгә мәгълүм. Әмма бу күренеш турында без белмәгән нәрсәләр дә шактый әле, шуларның кайберләрен искә төшерик. Нью-Йорк Үзәк вокзалын төзегәндә бик күп гранит кулланылган, шунлыктан анда радиация дәрәҗәсе бик югары һәм хәтта атом электр станцияләрендә рөхсәт ителгән нормадан да артып китә. Тәмәке тартучы ел дәвамында 300 рентген процедурасына тәңгәл нурланыш дозасы ала, чөнки төтендә радиоактив изотоплар бар. 10 банан бер уч уран кадәр диярлек үк радиоактив! Пилот һәм стюардессалар елына АЭС хезмәткәрләренә караганда күбрәк нурланыш дозасы ала, шунлыктан алар рәсми рәвештә "радиация шартларында эшләүчеләр" сыйфатында теркәлгән. Узган гасырда АКШта атом-төш коралын ясау буенча программа "Манхэттен проекты" дип йөртелә, аның кысаларында радиациянең кешегә тәэсире рәхимсез сынаулар нигезендә дә тикшерелә, мәсәлән, сабыйларга радиоактив солы боткасы ашаталар, Альберт Стивенска плутоний инъекциясе кадыйлар (уколдан соң ул 20 ел яши әле). Мария Кюри ачкан радий башта теш пастасыннан алып конфетка кадәр бик күп әйбердә файдаланыла – табигый ки, бу сәламәтлеккә зур зыян сала, тик бу соңрак ачыклана. Ташкүмер ягыла торган электр станциясе янында яшәүчеләр АЭС янәшәсендә гомер итүчеләргә караганда күбрәк нурланыш дозасы ала. Чернобыль зонасында утыртылган соя үзендә радиациягә каршы торырлык матдәләр булдырган, бу ачыш кешеләргә дә файда китерергә мөмкин. Әлеге зонада Cryptococcus neoformans гөмбәсе үсә һәм нурланыш тәэсирендә рәхәтләнеп үрчи. Мышьяклы сәнәгать калдыклары кеше өчен шулкадәр үк куләмдәге атом-төш калдыгыннан зыянлырак. Кеше үзенең кесә телефонына караганда күбрәк радиация тарата. Без даими радиация тәэсирендә яшибез, аның күпчелеге зыянсыз, бары тик югары дозадагы ионлы нурланыш (рентген нурлары, гамма-нурлар һ.б.) кына куркыныч.

("Die Presse").

Суүсем шешә

Пластик калдыкларның күләме елдан-ел арта бара. Әлеге материалның табигатьтә череп таркалуы өчен 100 дән 500 елга кадәр вакыт кирәген белсәк тә, аннан тулысынча баш тартырга җыенучы юк, экологлар гына чаң суга. Исландиядәге Сәнгать академиясе студенты Ари Йонссон, бик күп материалны өйрәнеп, пластикка алмаш уйлап тапкан – суүсемнәр нигезендә шешә ясаган. Кызыл һәм көрән суүсемнәрдән алынган агарны бераз җылытып, шешә өчен формада бозлы сулы чиләккә чумыралар да, ул шул формага кергәч, берничә минутка суыткычка урнаштыралар. Су савыты әзер! Су белән тулы килеш ул үзенең формасын югалтмый, бушагач ук таркала башлый. Составы 100 процент табигый булган савыттагы су саф килеш саклана.

("Die Presse").

Филгә дә ирек кирәк!

Британиянең кыргый хайваннарны коткару хәйрия оешмасы активистлары Һиндстанның Уттар-Прадеш штатында Раджи кушаматлы филне коллыктан коткаргач, мескенкәй шатлыктан елап җибәргән. Илле еллык коллык дәверендә филнең 27 хуҗасы алышынган. Шул гомер буе аны тешле богауда тотканнар, кыйнаганнар. Хайван үткән-барганнан көн саен хәер сорашырга мәҗбүр ителгән, урамда кунган. Хуҗасы бер дә ашатмаган, шунлыктан фил пластик һәм кәгазь пакетлар белән тукланган. Активистларның филне хуҗасыннан суд аша дәгъвалавы бер елга сузылган, һәм менә ниһаять алар уңышка ирешкән. Хайванны филләрне реабилитацияләү үзәгенә алып киткәннәр, банан, манго, икмәк һәм печенье белән сыйлаганнар. Аннары мал табибе 45 минут эчендә аны богауларыннан арындырган. Яраларын бәйләп, үзен юып, ашатып, Раджины тыюлыкка җибәргәннәр.

("National Geographic").

● Юлий Цезарь.

● Наполеон Бонапарт.



● Никола Тесла.

● Сергей Рахманинов.

● Теодор Рузвельт.

● Ким Пик.



● Рим Папасы Иоанн Павел II.

● Фердинанд Маркос.

● Мэрилу Хеннер.

Искиткеч хәтерле кешеләр

Әлеге исемнәр безгә фәнни әдәбият, шоу-бизнес һәм сәясәт дөньясы аша таныш, бу исемлектә исә аларның барысын да бер нәрсә – феноменаль хәтер берләштерә. Атаклы физик Никола Тесла фотографик хәтергә ия була, беркайчан да бернәрсәне дә язып куймый, лабораториясе янгач, үзе элек уйлап тапкан әйберләрнең яртысыннан артыгын яңадан ясый. Американың 26 нчы президенты Теодор Рузвельт даими рәвештә хәтерен яхшырту белән шөгыльләнә: көненә 2-3 китап укып, иң вак детальләренә кадәр әйтеп эчтәлеген сөйли. Берьюлы берничә эшне башкару аңа берни тормый – китап укыган чакта ул ике сәркатибе белән дә рәхәтләнеп аралаша торган була. Бөек пианист, композитор һәм дирижер Сергей Рахманиновка фотографик хәтере ноталарны тиз арада истә калдырырга булыша, ул берничә минут эчендә әллә ничә музыкаль әсәрне ятларга өлгерә. "Яңгыр кешесе" фильмының героена әйләнгән Ким Пик барлык укылган текстларын тулысынча хәтерендә калдыра, ул китапның ике битен бер карауга күрә һәм шундук ятлап ала. Рим Папасы Иоанн Павел II 21 тел белә, йөзләрчә диалектта рәхәтләнеп аралаша. Филиппинда 1965-1986 елларда хакимлек иткән Фердинанд Маркос илдәге һәр законны яттан белә, аңа теләсә нинди озын чыгыш ясар алдыннан аны нибары бер тапкыр уку җитә. "Такси" телетамашасы продюсеры актриса Мэрилу Хеннер – гипертимезиягә (искиткеч хәтергә) ия дөньядагы унике уникаль шәхеснең берсе, ул сабый чагыннан бирле бөтен гомерен барлык нечкәлекләре белән хәтерли. Полководец Юлий Цезарь үзенең 25 меңлек армиясендәге һәр сугышчының йөзен хәтерли һәм исемен белә, бер үк вакытта берничә төрле эш белән шөгыльләнә ала. Наполеон Бонапарт та феноменаль хәтергә ия була, шунлыктан ул теләсә кайсы җирлектә кирәкле юлны бик тиз таба һәм теләсә нинди маршрутны исендә калдыра.

("Интересно.cc").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

25 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ФРОНТ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Акыл батл» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Трибуна «Нового Века». 16+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
23.00 «В ОДНУ РЕКУ ДВАЖДЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Хәлил Әбҗәлилов турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Заман көзгесе». 6+
17.00 «Сәләт». 16+
17.30 «Адымнар». 16+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.30 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Калеб». 6+
21.55 «Туган авылым». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «В ШАГЕ ОТ РАЯ». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЦЕНА ЖИЗНИ». 16+
14.40 «Вместе с наукой». 12+
15.10 «Магия вкуса». 12+
15.40 «Спутник. Русское чудо». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. ПОТЕРЯННОЕ СЧАСТЬЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СПРОСИ МАРТУ». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Подкаст.лаб «Гори огнем». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОКТОР КРАСНОВ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного.
7.35 Больше, чем любовь.
8.15 «ПЕЧКИ-ЛАВОЧКИ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Интервью у музыки. Никита Богословский».
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 Большие и маленькие.
15.05, 23.20 «Три минуты тишины».
15.10 «Тагефон, или Смерть «великого немого».
15.55 «Агора».
17.15 Д. Шостакович. Инструментальные концерты. ГСО Республики Татарстан. Дирижер А. Сладковский.
18.15 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Кривая Калашникова».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
22.15 «КРАЖА».
23.25 «Секреты древних строителей: Остров Пасхи».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15, 0.00 «НАПАРНИКИ». 16+

Сишәмбе

26 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ФРОНТ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Төймә» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Казаннан - казанга». 16+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.10 Хоккей. «Динамо» (Мн) - «Ак Барс». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «В ОДНУ РЕКУ ДВАЖДЫ». 16+
0.00 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «В ШАГЕ ОТ РАЯ». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЦЕНА ЖИЗНИ». 16+
14.40 «Вместе с наукой». 12+
15.10 «История русского быта». 12+
15.40 «Легенда о танке». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. ПОТЕРЯННОЕ СЧАСТЬЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ДРУЖИНА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СПРОСИ МАРТУ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОКТОР КРАСНОВ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 8.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 15.15 «Секреты древних строителей: Остров Пасхи».
8.05 Сказки из глины и дерева.
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 «ВАРЬКИНА ЗЕМЛЯ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Олег Ефремов. Рассказывает Дмитрий Лысенков.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Поэзия. Александр Межиров».
12.10 Цвет времени. Эдвард Мунк. «Крик».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 Оттепель. В добрый час. Евгения Уралова. Рассказывает Евгения Ивашова.
13.20 «Игра в бисер» «Поэзия Василия Жуковского».
14.05, 22.15 «КРАЖА».
15.10, 23.20 «Три минуты тишины».
16.05 «Алов».
17.15 «Эрмитаж».
17.40 Оттепель. В добрый час. Олег Даль. Рассказывает Юрий Поляк.
17.55 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.10 Оттепель. В добрый час. Татьяна Доронина. Рассказывает Анастасия Дьячук.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Дневники конкурса «Учитель года России».
21.30 Больше, чем любовь. Давид Боровский и Марина Писная.
23.25 «Иерусалим - строители священного города».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15, 0.00 «НАПАРНИКИ». 16+

Чәршәмбе

27 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ФРОНТ». 16+
13.00, 0.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
21.00 «Соотечественники». 16+
23.00 «В ОДНУ РЕКУ ДВАЖДЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.30, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Хәлил Әбҗәлилов турында телеочерк. 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДРУЖИНА». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЦЕНА ЖИЗНИ». 16+
14.40 «Вместе с наукой». 12+
15.10 «История русского быта». 12+
15.40 «Антарктида. 200 лет мира». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. ПОТЕРЯННОЕ СЧАСТЬЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СПРОСИ МАРТУ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОКТОР КРАСНОВ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 8.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 Лето Господне.
7.05, 15.10 «Иерусалим - строители священного города».
8.05 Сказки из глины и дерева.
8.15 «Жизнь и судьба».
8.50 «ВАРЬКИНА ЗЕМЛЯ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Геннадий Шпаликов. Рассказывает Даниил Шперлинг.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Давид Ойстрах. Воспоминания о музыканте».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 Оттепель. В добрый час. Алексей Баталов. Рассказывает Максим Севриновский.
13.20 Искусственный отбор.
14.05 «КРАЖА».
15.05, 23.20 «Три минуты тишины».
16.05 «Дмитрий Блохинцев. Человек эпохи».
17.15 «Библейский сюжет».
17.40 Оттепель. В добрый час. Татьяна Лаврова. Рассказывает Дарья Урсуляк.
17.55 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.10 Оттепель. В добрый час. Владимир Ивашов. Рассказывает Павел Чинарёв.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Консервативная революция».
22.15 «ИРКУТСКАЯ ИСТОРИЯ».
23.25 «Отён: забытая сестра Рима».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15, 0.00 «НАПАРНИКИ». 16+

Пәнҗешәмбе

28 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ФРОНТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Память сердца». 16+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.10 «Сәенеч».
15.15 «Шома бас», «Алты хәреф» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Точка опоры». 16+
19.00 Хоккей. «Торпедо» - «Ак Барс». 6+ По окончании - «Погружение на 100» . 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+
21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Гәүһәр Камалова турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДРУЖИНА». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00, 23.50 «ЦЕНА ЖИЗНИ». 16+
14.40 «Вместе с наукой». 12+
15.10 «История русского быта». 12+
15.40 «Другой атом». 6+
16.30 «ВЕРОНИКА. ПОТЕРЯННОЕ СЧАСТЬЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СПРОСИ МАРТУ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+

21.20 «ДОКТОР КРАСНОВ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 8.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 15.15 «Отён: забытая сестра Рима».
8.05 Сказки из глины и дерева.
8.15 «Жизнь и судьба».
8.40 «ВАРЬКИНА ЗЕМЛЯ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Евгений Урбанский. Рассказывает Василий Симонов.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Ираклий Андроников. Первый раз на эстраде».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 Оттепель. В добрый час. Владимир Земляникин. Рассказывает Севастьян Смышников.
13.20 Абсолютный слух.
14.05, 22.15 «ИРКУТСКАЯ ИСТОРИЯ».
15.10, 23.20 «Три минуты тишины».
16.05 85 лет Александру Голобородько. Линия жизни.
17.15 Моя любовь - Россия! «Башкирский костюм и французский платок».
17.40 Оттепель. В добрый час. Татьяна Самойлова. Рассказывает Полина Рафеева.
17.55 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.10 Оттепель. В добрый час. Никита Михалков. Рассказывает Юрий Цокуров.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Дмитрий Данилов. «Саша, привет!»
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Дневники конкурса «Учитель года России».
21.30 «Энигма. Олег Виноградов».
23.25 «Бибракта - тайны затерянного города галлов».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15, 0.00 «НАПАРНИКИ». 16+

Җомга

29 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45, 0.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!», «Алты хәреф» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 16+
23.10 «ПРОГУЛКА ПО СОЛНЕЧНОМУ СВЕТУ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Гәүһәр Камалова турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Родная земля». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 16+
21.25 «Татар әдәбияты дәресләре». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДРУЖИНА». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ЦЕЛУЮТ ВСЕГДА НЕ ТЕХ». 12+
14.30 «Вместе с наукой». 12+
15.00 «История русского быта». 12+
15.30 «Юрий Андропов. Терра инкогнита». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. ПОТЕРЯННОЕ СЧАСТЬЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Уже не дети». 12+
23.50 «ОДИН НА ОДИН». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 8.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 15.20 «Бибракта - тайны затерянного города галлов».
8.05 Сказки из глины и дерева.
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 «ВАРЬКИНА ЗЕМЛЯ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Олег Табаков. Рассказывает Владислав Миллер.
10.20 «ДАЧНИКИ».
12.15 «Первые в мире».
12.45 Открытая книга. Дмитрий Данилов. «Саша, привет!»
13.15 Оттепель. В добрый час. Инна Гулая. Рассказывает Мариэтта Цигаль-Полищук.
13.30 Власть факта. «Консервативная революция».
14.10 «ИРКУТСКАЯ ИСТОРИЯ».
15.15, 22.10 «Три минуты тишины».
16.15 «Энигма. Олег Виноградов».
17.15 Письма из провинции.
17.40 Оттепель. В добрый час. Андрей Миронов. Рассказывает Михаил Тройник.
17.55 «Царская ложа».
18.40 «Смехоностальгия».
19.10 Оттепель. В добрый час. Станислав Любшин. Рассказывает Максим Керин.
19.45 «Алов».
20.35 «СКВЕРНЫЙ АНЕКДОТ».
22.15 «2 Верник 2». Олег Басилашвили.
23.30 «КИРЕ».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15 «НАПАРНИКИ». 16+

Шимбә

30 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.15 «Сөенеч».
11.30, 0.45 «Музыкальный майдан». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Вечер бокса в Альметьевске». 16+
16.30 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты. 16+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «КНИЖНЫЙ КЛУБ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Гәүһәр Камалова турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Егет чак, җырлар чак». Рөстәм Закировның юбилей кичәсе. 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 Спектакль «Миркәй белән Айсылу». 16+
22.30 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Вместе с наукой». 12+
5.30 «Боль. Жестокая радость бытия». 12+
6.30 «Я тебя знаю». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «ВСЕМ СКОРБЯЩИМ РАДОСТЬ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ФЛЭШМОБ». 12+
14.50 «Ночной дожор». 12+
15.45 «ОСЕННЯЯ МЕЛОДИЯ ЛЮБВИ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «РАСПУТИН». 16+
22.30 «СКРЮЧЕННЫЙ ДОМИШКО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Наше всё». 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «БЕГ». 12+
17.00 Ко дню рождения Юрия Любимова. «Человек века». 12+
18.20 «Михаил Задорнов. вся жизнь». 16+
19.10 «Эксклюзив». 16+
20.00 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 Бокс. Вечер Чемпионов IBA. 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00, 21.05 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «В кругу друзей».
12.50 «Доктор Мясников». 12+
14.50 «Юморина». 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.20 Большой праздничный концерт «Россия - Донбасс - Новороссия».
23.20 «ДВИЖЕНИЕ ВВЕРХ». 6+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.35 «СКВЕРНЫЙ АНЕКДОТ».
9.15 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ЦИРК ЗАЖИГАЕТ ОГНИ».
11.30 «Эрмитаж».
11.55 Земля людей. «Тофалары. Живая тайга».
12.25 «Эпоха Дмитрия Лихачева, рассказанная им самим».
12.55 Черные дыры. Белые пятна.
13.35 «Лазурная обитель».
14.20, 23.00 «Три минуты тишины».
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.20 «Нобелевские победы российской науки». «Илья Мечников».
16.05 Большие и маленькие.
17.55 «Первые в мире».
18.10 «Энциклопедия загадок».
18.40 «Доминанты».
19.45 «Кино история контрразведки».
20.25 «РОКИРОВКА В ДЛИННУЮ СТОРОНУ».
22.00 «Агора».
23.05 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.10 «Попутчик». 16+
14.20 «Игры разумов».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

1 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Эльмир Низамов һәм дуслар». 16+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Дуслык иленде». 12+
11.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Татар халык җырлары».
14.00 «Наша Республика - наше дело». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Амур». 6+
19.30, 22.30 «Семь дней». 16+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.30 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.30 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять».
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Килеп китсәм ни була?» Винарис Ильегет концерты. 12+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Фәйзи Биккинин турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+
14.20 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Заповедники РФ». 12+
6.00 «Институт надежды». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30, 14.35 «Первые в мире». 12+
8.45 «ОСЕННЯЯ МЕЛОДИЯ ЛЮБВИ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 22.40 «БУКЕТ». 12+
14.50 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.45 «ВСЕМ СКОРБЯЩИМ РАДОСТЬ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПАПАШИ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Легкие деньги». 16+
6.45 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.30 «Часовой». 12+
8.00 «Здоровье». 16+
9.05 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.20 «ПОКРОВСКИЕ ВОРОТА». 12+
17.05 «Кто взорвал «Северные потоки»?» 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «ArtMasters». Церемония награждения в Большом театре. 12+

«РОССИЯ»

6.15 «ПОСЛЕДНЯЯ ЖЕРТВА». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 16.00 Вести.
11.50 Праздничный концерт.
13.45 «САМАЯ ЛЮБИМАЯ». 12+
16.50 «Песни от всей души». 12+
19.00 Вести недели.
21.30 Москва. Кремль. Путин.
22.00 «1993 год. Перелом».. 12+
23.35 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Приключения волшебного глобуса, или Проделки ведьмы».
7.45 «РОКИРОВКА В ДЛИННУЮ СТОРОНУ».
9.15 «Кино история контрразведки».
9.55 Диалоги о животных.
10.35 Острова. Николай Крючков.
11.15 «ДЕНЬ АНГЕЛА».
12.30 «Ставропольский край. Из Ставрополя в Невинномысск».
13.10 Невский ковчег. Теория невозможного. Георгий Лебедев.
13.40 «Игра в бисер» «Александр Межиров. Лирика».
14.20 «Элементы».
14.50 «КРАСАВЧИК АНТОНИО».
16.25, 22.25 «Три минуты тишины».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.45 «Мюнхенский сговор. Приглашение в ад».
18.30 «Романтика романса».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 Дневники конкурса «Учитель года России».
21.05 «СВЕРСТНИЦЫ».
22.30 «Ночь Чайковского» в Клину. Гала-концерт лауреатов XVII Международного конкурса имени П.И. Чайковского.

«НТВ»

4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! Суперсезон». 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Салават театрының ямьле тамашасы

Казанда тормышыбызга ямь өстәп, өч көн Салават дәүләт Башкорт драма театры булып китте. Театр сөючеләргә «Безнең өйнең яме», «Хорошая девочка Лида», «Абау, димче килә!» спектакльләре тәкъдим ителде. Һәр спектакль икешәр тапкыр күрсәтелсә дә, һәркайсында тамаша залы тулы иде. Башкорт туганнарыбызны Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрының баш режиссеры Ренат Әюпов сәламләде. Театрның директоры Луиза Янсуар артистларга бүләкләр тапшырды. Салават театры директоры Айбулат Кутушев Яшьләргә җылы сүзләре, кунакчыллыклары өчен рәхмәтен җиткерде.

Кунакларның һәр спектакле үзенчәлекле булса да, «Безнең өйнең яме» тамашасын аерым телгә алмыйча булмый. Аны 2019 елда шагыйрь, язучы Мостай Кәримнең һәм Башкортстан Республикасының 100 еллыгы уңаеннан режиссерыбыз Р.Әюпов сәхнәләштергән иде. Спектакльдә Бөек Ватан сугышында әнисен югалткан украин кызы Оксананың башкорт гаиләсендә сыену табуы турында бәян ителә. Бу тамаша 2022 елда Бөек Ватан сугышына багышлап үткәрелгән «Дороги Победы» III халыкара онлайн-театраль марафонда «Теманың тирән ачылышы» өчен бүләккә ия булган иде. Салават театрында тамашачы спектакльне сәхнәдә урнашып карый, вакыйгалар, киресенчә, тамаша залында бара, Казанда исә артистлар да, театр сөючеләр дә үз урыннарына кайтты. Спектакльне тотып торган Җәмиль ролен Радмир Дәүләтбаев, Оксананы Нәзифә Аласова уйнады. Хәер, режиссер Р.Әюпов спектальләрендә, гомумән алганда, баш һәм ярдәмче рольләр булмый кебек, режиссер труппаны бер ансамбль итеп берләштерә белгәнгә күрә, кечкенә генә роль дә зур булып күренә. Бу спектакльдә дә нәкъ шулай булды. Ә бит вакыйгаларда бөтен труппа диярлек катнаша. Спектакльнең сәхнә рәссамы – Зилия Канчурина, композиторы – Илшат Яхин, биюләрне куючы Сулпан Аскарова. Инсценировканы исә режиссер үзе язган.

Александр Галибинның Россиядә киң прокатка чыккан һәм төрледән-төрле фестивальләрдә мул бүләкләнгән башкорт телендәге тәүге фильм «Сестренка» күпләрнең хәтеренә тирән уелып калгандыр. Беренче мәхәббәт гомер буе искә төшеп торган кебек, Мостай Кәримнең әсәре буенча уңышлы төшерелгән фильмнан соң кем нәрсә куйса да күңелгә ятмас иде кебек. Гел алай түгел икән шул. Р.Әюпов спектакле бөек язучының иҗатына мәхәббәтне һәм хөрмәтне тагын да арттырды. Дөрес, кинодагы кадрларны онытa торган түгел. Әмма экран аша тере хисләрне театрдагы кебек җанлы итеп чагылдырып була мыни ул? Бу әсәрдә исә берсе – үзенә энекәш, мәхшәр эчендә сыеныр куыш, икенчесе сеңел тапкан ике баланың хисләре кадерле. Әсәр сугыш вакытында кешеләрнең, милләткә карамыйча, бер-берсенә ярдәм итүе турында гына түгел, Җәмил исемле малайның, күңел җылысын кызганмыйча, Оксананың каткан, күшеккән җанын җылыту тарихы бу. Димәк, әсәр сугыш чоры вакыйгалары белән генә чикләнми, милләтара проблемалар турында гына уйлануга этәрми, тагын да зуррак фәлсәфи яңгырашка ия. Менә шул җылы хисләрне гәүдәләндерә алган да инде режиссер. Аның спектакле тоташ бер хисләр өермәсе диярге мөмкин. Чөнки балалар нәкъ менә хис белән яши, алар өчен әле бернинди акыл чикләүләре юк.

Спектакльнең тагын бер уңышы – милли тормышның киң вә матур итеп күрсәтелүе. Бу да режиссер Р.Әюпов иҗат тоткаларының берсе. Үз милләтенә шулкадәр гашыйк иҗат иясе булыр икән! Афәрин! Сәхнәдә курай моңы да ишетелә, күңелләрне җилкетеп Сабан туе авазлары да яңгырый, башкорт биюе дә вакыйгаларга матур гына «кереп утырган», мөгаллименең дәрес үткәргәнен, милли әлифбабызны өйрәткән мизгелне дә күрәбез. Бөтен нәрсә шундый табигый, җиңел, уен уйнаган кебек килеп чыккан ки, мәдәниятне көчләп тагу түгел.

Гадәттә, Р.Әюповның спектакльләре символларга бай була. Бу юлы да шулай. Сәхнәдә, мәсәлән, колга кебек озын җил генераторлары күрәбез. Алар тынып калган. Сугыш бара бит. Сугыш исә ул – терелекне, тормышны юк итүче. Сынатып карасаң, ул җил генераторлары сугыш чоры самолетлары пропеллерларына да охшап китә. Чынлыкта исә алар уенчык пропеллерларга охшатып ясалган һәм хыялый балачакны гәүдәләндерә. Соңга таба аларга җан керә. Бала-чага, пропеллерлар, бөтен сәхнә, алар белән тамашачы әйләнә сыман. Сугыш беткән. Тормыш тантана итә. Бар дөнья, әйтерсең, шатлык каруселендә әйләнеп, мәйханә килә...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәчетләрдә ил тарихы

«Казан Кремле» музей-тыюлыгында урнашкан Кол Шәриф мәчетендә Казан җәмигъ мәчетләренең фотокүргәзмәсен карап, ил, милләт тарихын, бүгенге көнне һәм киләчәгебезне күз алдына китерергә мөмкин. Татарның шанлы тарихын искәртеп, унике тарихи фото эленгән. Барысы да XVIII йөздә Казаныбызда төзелгән мәчетләр. Бөтенесе милли байларыбызның акчасына салынган.


● Кол Шәриф мәчете.

Әйтик, Апанай мәчете эре сәүдәгәр Якуб ибн Солтангали акчасына калкытыла. Бай акча биреп кенә калмый, хатыны белән төзелештә үзе дә катнаша. Соңрак бу мәчетне Апанаевлар карап, кайгыртып тора, мәчеткә исемне алар хөрмәтенә кушалар. Борнай мәчетен элеккеге агач бина урынына таштан салдыручы – сәүдәгәр М.Борнаев. Зәңгәр мәчет сәүдә остасы Әхмәт Аитов-Заманов акчасына салынган. Галиев мәчетенә сәүдәгәр һәм сәнәгатьче Муса Мәмәш акча биргән, соңрак байлар И.Уразаев, М.Галиев, И.Имәнколов аны төзекләндергән һәм киңәйткән. Нурулла мәчетен бертуган Ибраһим һәм Исхак Юнысовлар аталары беренче гильдия сәүдәгәре Гобәйдулла Мөхәммәтрәхим улы Юнысов васыять итеп калдырган акчага сала.

Сүзне озынга сузмыйча, шуны гына әйтик, Казандагы һәр мәчет элеккеге байларыбызга һәйкәл булырлык. Юнысов, Апанаев, Галиевләр гыйбадәт йортларын ниндидер табыш алу өчен түгел, мөселман милләттәшләренең мәнфәгатьләрен кайгыртып төзеткән. Бүгенге байларыбыз исә үзләреннән соң нәрсә калдырыр? Исәбе-саны булмаган банк биналары, сәүдә үзәкләре, күңел ачу комплекслары хәзерге заман кешесенә файда китерәме, әллә замандашларны фәкыйрьләндерүгә генә хезмәт итәме? Вакыт үткәч, аларны төзеткән байгураларны рәхмәт сүзе белән искә алучы булырмы?

Экспозициядә Казаныбызның күрке Кол Шәриф мәчетенә аерым урын бирелгән. Чөнки милли күтәрелеш елларында төзелгән бу мәчет белән татар милләтенең күп өметләре бәйләнгән. Исебезгә төшерсәк, 1999 елда беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев «Казан Кремле» музей-тыюлыгының ансамблен үстереп, Кол Шәриф мәчетен торгызу турында Указга кул куя. Ә Казанның 1000 еллыгы билгеләп үтелгән көннәрдә гыйбадәт йортын тантаналы рәвештә ачалар. Аның төзелешен бөтен дөнья буйлап сибелеп яшәүче татар милләте күзәтте. Кечкенә һәм ерак авылларда яшәүче әбиләрдән алып чит илләрдә гомер кичерүче дин һәм тел кардәшләребезгә кадәр төзелешкә акчаларын бирде. Тамчылардан күл җыела. Ул елларда татарның азатлыкка өмете нинди матур булса, Кол Шәриф мәчетебез дә шундый зур, мәгърур булып калыкты.

Инде яңа заман килде. Кабат җәмигъ мәчетен төзергә җыенабыз. Бу юлы тагын да зуррагын, 10 меңнән артык мөселманны сыйдыра торганын. Беренче ташын да салдык. Иң шәп проектны да сайладык. Хәер, конкурста беренчелекне үзебезнең Айвар Саттаров белән бергә Мәскәүдән «Гинзбург Архтектс» бюросына бирдек. Ул икесе ике төрле проектны ничек берләштерерләр – билгесез, аннан да бигрәк Мәскәүдән башка гына бер эшне дә башкара алмавыбыз кәефне кыра. Саттаров проекты гына ярамаганмы? Кол Шәриф мәчете проектында катнашкан, шуннан соң республикабыз буенча дистәләгән мәчет проектлары эшләгән абруйлы, тәҗрибәле архитектор лабаса. Аннан да бигрәк, Казансу елгасы буенда төзү килешенгән булса да, җир асты сулары якын, якын-тирәдә яшәүчеләр канәгатьсез, дигән сылтаулар табып, шәһәр башлыкларының мәчетне шәһәр үзәгендәге матур бу җирендә төзү уеннан баш тартуы борчый. Җәмигъ мәчетен адәм барып җитә алмаслык, кеше күрмәслек урында төзерләрме икән? Үз җирендә татарга тагын урын юкмы? Шәһәр үзәгеннән кабат сөрәләрме безне? Ярый хуш, беренче урынны алган ике проектка 2,5 миллион, икенчесен яулаучы тагын икесенә 1-әр миллион, өченче урынга чыгучыга 500 мең, тагын берәүгә президентның махсус бүләген бирделәр инде. Күпме акча! Ә мәчет юк әле...

● Апанай мәчете.

Күргәзмәдә яңа җәмигъ мәчете проектында катнашкан һәм финалга үткән проектлар да урын алган. Вакытлар үтү белән мәчетләрне төзү мәсьәләсе генә түгел, тышкы кыяфәтләре дә нык үзгәргәнен күрмичә мөмкин түгел. Нинди генә кыяфәтләргә кермәгән мәчетләр! Оча торган тәлинкә кебекләре дә бар. Завод торбасын хәтерләткән манараларны күреп шаккатмалы. Ярый, ахыры хәерле булсын.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● Айвар Саттаров проекты.

● Мәскәүдән «Гинзбург Архитектс» бюросы проекты.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип өчен В. ИМАМОВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль кәнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юлламы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмахананең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратыгыз

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 22.09.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2540 данә

Заказ 2636

16+